*Марс Шабаев*

# Сайланма әсәрләр

*Шигырьләр,*
*поэмалар,*
*балалар өчен шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2011

УДК 821.51.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Ш12

**Шабаев, М.С.**

Сайланма әсәрләр : шигырьләр, поэмалар, балалар өчен шигырьләр / Марс Шабаев; кереш сүз авт. Х.Камалов. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. — 335 б.
ISBN 978-5-298-01753-4

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марс Шабаевның бу китабына шагыйрь иҗатының поэзия сөючеләр тарафыннан яратып кабул ителгән әсәрләре тупланды.

УДК 821.51.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01753-4
© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Шабаев М.С., 2011

## Эзләнү юлыннан

Марс Шабаев поэзиягә шау-шусыз гына килде. Башта шигырьләр язды, үз тавышын эзләде, үз сукмагын чамалады. Аннары ниндидер бер дәрт белән поэмалар иҗат итеп ташлады. Тик шуннан соң гына аның тавышын ишеттеләр һәм аңа дикъкать юнәлттеләр. «Яңа җыр», «Кына гөле» поэмалары шагыйрьнең эзләнү юлында әһәмиятле моментлар булды.

Шигырьдә кеше язмышын, холык-фигылен сурәтләү гомумән авыр нәрсә, һәркемгә дә бирелми. Моның өчен тормышны белү генә җитми әле. Кайбер поэмаларда вакыйга-коллизия була, характерлар да төсмерләнә, әмма боларның барысына да укучы битараф кала. Ни өчен? Чөнки әсәрдә җылылык, эмоциональлек, авторның геройларын яратуы юк. Үзең яратмагач, бүтәннәр ничек яратсыннар аны? Димәк, әсәр ышандырмый. Ә «Кына гөле» ышандыра. Бистә кызы Рәшидә язмышы бик гыйбрәтле. Аның ялгышларында үзеңнең акылсызлыкларыңны ачыну белән искә төшерәсең. Рәшидә этисез үсә, бу хәл аның холкында нык эз калдыра. Артык беркатлы, анасы сүзеннән чыкмый, гореф-гадәтләргә буйсына... Ә кеше акылы кешегә ярамый, диләр. Бигрәк тә, Рәшидәнең анасы шикелле, искелектә катып калган булса. Рәшидә, аның сүзен аска калдырмыйм, дип харап була да инде...

Бу шәхси вакыйга, әмма шагыйрь шуны тәэсирле итеп яза. Укучыны кызыксындыра торган фикерләр һәм тойгылар күңел кылларына тия. Рәшидәне жәллисең һәм, үзем дә шундый хата эшләмим тагы, дип, уй төйнисең. Әсәр шулай укучыны битараф калдырмаган очракта гына иҗтимагый әһәмият казана.

«Җирән Конрад» әсәре бер дә көтелмәгән поэма булды. Материалы да кеше кулы тимәгән, тапталмаган. Автобиография элементлары нык сизелә. Шулай булмый хәле юк, Марс Шабаев лирик шагыйрь, ә лирикада шагыйрьнең шәхси кичерешләре, күргәннәре бик мөһим. «Сине эзлим» монологы тулысы белән шәхси тетрәнүдән тора. Шул ук вакытта бу бик табигый, сугышта этисен югалткан балаларга хас кичерешләр. Биредә уйлап чыгарылган әйбер юк, хисләр чын, тормышта булганча. Шушы чынлыгы белән укучыга тәэсир итә. «Үләннәрдән чыклар күптән кипкән, күзләрдән дә чыклар

кипкәннәр. Кайда, нинди үлән булып шыткан икән кырык бердә чыгып киткәннәр?..» — дип, шагыйрь ул авыр елларның әрнетә торган сурәтен күз алдына бастыра. Сугышта югалган этисен күңеле белән һаман эзләп, күпләрнең җанын тынгысызлый торган хис бу.

Сугыш чоры шагыйрьне тиз генә ычкындырмый, шул вакытлар аның канына сеңгән. Менә мәктәпкә немец теле укытучысы килә, җирән чәчле, таза гәүдәле. Бу үзе чын немец икән бит! Немецны фашист дип кенә күрә алган балалар аңа нәфрәт һәм балаларча хәтәр үч белән карыйлар, хәтәр үч белән төйнәләләр. Аларны ул хистән биздерүе кыен. Ә асылда, немец коммунист кеше икән, фашистлар тырнагыннан качып, ул безнең илгә сыенган. Аның хәлен аңлауга, хәленә керүгә лаек кеше. Әмма балалар моны тик соңыннан гына аңлыйлар... «Җирән Конрад»ның эчтәлеге шуннан гыйбарәт. Вакыйга контрастлы, драматизмга бай. Коммунист булганы өчен туган иленнән сөрелгән һәм ерак бер татар авылында дөнья куйган Конрад образы истә кала, интернационализм тойгысын уята.

Шабай поэмаларында ритмиканы тикшерү кызыклы булыр иде. Ритмика белән ул әсәрнең настроениесен тудыра, кискен хәлгә куелган геройларның эчке кичерешләрен шуның ярдәмендә тулырак ача. Әсәрдә нинди вакыйга булуга карап, ритмика шуңа муафыйк рәвештә алына. «Die tatarische Frau» поэмасы өчен ун, тугызлы үлчәү һәм сүлпән, бер калыпка сүзне төйгечләп тутырган алым һич батмас иде. Сюжет нигезендә катлаулы вакыйга ята. Врач-хирург татар хатыны яралы немецларны дәвалый. Әйтүе генә ансат, фашистларны дәваларга... Әмма моның өчен ничек үзеңдә көч табарга? Үзеңнең нинди акылыңа, нинди хисләреңә таянып бу эшне хаклы эш дип санарга?.. Ул заманда немецларга булган нәфрәтнең көчен күз алдына китерегез... Ә бит бу тормышта нәкъ шулай булган хәл, факт... Совет врачлары яралы немецларны дәваладылар... Күпме йөрәк түземе, нерв чыдамлыгы таләп ителә монда! Ә кеше йөрәге бер генә, һәм капма-каршы хисләр, фикерләр телгәли аны. Ләкин эшләргә кирәк. Врач хатын күңелендә эчке көрәш бара. Ниһаять, аңлый: ул биредә врач кына түгел, безнең гуман җәмгыять вәкиле дә. Авыруга, яралыга ярдәм күрсәтмичә, битараф булып калу — аның әхлагына сыймый торган нәрсә...

Бу образда татар хатыннарына хас булган сыйфатлар тулы чагыла. Эшенә гаять җаваплылык белән карау, теләсә нинди очракта да вак хисләрдән өстен була алу, кешегә илгәзәклек, авырлыкны үзенә алу — болар барысы да врач хатында бар. Шуңа күрә сугыштан соң да ул дәвалаган немецлар аны онытмыйлар, үзләренә кунакка чакырып язалар...

Шабайның һәр поэмасы — татар шигърияте өчен яңа сүз, яңа адым. Образ эчке кичерешләр аша ачыла. Ритмикасы да яңача әйләнмәләргә бай. Гомумән, поэмаларның тагын бер үзенчәлеге шунда: герой аерым, автор тарафыннан оештырылган шартларда түгел, бәлки үзенең тормыш юлында туры килгән язмышы кушканча яши. Бик мөһим нәрсә бу. Әсәрнең тормышчанлыгын, ышандыру көчен арттыра.

Марс Шабаев һаман эзләнә. Ул үзен проза жанрында да сынап карады. «Салда сәяхәт» повесте шагыйрьнең бу өлкәдә дә уңыш казана алуын раслый. Әсәр тоташы белән туган якның матурлыгы турында, Ык буйларының гүзәллегенә мәдхия. Ыкның тын тугайларын, серле чоңгылларын, хуш исле чәчәк белән тулган болыннарын ул якларда гомерендә дә булмаган кешеләр яратырлык итеп тасвирлап бирде ул.

Туган илнең киңлеген, Ватанның бөеклеген ярату аның шигырьләрендә Иделдән, Камадан, Ыктан башлана. Шабайга гомумән конкретлык хас, һәм аның шигырьләрен укыганда, Ык буйларының ямьлелеген күреп сокланасың, камышларның җырын ишетеп сөенәсең, үлән кыягында кояшны чагылдырган чык тамчыларының җем-җем килүенә рухланасың.

Шагыйрь поэзиядә тынгысыз эшли. Кайбер шигырьләре аның музыкага салынып, җыр булып җырлана. Шулай да шагыйрьнең йөзе поэмаларда җисемлерәк күренә. Аларда кеше язмышы бар, тормышның катлаулы яклары чагыла. Шигырьдә алынган фикерне, тойгыны ниндидер бер уртак ваклаучыга китерергә кирәк була. Уртак ваклаучы дигәнем — үзең генә тойган хис, тәҗрибә, шигъри танып белүеңнән килеп чыккан әйбер. Юк, бу нинди дә булса бер дөреслекне раслау яки инкарь итү формасында гына түгел, ә бәлки теге яки бу күренешнең, кеше холкының яңа бер мәгънәсенә төшенү, үзеңә күрә ачыш ясау шикеллерәк булуы мөмкин.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: шагыйрь иҗаты бүгенге көн вазгыятенә дә уңышлы ярашып яши, укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

Хисам Камалов,<br>Татарстанның халык язучысы,<br>Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

Казанныкы — Татарстанныкы.

Мин — татармын, димен,

Мин — татар!
Татарстанымда гына бары миңа:
«Син — безнеке!» — диеп, таң атар.

## Мин — сезнеке

Кайткан саен: «Кайсы авылдан сез?» —
Дигән сорау бик еш ишетелә.

...Укытучы булган безнең әти.
Әкияттәге чегән шикелле,
Авыллардан авылларга йөргән
Безне төяп,
Бик еш күченеп.
Аермасы шунда:
Калдырмаган
Арбасыннан коеп төшереп.

Әнкәй мине тапкан Тәкермәндә,
Туган йортта —
Үз әнисендә.
Кендек әбием Җәмилә әби:
«Улым, син бит кунак!» — дисенме?
Ә яшәвем сигез яшькә кадәр
Кадерәк инде,
Керәшен Кадерәк.
Үстергәндер типкәләми генә.
Тик иркәләп кенә,
Кадерләп.

Ә аннары...
Әти сугышларда...
Ул елларның авыр дүрт елын
Әниемнең туган апасында
Мин Усайда торып укыдым.
Сугыш кырларында ятып калгач,
Илне яклап, газиз әтием,
Миннән кала өч баласын төяп
Тәкермәнгә кайткан әнием...
Мең тугыз йөз кырык бишнең җәе.
Мин дә кайттым Тәкермәнемә.
Укып йөрү Хуҗәмәттә булды,
Ул да сеңгән хәтерләремә.
Өч ел шулай киләп сарып үтте...
Ә аннары инде — Минзәлә!
Ак Минзәләм,
Ыкның болыннары
Үз баласы итмәс мине әллә?

Гомеремнең калган бар еллары
Башкалада минә —
Казанда.
Чит җирләргә чыксам,
Анкетама
«Казанныкы» диеп язам да.
Казанныкы —
Татарстанныкы.

Мин — татармын, димен,
Мин — татар!
Татарстанымда гына бары миңа:
«Син — безнеке!» — диеп, таң атар.
Әйе, мин — сезнеке!

*1993*

## Җыр башлау

Анда миңа бар да үз һәм таныш,
Бар да якын миңа бишектән —
Ал гөләпләр,
Ап-ак төнбоеклар...
Мин аларны
Туганнарым кебек хис итәм.

Тик мин генә беләм чишмәләрнең
Челтер-челтер нәрсә сөйләвен:
Алар шулай сагынып мине көтә,
Өзелеп көткән кебек сөйгәнен.

Җәйге таңда,
Бераз йоклап калып,
Әрәмәлекләргә кичексәм,
Мине танып кабат җыр башлаучы
Сандугачларымны ишетәм.

Күзләремә чыккан соклануны
Таң чыклары бирә бит миңа:
Болыннарны айлар-еллар күзлим —
Туялганым минә юк кына!

Яшькелт Ыгым,
Сәламләргә ашыгып,
Камышларың сыгылып төшәләр;
Миңа юл күрсәтеп,
Як-ягымда
Выжлап оча авыр шөпшәләр.

Сазлыкларга такыр сукмак ята:
— Юл бирегез, бу мин... Мин, — дисәм,
Кочак җәеп көткән болыннарда
Серен сөйли миңа һәр сүсән.

*1960*

## Минем өчен

Чыңлап тора, җырлап тора
Ык болыны җәйге көндә.
Чикерткәләрнең романсы
Багышлана икән кемгә?

Кемгә икән елтырата
Карлыганнар дымлы күзен?
Зәңгәр ефәк шәл тибрәтә
Кемгә икән тымызык күле?

Тамам, тамам диеп торган
Бик өлгергән бу бөрлегән
Нигә шулай кызарынган,
Оялып ул кача кемнән?

Кемнәр өчен түшәк җәйгән
Кул тимәгән йомшак үлән?..
Бу садәлек, бу матурлык
Минем өчен —
Беләм, беләм!

*1960*

*** * ***

Сагыну гынамы бу?
Авырумы?
Әллә Ыгым
Диагнозын үзе куйсынмы?
Ык суларын эчтем, эчтем, эчтем...
Басалмадым барыбер сусынны...

Ыкка кушып эчеп бетерермен күк
Исертерлек зәңгәр һаваны.
Тәгәрәп-аунап алырмындыр төсле
Яшел үләннәрдән дәваны.

Сары комлыкларга колак куеп
Тыңланам да
Китәм сискәнеп:
Ишетәм кебек аргы басуларда
Туфрак ертып икмәк үскәнен.

Ә син, шәһәр кызы,
Аңламагач:
— Һәр җирдә дә шулай бит, — димә.
Туфраклар кара, сутлы монда —
Ягып ашарлык бар ипигә.

Тормыш юлларында күңелемә
Кунган булса әгәр бер-бер кер,
Мин ышанам:
Кочагына алып
Ык сулары юып бетерер.

Туган яклар...
Бер ай эчендә дә
Ун еллык көч биреп җибәрә.
Миндә булган барлык яхшылыклар
Шытып чыккан шушы җирләрдә.

*1965*

## Яңгыр үтте...

Яңгыр үтте басу сукмагыннан
Йөгерек адым белән, шыбырдап.
Аннан кояш чыкты,
        нур түгелде...
Арыш башаклары шул нурдан,
Шул яңгырдан уяндылар бугай,

Сары мыекларын тырпайтып,
Сөйләштеләр: «Бигрәк татлы булды,
Яусачы, — дип, — тагын бер кайтып!»
Басу карап йөргән авыл карты
Аңлап алды бик тиз аларны —
Башларыннан сөеп,
          сыйпап үтте,
Сөйгән кебек нәни баланы.
Гомере аның еллар сукмагыннан,
Җәйге яңгыр кебек йөгертеп,
Һай тиз үткән:
Башак исләреннән
Туймаган шул әле бер бөртек.
Ә башаклар,
          җылы кулны тоеп,
Сыендылар ныграк аңарга.
Иген һәм карт...
Тик үзләре белгән
Уртак бер сер бар күк аларда.

*1962*

## Фатиха сорау

Җилдә җырлый җикән камыш,
Җикән камыш сызгыра...
Тыңламасаң, аңламасаң,
Кагылмыйча уз гына.

Җилдән алган аһәңнәрең
Бир миңа, җикән камыш:
Юмартлык бит, кем әйтмешли,
Мәңгегә истә калмыш.

Без бергә шытып чыкканбыз
Шушы җир күкрәгеннән;
Җир белән тугандаш җаннар
Җир белән китәр моннан.

Алыймчы, җикән, моңнарың,
Салыймчы көйгә аны,
Аңласын җиһан тылмачсыз
Без белгән телдә аны...

Хыялым, йөгәнсез лә син!
Алай биек үрелмә.
Җикән җырын кайтарып бир
Туган-үскән җиремә.

Аны тыңлар кешеләрем
Яшиләр янәшәмдә;
Җикән камыш исеменнән
Шуларга эндәшәм дә.

*1967*

*** * ***

Озын сыйрак, җиңел сөяк —

Кояш үтә күренә.
Уалып китәр челтер-р-р итеп,
Сак кагыла күр генә.

Тупаслык-саксызлыклардан
Коелыр да төшәр күк;
Ул коелыр, көн кинәттән
Кара төнгә күчәр күк.

Уйный сабый, кайгы белми,
Таштан ташка сикереп;
Чулпыларының чыңнарын
Өзелмәс җыр иттереп.

Ай йөгерә, ел йөгерә,
Гел йөгерә кыз бала...
Әйткәндер аңа әнкәсе:
— Йөгер, көчең кызганма.

Толымнарың кая тартса,
Туктама, шул якка бар;
Чулпыларың чылтыравын
Җирсеп көткән зат табар.

Боргалан да, бормалан да,
Хаталарың мул булыр...
Иң турысы, иң газизе
Үзең тапкан юл булыр.

(Яшьлегенә абынганда,
Юл бирегез, ташлар, сез!)
Бара-бара буй үстергәч,
Балалыгың ташларсың.

Чулпыларың чылтыравын
Җиткерерсең Чулманга.
Челтер-челтер, җилдер-җилдер —
Зарыгадыр ул анда...

Шуннан бирле гел йөгергән,
Буй үстергән бу бала...
Гыйшык тотам шул балага —
Ык исемле елгага.

*1967*

## Ык агамыни?

*(Бер ханым соравы)*

Ык ага.
Ыкта чуртан бар.
Вак балыклар йота ул,
Су асты подданныйларын
Дер селкетеп тота ул!

Вакыт та чуртандай комсыз:
Ул безне йота тора...
Менә шуннан бу дөньяның
Мәгънәви ягын сора!

Вакыт кануннары кырыс,
Тормыш аңа буйсына.
Вакыт йоткан гомерләрне
Кеше гомер юксына.

Юксына да...
Табигатьтән
Ала көч, ала гайрәт.
— Диалектика, — дисезме?
Булса соң, булсын — әйбәт...

Яманатын алып китеп,
Яхшы атын калдырып,
Исеме һәм эше белән
Исәннәрне яндырып
Үлә кеше...

Үлән булып
Шытып чыга яңадан;
Бабайлардан балаларга
Күчә тора яңа кан.

Ык ага гомер бакыйдан,
Тормыш та шулай ага...
Берәү китсә, бу дөньяга
Киләдер ике бала...

Кешелек яңарып тора,
Яңарып тора вакыт —
Мәңге бергә шул агымны,
Бар, кара син туктатып!

*1967*

## ...Ра-ра-о-ом!

Ык буе. Үсмер чак.
Болыннан кайтабыз.
Аргы як — таулы як:
— ...ра-ра-о-ом...
Яңгырый кайтаваз.

Кайтаваз илерә:
— ...ра-ра-о-ом...
Юк паром.
— ...ра-ра-о-ом...
Буыннар тотмыйлар —
Эт булып аруым.

Таң яңа кабынган,
Йокылы, чыклы җир.
— ...ра-ра-о-ом...
Паромчы
Куышта йоклыйдыр.

Белми дә ул синең
Дөньяда барлыгың.
— ...ра-ра-о-ом!

— ...ра-ра-о-ом!!!
Бетәсен карлыгып.

...Олыгайдым, ир булдым.
Ык түгел арада —
Яшьлекне:
— ...ра-ра-о-ом...
Чакырып карарга.

— ...ра-ра-о-ом!
Паромчы
Чыкмаса чыкмасын;
— ...ра-ра-о-ом...
Паромчы йокласа йокласын.

Яңгыра, кайтаваз:
— ...ра-ра-о-ом...
— ...ра-ра-о-ом...
Кайтарчы, кайтаваз,
Үсмер чак аруын.
— ...ра-ра-о-о-о-о-ом!

*1967*

## Педучилище каеннары

Минзәләмә кайттым.
Минзәләдә
Ак бәс сарган моңсу каеннар:
«Бу кем тагын?
Нишләп йөри монда?» —
Дигән төсле миңа карыйлар.
Танымыйлар...
Ә мин менә үз кулларым белән
Утыртканын — берсен таныдым.
Кәүсәсенә барып сарылдым да
Пышылдадым:
«Бу — мин, акыллым...»
Каенкаем калтыранып куйды,
Коелдылар ап-ак бәсләре.
Ул да әйтте кебек:
«Картайгансың...
Ап-ак бәстә инде чәчләрең...
Күзләреңдә әллә яшьләрең?..»

Училище бинасыннан шунда
Йөгерешеп кызлар чыктылар:
«Ә без сезне көтә идек!» — диеп,
Көлешә-көлешә, наян-чытлыклар
Эчкә чакырдылар.
Каеннар да:
«Син икәнсең!
　　　　Әйдә, уз түрдән!» —
Диеп шаулаштылар.
Бәсләр сибеп,
Юл суздылар җем-җем ак нурдан.

Еллар җиле мине каеннардан
Алган иде йолкып-каерып...

Күптән инде...
Сирәк кайтыла шул...
Ә яшәүләр аерым-аерым
Ай-һай кыен!
Даим сагындыра...
Ак Минзәләм,
Җуйма:
мин — улың...
Соңгы сулышымда да каеннарың
Сибеп торса иде ак нурын.

*1993*

## Зөһрә йолдыз

Минзәләнең төне аяз иде.
Рәшит Гәрәй* белән без икәү
Мөҗип** дусны өенә озата бардык.
Алар сизде микән, юк микән:
Ай-йолдызлы күктә якты янып,
Зөһрә йолдыз торды җемелдәп.
«Фәрештәдәй, безне озата килә...» —
Диеп уйлап куйдым күңелдән.

Әйт син, йолдыз:
Кайчан,
Кайсы чорда,
Кайсы Зөһрә кызы татарның,
Күккә ашып,
Моңсу балкыды да —
Аның исеме белән аталдың?
Әкиятләр алар серле һәрчак:

Айда да бит, дибез, Зөһрә кыз.
Минзәләнең аяз төннәрендә
Син бигрәк тә якты, и йолдыз!
Ә җир кызы Зөһрә бер дә синнән
Ким балкымый күңелем күгендә:
Уңган да ул,
Серле һәм гүзәл дә —
Гүя чын фәрештә бүген дә.

Минзәләнең төне аяз иде,
Ничек булыр икән иртәсе?
Әйтче, йолдыз,
Кайсыгызны икән
Казаннарга урлап китәсе?
Зөһрә йолдыз әйтте:
«Юк, ярамый...
Минзәләне ятим итәрсең...»

*1993*

## Кадерәк

Якташларның үпкәләве бер хәл,
Хәтер ачы, хәтер битәрли.
Хәтер томаннары арасында
Кадерәк һаман калган бит әле.

Беркемгә дә әйтеп булмый торган
Изге хисем итеп, кадерләп,
Илле еллар йөрәгемдә йөрттем,
Бала чагым иде Кадерәк.

Минзәлә-су буйларында калган
Мираж кебек тонык шәүләңне
Капласа да, җуялмады еллар,
Җуялмады дөнья шаулары...

Кырык бернең елак яңгырлары,
Көзге яңгырлары ияртеп
Алып киткән иде...
Ул елларның
Каргышлары бүген тияр күк.

Теләпмени?
Еракларда барган
Сугыш өермәсе бөтерде,
Суырып алды мине, Кадерәк, синнән...
Ул — аждаһа үзенә бертөрле.

Аерып алды, оныттыра язды.
Сугыш сөремнәре әле дә
Каплап тора сине.
Мин күмелгән
Шушы җирнең олы гаменә.

Ә син, Кадерәк, гамьсез сабый чагым,
Кояш-айлы якты бер дөнья...
Гөнаһлымын сиңа кайтмый йөреп,
Кичералсаң, кичер бер юлга.

Баш идерде мине кырыс еллар,
Кырыс еллар җырын җырладым.
Ничек каерып ташлыйм ике араны
Аерып куйган сугыш елларын?!

Инде менә сугышларсыз-нисез
Сабый елларыма кайттым мин.
Кайттым, Кадерәк,
Тик барыбер синдә
Сугыш сагышын гына таптым мин...

*1993*

## Ак каеннар йөгерә

Чыгарылыш кичәсеннән таңда
Очынып кайтып килгән кызлар күк,
Җитәкләшеп ак каеннар йөгерә...
Берсе миңа кулын сузар күк.

Каршы барсам әгәр...
Юк, тоттырмас —
Чытлыкланып читкә тайпылыр;
Июнь төннәренең сихереннән
Яшел яллы кыргый тай булыр...

Каеннарда һаман яшьлек күрәм:
Яшьлек аның сылулыгында.
Аклыгында — яшьлек,
Яшеллектә...
Таң җилендә сыгылуында.

Каен урманнары шундый якты!
Якты сафлык бии...
Туйны күр!
Җиһан нигә шундый яктылыкка,
Инсан ак бәхеткә туймыйдыр?!

Июнь төннәренә әсирлеккә
Кул күтәреп йөгерә каеннар...
Ә кайдадыр күккә кул күтәреп
Ялваручылар бар, кайгы бар...

Якты шатлыгымнан оялам да
Якты бәхетемә куанам.
Нишләр идем, ят җирләргә кусаң,
Ак каенлы җирем, Ил-анам!

*1967*

* * *

> Җиләк җыям, как коям
> Дәү әнигә бүләккә.
> Монда җиләк күп икән,
> Аю-бүре юк икән...
>
> *Балалар җыры*

Чәчелеп киткән җиләк түгел —
Җыеп булмый уйларны;
Чәйгә салыр как итеп тә
Коеп булмый уйларны.

Тубал кебек тулган башың
Тырыс булса икән ул;
Тормыш шулай җырда гына
Кырыс булса икән ул...

Кайгыларны җуяр идек,
Торса коры теләктән.
Шатлык-бәхет җыяр идек
Кешеләргә бүләккә.

Ах, дөнья... Тылсымлы тырыс —
Шатлыкларга кечкенә,
Кайгыларга — төпсез тубал,
Тула белми һич кенә.

Арысландай азмы ирләр
Башы төпсез тырыста...
Балалар җырын ишәйтеп
Киткән алар тормыштан.

Чәчелеп яткан җиләкмени —
Батыр ирләр каберен
Җиһаннан җыеп йөрибез...
Таба алган кадәрен.

*1968*

## Ти-и-иде! Ти-и-иде!..

Тау астында — тал-тирәкләр,
Тал артында — Ык суы.
Җанбай күлдән ишетелә
Тәкәрлекләр үксүе:
Ти-и-иде!.. Ти-и-иде!..
— Кемнәр тиде?
Җофармы йә сусармы?
Оясыз калган тәкәрлек,
Гомерең ятим узармы?
Түзмәде күңел, ярсыды
Тәкәрлек тавышына:
Бала чакка кайтып, хәтер
Моң булып калды шунда.
Ул йөрде балтырган ашап,
Юа белән юанып...
Хәтер — сагышлы бер йолдыз:
Һич сүнәсе юк аның!
Уенны иртә оныткан
Сагышлар дөньясыннан
Ул йөрде күкәйләр эчеп
Тәкәрлек оясыннан...
Тәкәрлекләр, үксисез лә:
Ти-и-иде!.. Ти-и-иде!..
— Кем тиде?
Кайтармагыз шул елларга,
Кайтармагыз сез мине.
Көйде, көйде... утта көйде
Әтиләр...
Үстек ятим...
Ти-и-иде!.. Ти-и-иде!..
Безгә тиде
Зур сугыш...
Нәрсә әйтим?..

*1968*

## * * *

Әрәмәне бала-чага сарган,
Бала-чага... гүя саранча!
Гаепләмим комсызлыкта һич тә,
Юк, чыгармыйм һич тә саранга.

Без үзебез бала булмаганмы,
Йөрмәгәнме шулай тәм табып:
Пешәр-пешмәс әче бөрлегәнне
Кесәләргә салып йә кабып?

Ык буеның табигате юмарт:
Җаның нәрсә тели, бар да бар.
Балтырганнар, кузгалаклар безнең
Бала чакны озата баралар...

Әрәмәне бала-чага сарган —
Бөрлегән бит килә кызарып!

Авыл,
Әрәмәңдә күбрәк кайнашсыннар
Елгыр малайларың-кызларың.

Җир җылысын ялантәпи тоеп,
Җир сулышын сизеп чыклардан,
Җир кешесе үсә, җирне сөеп,
Бөрлегәннәр җыйган чаклардан.

*1968*

*** * ***

...Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»

*Г.Тукай*

Таныш бу моң, бишектән үк таныш —
Көен тоям, сүзен төшенмим.
Кем моңлана икән бу кадәрле,
Кайда җырлый, нинди кеше, дим?
Әле Заһит абый скрипкасын,
Әле Илһам тавышын төсмерлим.
Әле Гөлсем апа аһәңнәре сыман...
Аңлый гына алмыйм һичбер мин.
Транзисторны борам — анда түгел,
Печәнчеләр дисәм — чыкмаган.
Эзлим аны җикән камышлардан,
Эзлим аны якты чыклардан.
Һәм яктыра йөзем:
Һәрбер чыктан
Халкым карый кебек елмаеп.
Җирем үзе җырлый!
Җир булмаса,
Халкым да юк минем, җыр да юк.
Таныш бу моң, миңа күптән таныш —
Ул тирәннән килә, тирәннән.
Бу моң белән әле болгар бабам
Каен бишекләрдә тирбәлгән.
Бу моң белән Тукай калкып чыккан,
Бу моң Баһавилар җырында
Ленин күңеленә кереп калган...
Гаҗәпмени аны яңартуым
Ык буенда,
Җәйге болында.

*1968*

# Балыкчы карт сөйли

Август төне.
Куыш авызыннан
Дезертирдай салкын елыша.
Таң салкынын алдармын да, бәлки,
Йоклап китәрмен дип тырышма.
Чык тизрәк...
Күрче август күген,
Август күге нинди шәмәхә!
Пионерлар кара түккән төсле —
Сентябрь бит инде янәшә.
Су читендә агарып ни ята?
Каз кауры бугай.

Ал шуны.
Тукай, Такташларны исеңә төшер:
«Кисекбаш»ны, «Пар ат», «Алсу»ны.
Каурыеңны август күгенә ман,
Елгага яз татар моңнарын,
Уйлап торма кемнәр тыңларын да,
Уйлап торма дулкын юарын.
Елга, елга...
Еллар юалмаган
Моңнары күп безнең милләтнең.
Чырай сытма:
Җырга өйрәтәм бит,
Ат урларга сине өйрәтмим.

*1967*

## Янә сәлам бирү

Сәлам, Ыгым!
Беләм, исемең шигъри түгел,
Мәгънәң гади генә — елга, су...
Ләкин гомер бакый калыр миндә
Бу юксыну, сагыну, алгысу.

Зөяләрдә, Зәйдә йөзгәнем бар.
Тәмен белдем Мишә, Ашытның.
Тик барыбер җаным-тәнем белән
Сиңа, Ыгым, сиңа ашыктым.

Озаттың син мине Чулман аша,
Үрләп кара, диеп, Иделдән.
Аргамактай кая ыргылсам да,
Синең кулда калды дилбегәм.

Төшләремдә җирсеп ыңгырашам:
«Ы-ы-ык!.. Ы-ы-ык!..»
Бардыр сихерең.
Ыгым, суларыңа, агымсуларыңа
Елга бер керсәм дә — шөкермен.

«Һә-һә-һә-һә-ә-әй! Ык баласы,
күңелең йокламасын!» —
Диеп кага һәрбер дулкының.
Сагындырып җанны сыкратмасаң,
Юк илһамым минем, юк моңым.

*1969*

## Алиһәләр

Афродиталармы алиһәләр,
Алиһәләр Венералармы?
Антик кызлар.
Таш сыннарда күрдем,
Дастаннардан белдем аларны.
Сокланырга ярый...
Сокландыра
Музей залларында таш сыннар.

Айлы төндә Ыкта кызлар коена!
Көнләшүдән күккә ашсыннар
Алиһәләр, фәрештәләр...
Су кызлары
Әкиятләргә кереп качсыннар.
Астрономнар яңа исем белән
Бу төн яңа йолдыз ачсыннар.
Әлфияме, Әнисәме булсын,
Нәсимәме булсын ул йолдыз.
Ах, кызкайлар!
Җырга, дастаннарга
Ыктай озын әле юлыгыз.
Афродиталарны оныттырган
Әнисәләр, Әлфияләрне
Җырлыйсы иде —
Дөнья әйтсен иде:
Болар — татар алиһәләре!

*1969*

### * * *

Урман-сулар, болыннарга
Изге тынлык яшеренгән.
Кайгы-шатлыкларыңны сал,
Оялма күз яшеңнән.

Эчә тургай чык суларын,
Күккә менәр, җыр сузар.
Эчәм мин дә Ык суларын, —
Белмим, нинди җыр туар?

Болыннарда — аксыл томан,
Гөлләр чыкта коена...
Газиз җиргә зәңгәр күктән
Тургай җыры коела.

Тыелгысыз язгы судай
Ташыса да күңелем,
Җөрьәт итмим сүз әйтергә,
Әрсез бала түгелмен.

Олы тынлык, изге тынлык
Синдә генә, табигать!
Синең гади тургайларың
Нинди серле табиб, әйт!

Кояш батса, аең чыга,
Йолдызлар елмаялар.
Елмайса да моңаялар...
Көнләшә бугай алар.

Күрәләрдер ул йолдызлар
Бу бәхетле Җир барын:
Урман-сулар, кыр-болыннар,
Күктә — тургай моңнары...

Мин — кеше. Җирдә яшимен.
Барысына хуҗа, хаким.

Хакиммен диеп, Җиремне
Кыерсытмамын ләкин.

Хаким мин, әмма Җир улы.
Җир-анам миңа карый.
Ананы кыерсытырга,
Әйтегез, әллә ярый?!

*1970*

* * *

Ык суында йөзә пар акчарлак,
Юк аларда дөнья кайгысы.
Зәңгәр күкне кыеп-кыеп төшәр
Ак кайчысы белән кайсысы?

Юрамыйм да, юраган да булам
Юрамалый гына... тиктомал...
Әле зарыгу түгел, өзелү түгел,
Тойгыларны тыю... күк томан...

Ык өстендә йөзгән акчарлактай
Саф һәм якты әле хисләрем.
Парым югалткачтын, ярым җуйгач,
Белмим әле, белмим нишләрем?!

Зәп-зәңгәр күк. Кояш. Пар акчарлак,
Мин ваемсыз әле, кайгысыз.
Кыюлыгы җитеп, бәхетемә
Кулын салыр икән кайсыгыз?!

*1971*

* * *

Кабырчыклар җыям, кабырчыклар —
Диңгезләрдән түгел, инештән.
Бала чаклар — энҗе табар чаклар...
Ни кылансаң, бар да килешкән.

— Агымсуда энҗе буламыни?
Ул диңгездә үсә, тирәндә.
Дулкын шавы, дулкын бәллүендә... —
Зурлар миңа шулай дигәннәр.

Имеш, аны индус егетләре
Гомергә бер генә табалар.
Имеш, аңа җирдә шуңа күрә
Бәяләрне зурдан тагалар...

Күпне таптым, күпне югалттым мин
Агымсудай еллар эчендә.
Хыялдагы җем-җем энҗе хәзер
Чагыла инде, чагыла чәчемдә.

Тик барыбер кабырчыклар җыям,
Диңгезләрдән түгел, инештән.
Хыялдагы бөртек энҗе өчен

Баш тартам мең алтын-көмештән.

Минем энҗем — урман күлләрендә,
Үзебезнең агымсуларда.
Җитми аңа дөнья бәяләре,
Эзлим һаман, эзлим шуңарга.

*1971*

* * *

Кояш әле агач башларында
Эленеп тора арып, йокымсырап.
Ә түбәндә инде абагалар
Ялваралар төн карасын сорап.

Агачларның бер дә гамьнәре юк,
Алар горур,
Алар мәһабәт.
Изрәткәндер, ахры, җылы нурга,
Яктылыкка булган мәхәббәт.

Якты дөнья!
Яктыны сөйсә дә,
Агач түгел ләса бу бәндәң.
Төшереп тор искә хакыйкатьне:
— Караңгылык үрли түбәннән!

*1970*

* * *

Кама яры.
Җиңел зәңгәр чатыр.
Зәңгәр чатырларда кем ятыр?
Көмеш аймы, алсу таңмы аны,
Дулкын шауларымы уятыр?
Уятырга ашыкмагыз әле!
Сакчысы бар аның, карагыз:
Ары илле адым,
Бире — илле...
Йөреп тора изге каравыл.
Ары — илле,
Бире илле адым.
Аңа ияреп күктә ай йөри.
Барса — бара,
Туктады исә — туктый...
Дөньяның бу сихри кай җире?
Җиңел зәңгәр чатыр...
Чатырда — кыз.
Ә кайчандыр
Ак чыбылдыкларның эченә
Кызлар керә булган калтыранып
Сәгадәтсез зөфаф киченә.
Күктәге ай әйтерсең лә чулпы.
Көчләп ярәшелгән киленнең
Күз яшьләре белән юыла-юыла,

Шул заманнан калган эленеп.
Чулпы калган...
Кызны Чулман алган...
Бүген Кама — Киек Каз Юлыдай,
Яктылыкка тулып ага ул.
Җиңел зәңгәр чатыр.
Чатырда — кыз...
Сакта тора изге каравыл.

*1971*

## Хәтерләүләр

*(Шигъри бәйләм)*

Әткәм-әнкәм кабызып китеп барган
Яктысында гомер утымның
Тормыш китабының мин әлегә
Илле битен генә укыдым.

Бу китабым минем —
Хәтерләүләр...
Хәтерләүләр гомерем юлларын.
Хәтер — кинокадр, ни өчендер
Тәртипләрен бозып елларның,
Сүтә...
          сүтә...
                    сүтә...
Иң кирәкле,
Әйтелергә тиеш уйларның
Күплегеннән гаҗиз булгангадыр —
Бер еракка китә,
Бер кайта.
«Үткән еллар —
Аккан сулар...» — диеп
Җырлата да
Аннан моңайта.

Күңелдәге кичереш-табышларның
Еллар юып киткән бик күбен...
Онытылып укып утырганда
Тормыш китабымны мин бүген,
Хәтер күгемдәге иң беренче
Йолдыз булып әнкәм кабынып.
Биш дистәсен тутыралмады, бахыр...
Тол язмышы һәрчак авырдыр...
* * *

Ул яз артык иртә килде микән,
Әллә болай гына,
Шуклыктан —
Апрельдә үк ялантәпиләдек...
Дөресе,
Аякларга юклыктан.
Кутәрмәле чабаталар белән
Кар сулары ерып йөрүдән
Туйган иде безнең малай халкы.
Кара җирне бераз күрүгә,
Ходай биргән «ботинкадан» гына

Фарсит итә-итә,
Чабышып,
Җиңү көттек...
Чеби чыгып беткән
Аякларның кием сагышын
Тоймадык без.
Көчле башка сагыш —
Кайтыр микән безнең әтиләр?
— Сугыш бетә, — диләр.
Ни өчендер:
— Әткәң кайтыр, — диеп әйтмиләр...
Менә шундый апрель көннәренең
Тымызык кына матур кичендә
Без мәктәптә концерт куйган идек.
Исемдә әле,
Һаман исемдә...
Олтан салган итекләрем сөйрәп
Чыгып бастым сәхнә түренә.
Бик тырышып шигырь сөйләдем мин,
Тәрәзәгә үрелә-үрелә —
Әйтерсең лә тәрәзәләр аша
«Коммунизм кыры күренә»...
Концерттан соң дустым әйтә куйды:
— Шәп сөйләдең!
Итегең генә менә, малай, ну...
— Яланаяк чыгыйммыни, — дидем, —
Сөйләгәндә Такташ бабайны?!

Иртәгесен,
Кояш белән бергә
Нурландырып бөтен бүлмәне,
Бер пар чүәк балкып мине көткән!
Кемнең сандыгыннан —
Белмәдем.

— Такташ абыеңнан, улым, сиңа, —
Елмаюы моңлы әнинең.
Бәрәңгегә, ахры, алышып алган —
Киелә төшкән чүәк.

Ә минем...
Минем өчен
Көләч апрель белән,
Такташ исеме белән үрелеп,
Малай чакның ераклыкларыннан
Тора әле ул һаман күренеп...

* * *

Хәтерләүләр...
Ел томаны аша
Әткәй калка кояш төсендә.
Шул кояшка кереп эреде алар
Кырык бернең салкын көзендә.

Әткәй!
Ел томаны аша сине эзлим,
Томаннарда ялгыз эз генә...

Чыклы үләннәрдә ярылып калды
Шул ялгыз эз —
Синең эзләрең.
Син кояшка кереп күмелдең дә,
Ахры, белмәдең
Үзәгемне ничек өзгәнең...

Олау-олау китте ил ирләре,
Батырлыкка таңнан юл алып;
Йөзгә берәү кайтты...
Кайтмаганнар
Ерак меридианнарда югалып
Калдымыни?
Юк,
Калмады алар.
Һәркайсысы үзенең өендә.
Алар кемнәрнеңдер йөрәгендә
Бәйрәм итә Җиңү көнендә.

Алар бергә,
Алар безнең белән,
Тик һәркайсын эзли кемнәрдер.
Мин дә эзлим...
Сине соңгы тапкыр
Кемнәр,
Кайда,
Ничек күргәндер?

Кояшны мин һәрчак көтеп алам,
Таңнар белән торып каршылыйм.
Нурларына карап сокланам да:
— Бигрәк ерак алтын шар шул... — дим.
Алып китте алып китүен дә,
Кайтармады сине,
Югалтты.
Зәңгәр тәхетеннән төшми генә
Күзли мине,
Үзе югартын.
Син —
Бер дөнья миңа.
Кояш та син...
Син,
Эз салып чыклы үләнгә,
Шул кояшка кереп күмелмәсәң,
Кояш булмас иде түбәмдә...

*** * ***

Мин хәтерлим әле:
Тәкермәндә,
Яшәгәндә бабай йортында
Бер җан, бер тән булып унике җан:
«Булмый безгә, — диеп, — чуртым да!» —
Юктан да без кызык таба идек,
Кардан яланаяк чаба идек,
Кул «җылытып» тычкан утында.
Җәйләрендә безнең түбәбездә
Әйләнәләр иде тилгәннәр...

Коркылдашып бәбкә алган чакта
Алар, ахры, алдан белгәннәр:
«Тәгәрәшеп үскән тере йомгак —
Унике җан! —
Авыр еллар буйлап
Таралышыр әле», — дигәннәр.

Каршыдагы нарат кәүсәсендә
Тукылдаучы тукран тавышы, —
Әйтерсең лә табут кадаклаучы
Балтай урысының сагышы! —
Йөрәкләргә сугып тора иде,
Уеннарны оныттыра иде —
Өзелә кемнең гомер агышы?

Әллә сугыш окопларда гына,
Әтиләрне генә кырдымы?
Ярты мәктәп кара гүргә керде...
Үлем безне аяп тордымы?!
Балтай марҗалары елаганда,
Тәкермәннәр әллә җәйге таңда
Тыныч кына урак урдымы?

Унике җан идек.
Ничәбез бар?
Яланаяк чапкан юллардан
Ничәбезне үлем-тилгән алды?..
Ничәбезгә бераз соңарган?
«Калдырамын сезне орлыкка, — дип, —
Яшәмәгез кимлек-хурлыкта», — дип,
Язмыш безгә хөкем чыгарган.
Тәкермәндә тәкәрлекләр туе
Торфлыкта —
Сазлык түрендә
Шаулый микән?
Ник соң шулай була:
Еллар аша күпме үрелмә,
Кайтып булмый бабай нигезенә,
Кайтып булмый алай бик тиз генә
Тәкәрлекләр куып йөрергә...

Сүрелмәстер гомер-гомергә —
Сагыш кына көйри күңелдә...

*** * ***

Бирде язмыш,
Өеп бирде миңа...
Булгалады —
Абындым да мин,
Сыгылдым да,
Кабат турайдым да,
Сүрелдем дә,
Кабындым да мин.

Үзем белми,
Аны кемнәр белсен:
Күпме эшләнәсе эшләрем
Ятып калды!
Кайчак җитешмәдем,

Кайчак күктә йөрдем —
Төшмәдем...
Кайчак көч җитмәде,
Ә кайчакта
Нәрсәдәндер ваклык санадым.
Бүген менә барысын җыямын да
Вөҗдан бизмәненә саламын.
Булган булган инде!
Асылы бер үк —
Өлешеңә тигән көмешең.
Тартынмыйча әйтәм:
Без яшәдек
Үзебез өчен түгел,
Ил өчен.

Мин дә салдым үз КамАЗларымны,
Мин дә ерттым чирәм җирләрне,
Мин дә очтым космик корабларда —
Һич көтмәдем күктән биргәнне!
Әмма үлемсезлек таләп итмим.
Мин —
Гади бер кеше,
Меңнәрдән.
Мөмкин булса,
Сорар идем бары
Үз гомеремә калган көннәрдән:
Тормыш агымыннан тибәрелеп,
Яр читендә ярык тагарак
Булып аунамасам ярар иде!
Аксам иде алга,
Алгарак...

** * **

Мин тормышны уен гына санап
Йөрдем —
Булды!
Чөнки яшь идем.
Киткәннәрнең ачы тәҗрибәсен
Мирас итеп хәзер яшимен.
Кешелекнең рухи байлыгын мин
Җан азыгы итеп аламын,
Тик әҗәткә алам!
Кешелеккә
Мин бурычлы булып каламын.

Мин бурычлы, якты дөнья, сиңа,
Мин бурычлы Айга-Кояшка.
Мин бурычлы, акыл ияләре, —
Нинди байлык булса бу башта,
Мин аларны сездән үзләштергән,
Сезнең газапларны күрмичә.
Юк,
Хакым юк,
Миннән соңгыларга
Бу әҗәтне кире бирмичә,
Еллар тузанына күмелергә!
Мин бурычлы очкан кошларга —
Гомерем күкләрендә талпынганда,
Мин тырыштым кошка охшарга.

Бу тормышта барысы бер тамырда:
Кайгы-шатлык,
Яхшы-яманы.
Кешелекнең парадоксларда
Кайнап яши торган заманы.

Илле елым миңа набат кага!
Мин ишетәм шушы набатта:
Без яшибез икән кешелекнең
Үткән сабакларын кабатлап.
Буын арты буын килә-китә —
Кире какмыйм, еллар, мин сезне.
Буын алмашында,
Яңарышта
Кешелекнең үлемсезлеге.

*** * ***

Бу китабым минем —
Хәтерләүләр...
Үткәнемне кабат яңарту.
Сез табарсыз анда нәфрәтен дә,
Күбрәк булыр әмма ярату.

Мин яраттым, тормыш, өзелеп сине,
Җырдагыча итеп яраттым.
Син киердең алсу җилкәннәрен
Минем изге шигъри корабның.

Бу китапның соңгы бите әле
Язылмаган...
Безнең дәвамнар
Оныкларда булыр...
Ә хәзергә —
Көнем якты,
Зәңгәр һавалар!

Гомер китабымның илле битен
Тапшырам да сезнең кулларга,
Алга атлыйм —
Иң кызыгы алда,
Язылмаган әле,
Юлларда...

*1980—1982*

## Сөяр өчен килдем дөньяга

Ак таңнардан килдем,
Тын кичләрдән...
Сөяр өчен килдем дөньяга.
Йолдызыңны эзләп тап син, егет,
Сөю утларында ян син, егет,
Дигән кебек, дәрт-дәрманнар биреп,
Якты дөнья миңа елмая.

## Назга сусау

Назга сусау —
Мөлдерәмә хисләр...
Сөю-сөелүнең сафлыгы.
Ыгы-зыгылардан арына белеп,
Онытылып яшәү шатлыгы.

Назга сусау —
Чәчкә орынып алу,
Күзләргә яшь килү ирексез,
Иркәләү һәм иркәләнә белү,
Ләззәт кичерү әйтеп биргесез.

Назга сусау —
Калтыранып торган
Бармакларның кыюсызлыгы.
Төннәрендә берсен-берсе тапкан
Җанның-тәннең тыюсызлыгы.

Назга сусау...
Яшьме-картмы дими,
Кайната ул кайнар каныңны.
Назга сусау яши кешеләрдә —
Табигатьнең изге кануны.

*1982*

## Мәхәббәтнең серле табигате

Мәхәббәтнең табигате нинди?
Бармы чиге сөелү-сөюнең?
Нәрсә соң ул җан-тән яратуы? —
Җавап биреп кара син үзең!

Бер очраклы күз карашы белән
Меңнәр арасыннан тик берне
Сайлап алып,
Үз һәм якын итү
Ник һәрвакыт бәхет китерми?

Сөю...
Сөелү...
Акыл эшемени?
Ә сөймәгән кеше
Кешемени?!

Шигыремне бүлеп,
Фәрештәдәй,
Син керәсең... —
Өнеммени,
Әллә төшеммени?

Шигъри күктән
Җиргә төшер мине!
Күкрәгеңә капланыйм да синең,
Бөтен дөньясыннан яшер мине...

Мин тоярмын шунда сөю хисен,
Миңа бәхет —

Тою синең исең...

Икәү генә белгән ләззәтләрне
Татыйк әле тизрәк, татыйк әле.

Менә шул бит үзе, үзе инде
Мәхәббәтнең серле табигате...
*1977*

## Булсын...

Су икән —
Ул ага торган булсын,
Сагышларны ала торган булсын.

Ут икән —
Ул яна торган булсын,
Җылысы озак кала торган булсын.

Ат икән —
Ул җилә торган булсын,
Йөрәк кагып килә торган булсын.

Кош икән —
Ул оча торган булсын,
Зәңгәр күкне коча торган булсын.

Яр икән —
Ул кала торган булсын,
Сагышларга сала торган булсын.

Тфү! Тфү!
Шулай диеп әйткән телем корсын!

*1978*

## Бодлер рухында

Йөрәк сыкравыннан бик талкынган,
Төксе, усал, хәлсез бер мәлдә —
Ярат мине, яме!
Ярат мине!
Юк, бәхет үк сиңа бирмәм дә...
Син бирерсең миңа көзнең шушы
Сүнеп барган шыксыз көнендә
Тик бер назлы мизгел,
Татлы мизгел,
Һәм ул калыр минем күңелдә
Мәңге... мәңге...

Шыксыз көзнең соңгы,
Ләкин тере,
Җәйне хәтерләткән нуры бул.
Син белмисең генә:
Нинди рәхәт
Синең тезләреңә орыну...
Кайнар күкрәгеңә башны куйыйм,
Ойыйм әле шунда,
Ойыйм... ойыйм...

Кайгы-сагышымны тарат, димим, —
Ярат кына, яме!
Ярат мине!

*1978*

* * *

> Күк төймәм кемдә —
> Күңелем шунда.
>
> *Татар халык мәзәгеннән*

Ак төймәм дә, күк төймәм дә
    түгелсең...
Мәхәббәтнең баш-ахырын
    кем белсен!
Мәхәббәтем ахыргача
    түгелсен.
Миңа килгән — сиңа килми
    калмас ул,
Тынычлыгың алыр, җаның
    алмас ул,
Тик шуны бел: гомер буе
    янмас ул!
Бу дөньяда һәрнәрсәнең
    башы бар:
Юл икән ул — юл өстендә
    ташы бар,
Күз икән ул — күз өстендә
    кашы бар.
Мәхәббәт — серле табышмак,
    тылсым ул;
Эзләмик башын-ахырын,
    калсын ул,
Кан кайнар чак — йөрәкләрдә
    янсын ут!
Миннән башка кеше кертмә
    уеңа,
Килче тизрәк, сарыл минем
    муенга,
Керче тизрәк, кер, бәгърем,
    куенга!

*1978*

## Бәйлә...

Бәйлә минем йөрәк яраларын,
Ясар өчен тирән,
Яңаларын...

Якты карашыңны ташла да бер,
Сөю хисләреңне... башкага бир!

Биреп кенә кара —
Син аңларсың:
Көннәрең төн булыр,
Гел таңнарсыз.

Тормышыңа, юк, кермәсен ялган...
Сөюдә тик, бәгърем, сөелеп алдан!
Мәхәббәттә алдану да татлы —
Акыл — каршы,
Йөрәк синең яклы.

Якты карашларың ягымлыдыр,
Сагындырыр алар,
Сагындырыр...

Тормыш изге һәм саф — сөйгән чакта!
Хыянәт һәм мәкер бер почмакта...

Көтә алар:
Чыгар, диеп, форсат!
Иркәм, башны ташка
Орыйк орсак,
Акса аксын яңа яралардан
Ургылып-ургылып кап-кайнар кан —
Бирмик форсат
Мәкер-ялганнарга,
Сылап-сыйпап безне
Ялганларга!

Бәйлә минем йөрәк яраларын,
Ясар өчен тирән,
Яңаларын...

*1978*

## Ела...

Елыйсыңмы бер сәбәпсез?
Ела!
Яшь кызларга елау — изге
Йола.
Елыйсыңмы сагышланып?
Ела!
Күз яшьләре сагышларны
Юа.
Елыйсыңмы яратканга?
Ела!
Мәхәббәт ул — еларлык эш:
Уйла...
Һаман әле елыйсыңмы?
Ела.
Тик барыбер эреп бетмәс
Дөнья.

Инде елама,
Берни уйлама —
Кил яныма... кил... кил...
Яшь аралаш көл... көл...

*1978*

## Вәгъдә йөзеге

Бүләк — алтын йөзегем,

Бармагыңа кигезим.
Сер-сихерен йөзекнең
Сынарсың әле үзең.

Сагышлансаң, моңайсаң,
Тоныкланыр бу йөзек.
Шатлык белән елмайсаң,
Балкып янар бу йөзек.

Йөрәк утың дөрләсә,
Утка чыдар бу йөзек.
Сөю хисен күрмәсә,
Юкка чыгар бу йөзек.

Бармагыңнан коелыр,
Көл булыр ул, таралыр.
Күңелеңдә кайгы-зар,
Үкенеч кенә калыр.

Менә шундый йөзегем
Бармагыңа кигезим.
Белдең серен йөзекнең —
Сынатма гына үзең.

*1979*

*** * ***

Исемеңне язам комга:
— Син дә, диеп — булчы монда.
Язам комга балалардай,
Шулай уйныйлар алар да.
Ышаналар ихлас, чынлап...
Ташкурчагын көйләп-җырлап
Бәү-бәү итсә бер кыз бала,
Бу уенда нәрсә яңа?
Аксиома, аксиома!
Тик... куанып бак син аңа...

Исемеңне комга язам,
Комга язам бер сүз:
**Розам...**
Кызынасың син, янәсе,
Синең белән мин янәшә...
Күзләреңне күрергә мин
Күзем йомып үреләмен.
Миннән җитез дулкын-иркә
Үрелә дә исемең сөртә...
Хәреф-хәреф ялап ала;
Роза... оза... а... а... кала.
Кала салкын, юеш ком... ком...
Белеп ялый, талый дулкын!..
Хыялларны җимереп-ватып,
Куеп китә бака кабык...

*1969*

# Май кызлары

Май кызлары килә,
Май кызлары!
Кайсылары чибәр,
Кайсылары?

Ах, сорама инде:
Йөрәгеңә
Кояш булып керә
Һәммәсе дә!
Мин, үзем дә сизми,
Аккорд алдым
Кояшлы бер сөю гаммасына.

Җырым!
Мин ыргытам сине алларына,
Чәчрәп кит тә,
Алар күтәрсен.
Кызлар белән бергә,
Кызыктырып,
Киң урамнар иңләп үтәрсең.

Май кызларың,
Казан,
Һай, кызларың!
Якты кызлар —
Шәһәр гөлләре.
Озын кышлар буе сагынам шул
Май айларын,
Шушы көннәрне.

Май башында кызлар ачылалар.
Соңдырмы бу,
Әллә иртәрәк? —
Әйтә алмыйм.
Алар исертәләр,
Яшьлекләре белән иркәләп.

Май җилендә,
Комач алсуында
Атлап килүләрен күр әле!
Каршы төшеп,
Шаян сүзләр кушып,
Ияреп китте инде йөрәгем...

Казан!
Гомер агышлары бигрәк җитез:
Язлардан соң шаулап җәй үтәр.
Ә җыр һаман-һаман чыңлап торыр,
Ул җырга соң,
Әйтче,
Ни җитәр?!

Май кызлары килә,
Май кызлары!
Безне сөяр икән
Кайсылары?

*1980*

* * *

Урамда — җәй.
Синең итәк — тездән.
Бик килешле,
Матур бу рәсем.
Ак өермә кебек бөтерелеп,
Туй уза, туй!
Әнә күрәмсең...

Ак өермә кебек ак кәләшләр,
Яздан алып кара көзгәчә
Оча гына —
Сөйгәннәре кочагына!

Синең, сеңлем, итәк тезгәчә —
Кыска әле...
Синең ак өермәң,
Кайсы җәйләр аша өлгереп,
Кайсы кышлар аша килеп җитәр?
Алдагысын, диләр, күз күрер!

Ә хәзергә
Җәй килүгә куан!
Кортлар бал җыярлар зеңгелдәп...
Синең, сеңлем,
Самими, саф күзләр, —
Ай-һай инде! —
Бигрәк зәңгәрдән...
Түтәлләрдә кыяр өлгергәндә,
Җиргә тып-тып алма тамганда,
Күзләреңә син җыярсың әле
Бәрхет зәңгәрлекне һаман да.
Ул тулышыр,
Ташып чыгар беркөн,
Зәңгәр дәрья булып түгелер...
Ак өермә урап алыр кемне?
Кайсы бәхетлене?
Кем белер?

Аһ, кирәкми!
Карамачы шулай!
Зәңгәр ялкыныңны сирпемә.
Кайгы юрамыйм бит,
Ак юл юрыйм...
Ак өермә кебек,
Син менә
Бөтерелерсең әле бу дөньяда —
Кара буран кагыла күрмәсен.

Урамда — җәй.
Синең итәк — тездән... —
Бигрәк тансык миңа бу рәсем.

*1980*

* * *

Йоклый дөнья җәй кочагында...
Тик йолдызлар сакта.

Алар мәңгелекнең сагында.
Тыныч шундый чакта.

Җәйрәп йоклый кырлар-басулар,
Йоклый күлләр-сулар...
Тынган шатлык,
Тынган ачулар —
Син дә йокла шуңар.
Томаннарга төренә иңкүлек,
Гүя ак җаймәгә.
Ак җаймәңне иңеңә элеп,
Йөрмә, аһ, җәйләрдә!
«Йокы алмый мине нишләптер
Җәйге төндә, — дисең. —
Юк, ичмасам, сердәш-иптәш тә,
Сыеныйм кемгә?» —дисең.

Томанда эреде —
Эзләмә
Кичәге көнне син.
Иртәгә кем багар күзләргә? —
Син әле белмисең.

Агыла серле нур күкләрдән
Ак шәүләң өстенә.
Тынып тор син яшьнәү-күкрәүдән...
Җәйге төн — төш кенә...

Кил әле,
Җылытыйм, таң кызы:
Салкындыр таң алды.
«Ул инде түгел, — дип, — ялгызы»,
Йолдызлар таралды.

Дөньяда син калдың,
Мин калдым —
Йөрәкләр айкалды...
Исәбен югалткан еллардан
Әнә шул җәй калды...

*1980*

## Алма кайчан кызара

Алсу алма ничек ярала?
Бу сорауга көлеп карама.

Чигү кирәк күп мәшәкатьләр:
Алсу таңнар,
Алтын шәфәкъләр,
Яңгыр биюләре,
Яшеннәр
Арасына серен яшергән
Син өзәсе алсу алма ул.
Кирәк аңа хәтта җил-давыл!

Бал кортлары җыры булмаса,
Сайрар кошлар таңда кунмаса,
Салкын чык суларын эчмәсә,

Җылы кояш нуры төшмәсә,
Кысыр калыр иде алмагач.
Аңладыңмы?
Инде аңлагач,
Синнән тора алма язмышы —
Йөрәгеңә уеп яз шуны:
Алсу алма пешә, кызара,
Өзелеп сөйсәң генә,
Кыз бала!

*1980*

* * *

Дөнья!
Тимереңнән бүген камыр ясыйм.
Төшенкелек-сагышларга
Чыгам ясин.

Коры комда коры чыбык
Күрәм икән —
Шаулап торган ямь-яшел бер
Агач итәм.

Телим икән —
Диңгезеңне яндырамын,
Тауларыңнан такыр дала
Калдырамын.

Телим икән —
Йолдыз итеп мин чәчәрмен
Сөю көткән кызларыңның
Күз яшьләрен.

Телим икән —
Суларыңа ялкын өрәм,
Ялгышлардан-язмышлардан
Аркан үрәм.

Мин убырлы карчыгыңны
Тылсым-нисез
Гүзәл кәләш итеп бирсәм —
Нәрсә дисең?

Гел игелек,
Гел изгелек чәчәм бүген,
Бар инсанга күк капусын
Ачам бүген.
Кичер, дөнья,
Җир кызының мәҗнүн колын:
Тик аңарга табынам мин,
Сәҗдә кылам.

Мин татыймын шатлыкларын,
Бәхетләрен —
Минем сөйгән һәм сөелгән
Вакытларым!

*1980*

* * *

Сокланулы яшерен карашымны
Сизгәнеңне, сеңлем, сиздермә.
Син карама миңа ачуланып,
Күзләреңне төшер тиз генә.
Шагыйрь җаны гөнаһлардан ерак,
Гүзәллеккә табына ул бары...

Сафлык-садәлеккә гимн итеп
Укыйм синең күзләр,
Кулларны...
Җилдә җилфердәгән чәчләреңне...
Укыйм йөрәгеңнең тибешен... —
Наз-иркәләү көтә бар булганың,
Үзең, ахры, әле белмисең.

Өлгергәнсең болай кем өчен?
Мин дә белмим...
Тик сокланам гына...

*1980*

## Алай булгач

— ?
— *Белмим...*

Алай булгач,
Әйтче:
Яңгыр сусап
Яфракларын сузган сиреньнәр
Тамчыларга нигә куаныша,
Пышылдашып нәрсә сөйлиләр?

Алай булгач,
Әйтче:
Сабый бала,
Уеннардан арып,
Йокыда
Татлы елмая да
Очына-очына
Ник талпына?
Кемгә кул суза?

Алай булгач,
Әйтче:
Ай-кояшлы,
Көмеш йолдызлы бу дөньяда
Күңелләрдә кайчак бер сәбәпсез
Нигә моңлы җырлар уяна?

Алай булгач,
Әйтче:
Кагылуга
Җылы бармакларым,
Нигә син,
Бөтен тәнең белән калтыранып,
Суырылып миңа киләсең?
Алай булгач,

Әйтмә:
Йом күзеңне,
Йом күзеңне —
Берни күрмәсен.
Сүзсез сусап торган иренеңнән
Бер үбәсем килә,
Үбәсем...

*1980*

## Бер очрашу

Очраклымы икән бу очрашу?
Ничә еллар ята арада...
Бер-беребезгә кем дип эндәшергә?
Һәм күзләргә ничек карарга?

Көтмәгәндә...
Көтмәгәндә микән? —
Күзләреңнән яшьрен, кыюсыз
Очкын сирпелде дә...
Юк, сүнмәде...
Ул кычкырды:
«Әллә таймыйсыз?!»

Шул очкынны күреп,
Йөрәгемнән
Тыелгысыз бер хис сикерде.
Җиде йозак,
Җиз сандыкны кинәт
Бәреп чыккан дию шикелле.

Тик икебез генә белгән серләр, —
Белгән,
Ләкин әйтә алмаган! —
Тулышты да безнең карашларда...
Түгелмәде...
Инде алардан, —
Ераклarda тынган күкрәүләрдән
Кабынмаган кебек яшеннәр, —
Ялкынланып булмас,
Булмас диеп,
Ялтырады яшьрен яшең дә...

Сорашасым килә.
Дәшә алмыйм.
Егерме ел соңга калганбыз!
Аерылышкач,
Кабат аймылышкач,
Без аңларбыз әле,
Аңларбыз...

Ә хәзергә күзләр сөйләшсеннәр.
Көтелмәгән көткән мизгел бу.
Безнең мизгел!
Сафлык белән изге,
Якты сагыш белән изге бу.

Әйтелмәгән шушы якынлыкны,
Күңелләрдә йөрткән җылыны

Сүрелдермик...
«Кабат очрашканчы!
Йә, хуш!» — диеп сузам кулымны.

*1980*

## Хатка язмас бер сүз

«Хат язмыйсың, — дисең. —
Хатка саран!»

Бер язармын әле,
Язармын.
Мәңге бетмәс озын хатымның син
Табалмассың очын-азагын.

Син укыган юлларында булмас
Каным сине көткән минутлар.
Булмас анда син урлаган җаем...
Күзгә кергәч,
Яктым мин утлар.

Шул утларга салдым
(Суга түгел!)
Синең күзләреңнең елтырын...

«Диңгез кибеп,
Таулар җимерелсә...» — дип,
Син укыган идең бер ырым
Шул җаеңдә.

Ырым очты утка!

Таулар исән,
Диңгез кипмәде...

Ләкин мине синең кебек усал
Беркем
Берчак ташлап китмәде.
Ә син киттең кара күңелең белән,
Йөрәк хәзер җансыз чүл төсле.
Мин сусадым сиңа хат язарга,
Каләмемә язар сүз төште,
Бары бер сүз!
Язмыйм —
Сүз көчле!
Мин кызганам сине!

*1980*

## * * *

Ак күгәрченмени! —
Ике кулың
Очып йөри кызың тирәли.
Шулкадәрле булса булыр икән —
Коеп куйган үзең:
Күр әле!

Шул нәни кыз —
Үтеп булмас кыя...
Йөрәк тибешләрен тойсак та,
Ак күгәрчен кебек ике кулың,
Юк,
Сарылмас минем кочакка.

Онытмадым кулларыңның телен:
Алар,
Чәчләремнән иркәләп,
Сөйли иде уртак сер-хисләрне...
Куанганбыз икән иртәрәк...

Ак күгәрчен кебек кулларыңны
Болгадың да:
— Хуш! — дип беркөнне,
Очып киттең...
Нигә бүген әле
Югалган моң кабат бөркелде?

Күңелемдә — өмет,
Сүнми яши:
Якты дөньяларда мин барын
Онытмаслар төсле,
Онытмаслар
Ак күгәрчен кебек кулларың.

*1980*

## Кабан буйларында көзге җил

Кабан буйларында көзге җил...
Җил дәштеме әллә:
«Кил, — дип, — кил!»

Көзге тополь гүя карачкы...
Күзләремә туры карачы.

Очраклымы безнең очрашу?
Көзге җилләр яфрак очыра шул...

Хыялларда калган хисләргә
Көзге җилдә,
Әйтче,
Нишләргә?

Ятим тора салкын утыргыч...
Нәрсә әйтим,
Күңел буш булгач?..

Юк,
Кирәкми инде,
Карама:
Ялган кертмик ике арага.

Кабан буйларында көзге җил...
Җилләр ялгыш дәшкән:
«Кил, — дип, — кил!..»

*1982*

## Яшем — утлы яшен

«Инде хәзер нинди мәхәббәт ди?!
Яшең җитеп бара...»
Әйе,
        яшем —
              гүя яшен! — сискәндерә дә ул,
                    куркыта...
Куркыта
        хисләр суыну түгел,
тәҗрибә — бар,
        җегәр юклык түгел,
куркыта —
        ни хикмәт! —
        хисләрнең җетеләнә баруы,
              һаман ташуы,
                    шашуым...
Күрәсең, куркыта
        яшисе гомернең
              яшәлгәненнән күпкә азлыгы,
                    күпкә...
Ашыктыра:
        өлгерергә кирәк,
              өлгерергә!
Яшьлектә сөймәгәннәрне сөяргә,
        саранланмый иркәләргә-назларга,
назландырмый гына назланырга,
алырга мөмкин булганның
        барын алырга,
              алып калырга...
Бирергә мөмкин булганның,
        тамчысын да калдырмыйча,
              бирергә...
              өлгерергә!
Әйе,
        яшем —
              утлы яшен! —
Сискәндерә,
        һәр чатнавы куркыта:
              булмагае, димен,
                    соңгы кат...

*1987*

## Мизгел

Бәхет һәрчак тик бер мизгел була,
Бәхет мизгелләре бик тиз уза.
Ә кайгылы мизгел буламы?
Әллә сузыламы кайгы
        айлар,
              еллар?..
Әвереләме аннан язмышка?..
Тормыш тукып тора —
        әйтерсең лә укытучы апа! —
              ялгышма...
                 ялгышма...
                    ялгышма...
Бу тукулар ай-һай нык туйдыра!
Тыңламыйбыз барыбер:

абынабыз тагын ялгышка
һәм сылтыйбыз аны язмышка.
Абынулардан җаннар канаса да,
яшәү —
бер бәхетле мизгел!
татлы авыртынулы мизгел...

*1987*

## Баркарола

Алтын шәфәкъ иңә...
Әйтерсең лә
Яңа бер җыр керә күңелемә.
Алтынланып Идел-су тирбәлә
Гүя йоклата ул сине менә
Тирбәлдереп кенә,
Төнге гөлем...

Комлы ярга кургаш дулкын кага...
Җәелә төн җиргә,
Төн дөм кара...
Идел җылы, тигез сулыш ала —
Синең сулышың да йоклаганда
Шулай җылы була,
Төнге гөлем...

Кай саксызы төн тынлыгын ваткан?
Сискәндергеч бер өн-аваз килә
Кинәт кенә шунда аргы яктан —
Төшләндең дә син сискәндең гүя,
Нигә икән, нигә,
Төнге гөлем?..

Кирәкмәгән шөбһә-шомнарымны
Юып ала Идел томанымы,
Әллә айның көмеш нурларымы?
Сак йокыңны саклап торганымны
Күзли йолдызлармы,
Төнге гөлем?..

Таң йолдызы —
Чулпан йолдыз яна...
Әкрен генә офык алсулана...
«Аерылабыз...» — диеп моңсуланма,
Таң йокыңны бүлмә,
Төнге гөлем...

Син татлы бер төш күрерлек кенә,
Йөзеңнән нур бөркелерлек кенә,
Куенымда бер эрерлек кенә,
Бер мизгеле бер гомерлек кенә
Вакытың бар әле,
Төнге гөлем...

*1986*

## Сөяр өчен килдем дөньяга

Мин таңнардан килдем.
Шул таңнарда
Каеннардан төшкән аклыклар...
Бардыр мин эчәсе каен суы,
Бардыр талчыбыктай таң сылуы,
Мин сөясе, иркәлисе ярдыр...
Бардыр әле татлы шатлыклар...

Мин кичләрдән килдем.
Кичләрендә
Салкын сулы сиртмә коега
Кызлар су алырга киләләр дә,
Егет куенына керәләр дә,
Эри алар — сөю җилләрендә
Коеларга йолдыз коела...

Ал таңнардан килдем,
Тын кичләрдән...
Сөяр өчен килдем дөньяга.
Йолдызыңны эзләп тап син, егет,
Сөю утларында ян син, егет,
Дигән кебек, дәрт-дәрманнар биреп,
Якты дөнья миңа елмая.

## Өч экспромт

*** * ***

Үз итмәдең мине,
Яратмадың...
Ә мин барыбер сине яраттым!
Әйтче,
Яратканнар,
Син дип җан атканнар
Йөрәген син ничә канаттың?..

*1973*

*** * ***

Бу кичеңне син миңа бирче,
Көттермичә яныма килче,
Кайнарланып куенга керче —
Бүген безнең хушлашу киче...
Килче!

*1978*

*** * ***

Яшерен теләк, өмет белән:
«Кавышам, — дип, — егет белән!» —
Үзалдына япа-ялгыз
Елмаючы бәхетле кыз
Кич уенга җыенгандай —
Балкый күктә тулышкан ай!

*1984*

* * *

Әй, егет чак,
Гыйшык тоткан вакыт!
Искә төшерәм дә елмаям:
Тәмле телләр,
Яхшы кыланышлар
Табылып тора иде ул каян?

Кайнарланып сөйли һәрбер гашыйк,
(Әйләндерә диген кем телен?)
«Ефәкләргә генә төрермен дә
Кулларымда гына йөртермен...»

Үзе дә бит ышанып, нык инанып
Сөйли менә шундый сүзләрне.
Өйләнгәндә уйлый:
«Эләктердем
Дөньяда тиң чыкмас гүзәлне».

Әй, егетләр,
Кулларыңда йөртү
Гүзәл ярны —
Ул бит шаяру.
Сөюеңне түкми-чәчми генә
Еллар аша илтү —
Һай, авыр!

*1965*

# Моңсу көзем

*(Шигъри бәйләм)*

* * *

Язы үтте,
Җәе үтте,
Көз дә үтә...

Кошлар китә инде,
Кошлар китә...

Кышлар җитә...
Күңелемнән сызып, сызлап,
Иңрәп үтә
Моңсу бер хис:
— Бирештең ич!

Яз, җәй, көз, кыш
Чукып тора йөрәгемне тик ике кош:
Берсе — өмет,
Берсе — сагыш...
Яшел өмет.
Сары сагыш...

Яшел өмет:
— Түзик әле, көтик әле —
Кыш китерер, бәлки, безгә ак бәхетләр.
(Өметләнү — ах, рәхәт лә!)

Сары сагыш:
— ...
Нәрсә әйтсен сары сагыш?
Күзгә бары яшь китерә...
Менә шулай мине һаман интектерә
Шул ике кош...
Яз, җәй, көз, кыш...

Язы үтте,
Җәе үтте,
Көзе үтә...

Кошлар китә инде,
Кошлар китә...

Кышлар җитә...

* * *

Шәмәхә төн.
Җылы август төне.
Күктә гүли Киек Каз Юлы.
Күк —
Галәмнең сихри бер кисәге,
Сер яшергән алтын язулы.

Шәмәхә төн.
Тып-тын йолдыз тама.
Җиргә тып-тып алма коела.
Алма исләреннән исерсәң дә,
Оемачы, күңел, оема!

Шәмәхә төн, бәлки, мәңгелектер,
Җирдә аны бик тиз ваталар;
Август төне шартлап ярылып китә —
Ерак күлдә үрдәк аталар.

Йолдыз тама...

Тып-тып алма коела...
Кош егыла төпсез упкынга...
Атылган кош төсле егылырмын
Шул упкынга...
Бәгърем, юксынма.

Шәмәхә төн,
Август төне булыр,
Күктә гүләр Киек Каз Юлы...
Син юксынма,
Син укырга тырыш
Сер яшергән алтын язуны.

Әйтелмәгән, бары төсмерләнгән
Минем хисләр, минем тойгылар
Бу дөньяга сыеп бетмәделәр —
Күккә чәчрәп,
Йолдыз уйдылар...

Кулыңны суз —

Әнә йолдыз тама.
Син курыкма:
Мин бит янәшә...
Җирдә — алма исе...
Ә төн шәмәхә...

＊＊＊

Тупылларда көзге яфрак яна —
Яныйм мәллә, диеп тукталырсың.
Көзгә кергән сөю бер дөрләр дә
Гөлтләп сүнәр,
Син калырсың...
Сөю сүнәр,
Ә син калырсың.

Моңсу күктән тезелеп кошлар оча —
Очалмадым, диеп офтанырсың.
Хәтеремнән күпләр очып үтәр,
Эзсез үтәр,
Син калырсың...
Сөю сүнәр,
Ә син калырсың.

Дулкын кага-кага Идел ага —
Иделкәем! диеп сокланырсың.
Ияреп агалмассың,
Кайчан да бер
Идел кибәр,
Син калырсың...
Сөю сүнәр,
Ә син калырсың.

Күңелеңдә бер җыр чыңлап торыр —
Аның җыры... диеп моңланырсың.
Җырлый-җырлый күпме юанырсың,
Җыр онытылыр,
Син калырсың...
Сөю сүнәр,
Ә син калырсың.

＊＊＊

Яңгырлы җәй,
Йә, нәрсә соң инде,
Хушлашырга булгач, хушлашыйк!
Күңелләрдә озак яна торган
Сары ялкыннарга хут ачыйк.

Офыкларда кургаш-кургаш болыт...
Аерылуның сагыш-кайгысын
Канатына алып кошлар китә...
Нинди юллар көтә кайсысын?

Чияләрнең ап-ак күбекләнеп
Кайнап торган чагы, ямьле яз,
Чыклы болыннарның дымсулыгы,
Йөгерек җилдәй җиңел синең наз...

Ул бәхетле илгә кайтулар юк!

Буразнадай җыерчыкларның,
Берәм-берәм сыйпап һәркайсысын,
Мәгънәләрен җыяр чакларың.

Кайтулар юк...
Җилдә көрсенәләр,
Алма коя-коя, бакчалар...
Күргән-кичергәннәр өлгергәннәр
Әче җимеш булып, баксана!

Җәй-көзләргә посып сиздермичә
Килә икән суыну-салкыннар.
Тәрәзәгә һаман яңгыр кага...
Ә күңелдә — сары ялкыннар.

*** * ***

Янә салкын, шыксыз, шомлы
төн килде,
Ялгызлыгым белән тәңгәл,
тиң килде.
Йомшак урын, ак җәймәләр
өстендә, —
Гүя судан алган балык
төсле лә! —
Бәргәләндем, боргаландым,
әйләндем...
Ай үттеме, ел үттеме? —
Әйтәлмим.
А, ниһаять, балкып көләч
көн туды!
Битләремә җылы, йомшак
нур кунды.
Назлы җил сарылды иңгә
иркәләп.
Шатлык тоеп тетрәнде җан
иртәрәк...
Син түгел бит, син түгел бит,
ах! түгел!
Ник соң шулай җанга якын,
ах! бу көн!

*** * ***

Тетрәндерде мине,
Тетрәндерде
Хыянәтчел хәтәр авыру...
Кәбисә ел, ай-һай, усал кисә:
Сынауларның иң-иң авырын
Быел бирде миңа,
Өеп бирде!
Зәхмәтеңне тизрәк алсаңчы,
Кәбисә ел,
Әфсен укып кына
Иделләргә илтеп салсаңчы!
Төннәрендә үз-үземне тыңлыйм.
Санап ятам йөрәк типкәнен.
Белмибез лә икән исән чакта
Яшәү дигәннәрнең ник тәмен?!

Тыңлап ятам...
Йөрәк тигез тибә...
Юк, канәгать түгел үземнән:
Чөнки инде күңел-оркестрның
Иң кирәкле кылы өзелгән...
Бары бер кыл!
Һәм уйнамый күңел...

* * *

Бакча буйлап торна торык кызлар
Пырхылдашып йөгереп үткәндә,
Кинәт кенә моңсу тавыш телде
Тирә-юньне зәңгәр күкләрдән:
— Тор-рыйк... Тор-рыйк...
Кызлар, тынып калып,
Күзәттеләр торна кәрванын.
Әйтерсең лә якты хыяллары
Торналардай очып барганын,
Үзләренең җирдә калганын
Сизенде дә сизгер күңелләре,
Көрсенделәр кызлар тын гына...
— Тор-рыйк... Тор-рыйк... —
Торна тавышлары
Эреп тынды...
Калды моң гына...
Ә бакчада чыпчык чыркылдаша!
Чыпчык китми,
Чыпчык гел янда.
Янда булгач — бер дә кадере юк:
Нәрсә җитми икән бу җанга?
— Тор-рыйк... Тор-рыйк... —
Моңсу ул тавышлар
Ник күңелне тырнап торалар?
Юксындыра, ымсындыра нигә
Һавадагы ерак торналар?..

*1976*

* * *

*Розага*

Үпкәләмә.
Кыз чакларың түгел.
Сүреләдер матурлыгың да...
Йөрәгемә иртә кергән идең,
Соңлап урын таптың җырымда.

Булды вакыт:
Сыеша алмый, ташып,
Кага идең кайнар күкрәгем.
Чайпалдырмадым да,
Түкмәдем дә —
Барыбер сине җырга кертмәдем.

Күңел — комсыз,
Йөрәк көнчел булды:
Яшереп килдем кеше күзеннән.
Аз идеме гыйшкын җырлаучылар,
Җырлап бетермичә өзелгән?!

Җырга исереп күпләр онытылды.
Ә син идең һаман моң гына.
Шауламадың,
Урын дауламадың,
Үз урыныңны белдең тын гына.

Син һәрвакыт янда,
Янәшәдә,
Әйтерсең лә минем күләгәм.
Сиздермәдең...
Ләкин ул җырлардан
Йөрәгең көнләгәндер, көнләгән!

Кил әле, кил!
Йомшак башмаклардан,
Кухня исе сеңгән халаттан
Булсаң ни соң?
Сине җырлыйм әле,
Тарсынмыйча гына халыктан.

Җырлыйм әле...
Сине һәрчак янда,
Янәшәмдә кебек хис итеп:
Казаннардан килеп җитмәссеңме,
Соңлап туган җырым ишетеп...

*1973*

* * *

— Сим-сим, ач ишекне! —
Бер ваемсыз,
Бер риясыз авыл баласы, —
Юри генә мин шакыган идем
Ишегеңне, Казан каласы.
Ачылды да куйды! Кердем киттем...
Таш урамнар булды лабиринт.
Әйттең, ахры, кала:
«Бу балага
Ягын онытырлык яр бирик!»
Серле идең, кала, сихри идең...
Туып килә иде алсу таң...
Пәйда булды гүзәл яр дигәнең,
Шык-шык атлап шыксыз асфальттан.
Аны тапкан асфальт урамнарда
Мин ваз кичтем болын-кырлардан,
Онытылды сиртмә коеларым,
Сулар эчтем колонкалардан.
Казанда да тополь мамык коя,
Кыркып торсалар да башларын.
Җирсүемне җилгә очырдым шул,
Сагышымны кыркып ташладым.
Авыл алачыгы.
Анда — чаңнар...
Йотылдылар оркестрларда.
Эх!
Кайтарып кабат шул елларны
Сандалларга салып сугарга!
Инде хәзер күпме шакысам да:

— Сим-сим, ач! — дип, серле ишекне,
Әкият онытылган...
Тылсым үткән...
Таш лабиринт...
Беркем ишетми...

* * *

Дәһшәтле сугыш еллары.
Син сабыйга табигать
Әйткәндер: «И бала, бала...
Нинди көчләр табыйм, әйт!
Еракларда — утлы сөрем,
Бирердә — явым болыт.
Җылытырга, яратырга
Калганмы ягымлылык?
Бар булган матурлыгымны,
Сафлыгымны ал, әйдә!
Бер сабыйга төкәнерлек
Бардыр әле алай да.
Сугыш ялмап бетергәнче,
Сиңа бирим, кыз бала.
Кыз бала бит — булыр ана,
Анадан кем кызгана?
Сугышны үтереп үлә
Еракта этиләрең.
Уллары ятим булмасын
Синең күк ятимнәрнең.
Үс кенә, әйдә, авыз ит
Балтырганнан, юадан...
Баһадир егетләр итеп
Кайтарырсың яңадан».

*1973*

* * *

Меңнәр арасыннан табышырга
Юкса инде кем кушкан безгә?
Юл читендә зәгыйфь учак күреп,
Тик очраклы очрашканбыз да —
Күзләр ял сораган.
Туктаганбыз
Һәм әйткәнбез:
— Дөнья, бар, йөгер.
Без калабыз әле.
Икәү булгач,
Бер мизгелең безгә бер гомер.

Дөнья агышында кинәт шулай
Туры килгән безнең тукталыш.
Кирәк булган безгә
Күздән күзгә
Сүнмәс-сүрелмәслек ут салыш.
Сүнмәс-сүрелмәслек уртак учак.
Уртак табын...
Ләкин мин беләм,
Дөнья өчен мизгел бер гомердә
Күзләреңнән туеп өлгермәм.
Бер-беребезгә салган ике уттан
Өченче ут инде кабынган.

Өченче ут...
Ул яңаны көтә...

Кузгалырбыз, ахры, табыннан...
Башка мизгел.
Башка күзләр өчен.
Ә без дөнья әйләнешендә
Яңа юлга инде җыенабыз...
Ут калдырып алар өчен дә.

*1971*

## Янсын җанын, янсын

Янсын җаның,
Җылыт дөньяларын...
Көне килер —
Төн бер суыныр...
Тамчысына кадәр йотлыгып эч:
Һәр мизгелең —
Хәят суыдыр.

## **Килдем...**

Кайдан килдегез сез безгә,
Батмаенча диңгезгә?

*Татар халык җыры*

Минзәләдән килдем.
Минзәләдә
Ак күбеккә баткан чияләр,
Ботакларын җиргә кадәр иеп:
«Бер кайтырсың.
Танымабыз...» — диеп,
Шаулап калды...
Кызлар-гүзәлләр дә танымаслар,
Борын чөярләр!

Ык буеннан килдем.
Ык буенда
Калды мин чуммаган чоңгыллар...
Калды төнбоеклар,
Бер төш булып...
Калды мин яраткан сары комлык:
«Нәрсә икән, бала, һәй, уеңда?..» —
Дигән төсле,
Моңга чумды да.

Урманнардан килдем.
Урманнарда
Мин эзләгән зелпе тамыры,
Мин кисәсе чабаталык юкә, —
Азга түгел,
Гомерлеккә...
Күпкә —
Эреде дә зәңгәр томаннарда,

Балачакны җуеп калдырды.

Болыннардан килдем.
Болыннарда
Мин өзәсе юа, балтырган,
Мин кабасы сусыл алсу җиләк,
Мин иснисе чәчәк,
Нидер көйләп,
Хыял-теләкләрне күп елларга
Чит күзләрдән саклап калдырган.

Мин таңнардан килдем.
Шул таңнарда
Каеннардан төшкән аклыклар...
Калды мин эчәсе каен суы,
Калды талчыбыктай таң сылуы,
Үбелмичә калды... —
Соң аңларга! —
Кичерелмичә калды шатлыклар...

Мин кичләрдән килдем.
Кичләрендә
Салкын сулы сиртмә коега
Кызлар су алырга киләләр дә,
Егет куенына керәләр дә,
Эреп бетә...
Сөю җилләрендә
Шул коега йолдыз коела...

Килдем Минзәләдән.
Ык буеннан,
Урманнардан,
Яшел болыннан...
Ал таңнардан килдем.
Тын кичләрдән...
Авылдагы олы-кечеләрдән,
Күрше-күлән,
Кардәш-ырудан
Хәер-фатихалар алып килдем...

Ярты җаным шунда калды минем!
Шунда калды...
Тагын сезгә нәрсә әйтим инде?!
*1981*

## Көз

Җәй буена арган бакча
Калган тынып,
Соңгы гөлләр утыралар
Уйга чумып.
Агачларга кунган инде
Сары кошлар;
Алары да очып китәр,
Калмас кышка.
Сирәкләнә кояшның да
Елмаюы;
Дымлы челтәр бәйли болыт
Айлар буе.
Майланган таба шикелле
Асфальт буйлап

Җил йөгерә, яңгыр белән
Качыш уйнап.
Киң Иделнең комлыклары
Ята тып-тын:
Салкын ярны ялап үтә
Кургаш дулкын,
Һәрнәрсәдә талгынлык бар,
Авырлык бар.
Олыгайган, акыл кергән
Сабырлык бар.
Көзнең шундый вакытында
Җир көчле ул,
Яшьлек дәртен баса төшкән
Ир төсле ул.

*1960*

# Урам. Гади якшәмбе

Урам көлә,
Урам бәйрәм итә —
Туй-фәләнме,
Кунак дәшкәнме?
Урам гөрли,
Җырлый...
Ә урамда
Гап-гади бер җәйге якшәмбе.
Урам сузылып яткан.
Кешеләрне
Йөртә тыз-быз,
Такси йөгертә.
Егетләрдән кызлар күзләтә ул.
Әй син, урам!
Әле бик иртә...
Иртә шаярасың:
Туганыңа,
Исем алганыңа ай да юк.
Әнә әле яңа йортларыңа
Һаман күченәләр...
Ял да юк.
Кара, урам:
Менә бу кыз синдә
Беренче кат сөю кичерер;
Шатлыклары булыр,
Кайгылары...
Көтеп алыр һәрбер кичеңне.
Ә бу картны менә яңа йорттан
Озатырсың соңгы йортына...
Пенсионер ул.
Юк, моңайма, урам!
Нишлисең бит,
Кеше бер тына...
Пенсионер китәр —
Күкрәгеңә
Яңа эзләр салыр ир бала.
Егылып алыр...
Ә син юат аны:
«Егет кеше бит син, елама!»
Бала тавышы —

Тормыш тантанасы.
Тыңлыйм аны, тыңлыйм,
Сокланам.
Хәтеремдә исә башка урам,
Башка бала йөзе саклана...
Кешеләргә ишеттерми генә
Елый иде урам сулкылдап...
Бала чагым шунда югалттым мин,
Сигез яшьлек сабый,
Шул елда...
Бер ураммы?
Ул көн миллион урам
Күз яшенә төелеп елады.
Ә син, урам, күрмә, күрә күрмә
Төшеңдә дә андый елларны.
Көлеп яшә,
Әмма бер датаны
Һич онытма, урам, яшьтән бел:
Мең тугыз йөз кырык беренче ел.
Егерме икенче июнь.
Якшәмбе.

*1964*

## Литавралар елый...

Литавралар чыңлап ыңгыраша —
Кемнең икән соңгы юлкае?
Литавралар елый,
Литавралар...
Җир өстенә җәелә зур кайгы.
Машинада,
Комач арасында —
Миңа таныш түгел ветеран.
Таныш түгел...
Ник соң китә алмыйм?
Юл чатында һаман ник торам?
Үлем-мәкер,
Кемгә килсә дә шул,
Кыргыйлыгы белән куркыныч.
Ә ветеран гүя әйтә кебек:
— Юк, куркыныч түгел, бул тыныч.
Гомер буе кешеләргә биреп
Мәхәббәтен, тормыш җылысын,
Яшәгән ул...
Литавралар елый —
Йөрәк елый...
Әйдә, еласын!..
Кайнар яшьтә кайгы эреп бетсен —
Соңгы юлга китә ветеран.
Җирнең авырлыгын иңгә алып,
Аның урынында мин торам.
Тыныч йокла, тыныч, ветеран...

*1964*

## Без ике ир

Без,

Шатланышып, бераз шүрләп,
Мәктәп бусагасын атлап кердек.
Ике бөртек,
Түгел ике бөркет.
Ике бөркет түгел,
Ике бөртек.

Без,
Кыяр урлап тотылганда,
Талчыбыкның татлы тәмен белдек.
Ике өтек,
Түгел ике бөртек.
Ике бөртек түгел,
Ике өтек.

Без,
Юк мыекны кыра-кыра,
Янып-көеп кызлар сөеп йөрдек.
Ике бөркет,
Түгел ике бөртек.
Ике бөртек түгел,
Ике бөркет.

Без...
Вакыт җитте: йөрәкне дә,
Хезмәтне дә туган илгә бирик.
Ике ир бит,
Түгел ике бөртек.
Ике бөртек түгел,
Ике ир бит.
Әйтсен Ватан:
«Ышанычлы ике ир!» — дип.

*1964*

## Дворник карт белән малай

Карлар ява...
Карлар эри...
Дворник карт сулар ера,
Карлар көри,
Сакалында көмеш арта,
Һич эреми,
Еллар эзен эретерлек
Көч күренми.

Еллар килә...
Еллар китә...
Карлар кебек эри еллар,
Эри гомер —
Дворникка исәп-хисап
Көне килер:
Якты дөнья алдында ул
Җавап бирер.

Җавабы бар —
Җавабы юк:
Барысын да тота алмый,
Эри хәтер.

Дворник карт бер нәрсәне
Ачык әйтер:
— Гомер буе кундырмадым
Күңелгә кер.

Гомер озын —
Гомер кыска,
Әйтерсең лә ярылып ята
Эзләр карда.
Бүген булса, иртәгә юк —
Эри бар да...
Җирдән чыгып, керә кеше
Шул Җир-шарга.
Малай көлә...
Малай көлми...
Дворникның күршесе ул,
Сабый әле.
Тормыш аңа карлы юллар
Салмый әле.
Күп күрсә дә, күпне аңлый
Алмый әле.

Күпне күрә...
Күпне күрми...
Малай көн дә бер уенны
Уйнап йөри.
Кар ташый ул чана белән.
Карлар эри...
Дворник карт соңгы тапкыр
Карлар көри.

Эзләр кала...
Эзләр бетә...
Шул сабыйның чанасында, —
Сизми үзе, —
Дворникның олтан салган
Итек эзе
Гүя менә бу дөньяның
Ике күзе...

*1964*

## Үз-үземне юату

Төкерәм мин,
Күңелсез уйлар,
Сезгә!
Вакыт җиткәч,
Барыбер китәрсез лә...
Мин просто бераз гына
Арганмын:
Йөге авыр тормыш дигән
Арбаның.
Кайчагында кирәк туктап
Тын алу.
Күпкә китә юкса
Рухи туналу.
Суыту кирәк
Кызган йөрәк моторын,

Истә тотып
Алга шәбрәк тартырын.
Менә минем
Бүген шундый көнем лә!
Юньсез уйлар,
Сез мәңгелек түгел лә!
Бүген, ярар,
Чуалыгыз томанда.
Сез үләрсез
Иртәгә көн туганда.
Ярдәм итмәс
Төшенкелек алласы —
Сытар сезне
Эшчән тормыш арбасы!

*1964*

* * *

Кояш кебек балкый, диләр,
Көләч булса, кешегә дә.
Ә бит кояш бик еш кына
Яндыра да, пешерә дә.
Тик барыбер борынгыдан
Табынганнар шул ут-шарга.
Гашыйклар да тартынмаган
Сөйгәненә:
— Кояшым! — дип сүз кушарга.
Гөрләвекләр йөгерешендә
Уйнакласа кояш язын,
Җәен чәчәк чыкларында
Тирбәлә ул, биреп назын.
Көзен җиләк-җимешләрдә
Алсулана, уттай яна.
Салават күпере төсенә
Кышын боз тәрәзне мана.
Кояш белән бергә торам,
Юлга чыксам —
Баш түбәмдә.
Нурларыннан илһам алып
Күтәреләм
Зәңгәрлеккә мин түбәннән.
Юк, кояшсыз тормыш бармый,
Көн туа алмый, яшәрми җир.
Үлсәм дә мин,
Үлән булып сузылырмын:
— Ах, кояш! — дип дәшәрмен бер.

*1966*

# Кызлар бәрәңге ала

Сабан ярып киткән кыр күкрәген,
Җир күлмәге чуар төсендә:
Алсу-кызыл тәнле бәрәңгеләр
Тәгәрәшеп ята өстендә.
Тыгыз тәнле кызыл бәрәңгеләр
Хәтерләтә миңа кызларны.
Басу тутырып көлгән чибәрләрдә

Бер җыерчык, берәр эз бармы?
Алсу-кызыл тәнле бәрәңгеләр
Чиләкләрдән коела дыңгырдап...
Эшләп йөри кызлар-чыркылдыклар,
Машинага кушылып, җыр җырлап.
Ә бәрәңге уңса уңар икән —
Күренми дә хәтта буразна.
Авыл карты кызыгып карап тора
Бәрәңгегә түгел... кызларга!

*1966*

## Башка юк

Хәтерлимен әле әниемнең
Сөялләнгән каты кулларын.
Җир шикелле каты...
Әмма белмим
Алардан да йомшак кул барын.
Ул куллар бит мамык мендәр иде,
Йоклаганда арып,
Баш куеп.
Үзе йомшак,
Үзе кырыс,
Каты
Ил кулы бар тагын —
Башка юк...

*1966*

## Соңлый язган тәүбә

Кояш таплы, ай таплы дип
Җырлауларым җитәрлек.
Юләрлек —
Кояшларның һәм айларның
Булмый исен китәреп.

Соң булса да, уң булсын, дип
Тәүбә бирдем: җырламам
Яңадан...
Мәңге бетмәс таплар булмас,
Бетәр әле берзаман.

Күккә карасаң күк биек...
Җәйрәп ята Җир-анам —
Кызганам.
Җир тапларын юар өчен
Җиңнәремне сызганам!

*1967*

## Шагыйрь монологы

Күңелем пакь,
Кулым,
Буялса да,
Язу карасына буяла.
Максатларым ачык:
Хакны сөйләү,

Хаклык аша карыйм дөньяга.

Пегастырмы —
Канатлы аттырмы —
Шагыйрьләрнең илһам юлдашы? —
Укып беләм,
Ләкин күргәнем юк...
Мин шигырьдә
Үзем эш аты.

Кирәк түгел,
Мине данламагыз —
Мин шигырьнең кара эшчесе.
Дан дауламый гына чорлар кичкән
Тыйнак Кол Галиләр төслесе!

Тукай,
Такташ,
Җәлил —
Остазларым,
Яшь ягыннан эне булса да.
Ике урталыкта
Үлем белән
Үлемсезлек дигән бусага.

Юк,
Сорамыйм һич тә үлемсезлек,
Булдыралган кадәр җырлыймын.
Кырыс шагыйрь дигән исем алдым —
Җырладым бит кырыс чорны мин.

Сандугачлар,
Айлы төннәр икән:
«Иске тема, — дибез, —
Ялган бу!»
Иске темалар юк,
Мәңгелек бар...
Аңа кирәк яңа ялгану.

Һәр чорның да үзенең шагыйрьләре —
Яңа җимеш шигъри агачта.
Затлылары аерылып тора
Бер кәрзингә өзеп салгач та.
Мин,
Үземчә,
Алтын сүзләр коям!
Тик банкка аны салмыйлар.
Бик салырлар иде,
Финансистлар
Сүз бәһасен аңлый алмыйлар.

Сүз бәһасе...
Ул шигырьдә арта —
Сез түләгез аңа бермә-бер!
Асыл шагыйрь һәрчак бербөтен ул:
Сүзе,
Үзе —
Барысы бергәдер.

Минем эш сәгатем чикләнмәгән,
График төзеп булмый хисләргә.
Кешеләрнең кайгы-шатлыкларын
Мөмкинме соң инде чикләргә?

Минем ял вакытым кайчан, димсез?
Ял вакытым —
Шигырь язылса,
Шул шигырьдән бик канәгать калып,
Күңелемдә кояш,
Яз булса.

Ә канәгать шагыйрь буламыни?!
Димәк,
Димәк...
Ә менә бәйрәмгә,
Бәйрәмнәргә бай мин:
Һәр шигъри юл
Олы бәйрәмемә әйләнә.
Күңел бәйрәмемә бүләк була,
Тыңлаучысын тапса җырларым,
Тойсам шунда яңа илһамлану,
Күңелемдә яңа җыр барын.

Кайчак дәшми күңел,
Ул бикләнә,
Ят күзләрдән кача эчкәрәк,
Ә ят күзләр,
Симез һәм тук йөзләр
Тормый алар бер дә нечкәләп.

Юк,
Артыгын бер дә сорамыйм мин —
Бары күңелемә тимәгез,
Мин шигырьдә эшче.
Эш хакымны
Тик ярату белән түләгез.

*1982*

# Дирижер Алмазга

Ап-ак түше балкып-балкып китә,
Әйтерсең лә кара карлыгач.
Син киләсең аңа буйсынырга,
Көнлек мәшәкатьтән арынгач.
Күңелеңне ияртеп алып китә
Үзе генә белгән моңнарга.
Дөнья үзе бер мизгелгә тынып
Калыр төсле аны тыңларга.
Кул-канаты тынган зал өстендә —
Гүя менә галәм өстендә, —
Уйнаклый да оча...
Куллар хаким
Хыялыңа синең,
Хисеңә.
Күтәрелә,
Күтәрелә моңнар
Һәм сине дә бергә күтәрә

Ваклыклардан,
Ыгы-зыгылардан,
Биеккәрәк —
Рухи күкләргә.
Алып керә кара урманнарга,
Адаштыра кышкы буранда,
Наз бөрки дә гашыйк булганнарга,
Йолдыз чөя ялгыз урамга.
Күкрәп уза бәхет яңгырлары...
Соңгы аккорд —
        канат-кул —
                яшен...
Дөнья тына...
Иркен зал яктыра...
Син сөртәсең ашыгып күз яшең.

*1984*

## Жанымны як

«Кош кына да — өч йөз елны яши!
Ник табигать бездән кызганган?
Гомер кыска...» — диеп офтанасың,
Көнләшәсең һаман козгыннан.
Офтанма син!
Яшьтәмени хикмәт?
Туган көннән алып үлемгә
Еллар санау —
Бары бер шартлылык.
Гомер озынлыгын кем белгән?!
Көннәр-айлар,
Еллар-гасырларга
Салып үлчәмик лә без аны —
Ялыктыргыч озын гомерләр дә
Барыбер мәңгелекнең тузаны.
Бик күп сыя гомер бизмәненә,
Яши белсәң янып-яктырып;
Бер гөнаһың өчен вөждан сине
Тотып ярса,
Мең кат яткырып;
Чит җирләрдән кайтып егыла алсаң,
Елый алсаң туган нигездә;
Икәү бергә эри алсаң әгәр
Татлы...
        татлы...
                татлы мизгелдә...
Яшәү тәме —
Хисләр чиксезлеге.
Югалтулар булсын,
Табышлар...
Онытылмас кыска куанычлар,
Онытылырлык озын сагышлар...
Тамчысына кадәр йотлыгып эч:
Һәр мизгелең —
Хәят суыдыр.
Җаның ягып яшә,
Җанымны як!
Көне килер,
Тән бер суыныр...

Еллар үткәч,
Кемдер, бармак төртеп,
Тиңләмәсен дисәң козгынга —
Җаныңны як!
Җылыт дөньяларын,
Янсын җаның,
Янсын,
Кызганма!

*1985*

## Куан, каләм!

Керфекләрдән яшьләр кипмәгән,
Күңелләрдән курку китмәгән...
Ил өстеннән томан тарала:
Җимереклек — кая карама.

Хәбәрдарлык үзенең пәрдәсен
Чынлап күтәрәме әллә соң?
Карашларда әле шөбһә-шик:
Сүзне үлчәбрәк сөйләшик —

Дөнья хәлен әле кем белә...
Авыз пешмәгән бит бер генә!
Әмма инде апрель җилләре
Айкап үтте барлык җирләрне.

Онытылган кырлар-басулар
Апрель ташулары ярсудан
Чистарынып калды, юылып:
Сөр, чәч, үстер! —
Башка юлы юк.

Сөр, чәч, үстер ирек гөлләрен!
Ничә еллар хөрлек күрмәдең...
Күңел яралары,
Рәнҗешләр,
Түбәнсетелүдән әрнешләр
Юылып төште инде быел яз —
Куан, каләм!
Куан, кыю яз!

Гүя борын төрткән яшь үлән,
Безнең ерак калган яшьлектән
Илле алтынчы еллар түреннән
Өмет чәчәкләре терелә.

Ирек — онытылган сүзләргә,
Ирек — куркытылган сүзләргә!
Һәрнәрсәнең исем-җисемен
Әйтер хакың бүген бар синең.

Яңа инкыйлаби быел яз —
Куан, каләм! Куан, кыю яз!

*Апрель, 1985*

## Казан циркында

Хәвеф көтеп,
Йөрәк кысылып килә,
Тынып кала кинәт бөтен зал...
Барабаннар кага...
Тукта, Кио!
Чынлап күз буарга тотынсаң,
Кисмә ул гүзәлне,
Кис син мине,
Серле сандыгыңа биклә дә...

Исем китми исләр китәренә,
Кызык тапмый күңел никләргә?
Нигә икән була шундый халәт:
Бурыч үтәгәндәй яшисең,
Тәмен тапмый гына эшлисең дә,
Тәмен тапмый гына ашыйсың.

Хисләреңне юып ага гомер,
Чүп-чарларны юган яз сыман.
Синең фокусларың ни-нәрсә ул?
Ни булса да,
Барыбер аз сыман...
Ә уйласаң,
Төссез торгынлыктан
Торатәшка каткан күңелне
Бер кузгатып җибәрергә юкса
Бер ым,
Бер сүз җитә түгелме?
Хәвеф көтеп,
Йөрәк кысылып килсен,
Йокламасын вөҗдан гырылдап —
Булдыралсаң әгәр,
Эмиль Кио,
Син бөек маг,
Шундый ырым тап!

Ә күз бума...
*1985*

## Кичке эңгер

Кичке эңгер —
Шәһәрдә бер мизгел:
Гөлт итә дә кабына утлары.
Шәһәр хәрәкәттә.
Шәһәр гөрли...
Һич күренми аның туктары.

Тик бистәдә генә карт урамнар
Чекерәеп ята,
Караеп...
Заман өчен калган тараеп...
Тараюда гүя бар гаеп!

Кичке күкне мәчет манарасы
Курка-курка гына тишкән дә,
Кабаннан су эчә күләгәсе,
Калтыранып егылып төшкән дә.

Яңа бистә Яңа бистә инде:
Бик заманча түгел сурәте.
Күп йортларда әле шәмаилләр,
Ишетелгәли Коръән сүрәсе.

Болары да тарих өчен —
Мизгел...
Эреп бетмәс диеп уйлама.
Ирексездән йөрәк кысылып куя,
Борчулы бер тойгы уяна:

Күккә курка-курка борын төрткән
Манараңның соңгы сәгате
Кайчан сугар, Казан?..
Җуелырмы
Синең үзеңә хас сәнгатең?

Кичке эңгер...
Караңгылык иңә
Авып барган Сөембикәгә...
Яшь ай килеп куна манарага —
Эреп юкка чыгар иртәгә...

*1981—1984*

## Бушлай гына...

Бушлай гына киләсең дә дөньяга,
Җир йөзендә —
Кешеләрнең уртак өендә
Бер түләүсез яши бирәсең, —
Сиңа шулай тоела, —
Бушлай гына...
Аннары,
Гомерең белән түләп,
Китеп барасың якты дөньядан,
Җир йөзеннән —
Кешеләрнең уртак өеннән,
Кемгәдер,
Яңа бер килүчегә
Урыныңны калдырып,
Бушлай гына...
Ул да яшәсен өчен бушлай гына
һәм китеп барсын өчен
Гомере белән түләп,
Урынын калдырып
Кемгәдер өченчегә,
Бушлай гына...
Аннары —
Өченче дүртенчегә,
Дүртенче бишенчегә —
Шулай бихисап...
Һәммәсе бушлай гына...
Түләнгән гомерләрдән чылбыр ялгана —
Мәңгелек чылбыры —
Бушлай гына...
Шулай тоела,
Шулай тоела,
Ах! шулай тоела,

Тоела тик шулай гына...
Бушлай гына...

*1987*

## Бабай

*Ул үзе*

Төсе —
Алламыни!
Җиргә иңгән.
Шул ук җиргә китәр тиздән.
Инде җир төсенә кергән...
Шушы җиргә көчен биргән:
Иркәләгән, сөйгән, сөргән,
Кеше булып атлап йөргән.
Сеңгән аңа басу исе,
Күчкән аңа шул җир төсе...

Күзләре —
Ут-кояштан, якты күктән
Кайчандыр җыеп эреткән
Яшәү нуры инде күптән
Юмарт өләшенеп беткән...
Тормыш балкыбрак киткән.
Алган әҗәт инде күчкән
Ерактагы офыкларга,
Якындагы оныкларга...

Башы —
Җир күк авыр бер шар булган,
Җир күтәрмәс уйлар тулган.
Йомшак чәче — сирәк кылган,
Яра җөе — Порт-Артурдан...
Язмыш күп төпкә батырган,
Җиңмәгән...
Аңа ахырдан
Үзе килеп чүккән тезен:
«Әмәлем юк, син бик түзем!»

Куллары —
Кош итеп сөеп туйсын да
Оныгын оя-учында
Җибәрсен чөеп, очсынга...
Кешелек,
Тизрәк күч шунда,
Аның кодрәтен той син дә —
Үс шунда җылы учында!
Ә куллар нидер эзлиләр...
Бабай анысын үзе сөйләр.

*Аның зары*

...Җитмиме миңа
Олан карашы —
Эретә алырлык
Картлык бозларын?
Дулкыннар ваткан
Корабым баткан...
Юкмы көч-куәт

Бирер дусларым?

Җитми лә миңа,
Нәрсәдер җитми...
Юкса чит итми
Болай беркем дә.
Ә никтер менә
Хет кер кабергә,
Кәфен урынына
Уйлар бөркән дә...

Кулым кушыру
Булыр купшылык.
Тынгылык сөйми,
Сөймәс бу башым.
Гаҗизлегеңнән
Диңгезгә ут төрт,
Алмаштыр яки
Төсен кояшның!

Кеше җиһанга
Мал белән килми,
Гүргә кергәндә,
Мал белән китми.
Җитми лә миңа,
Нәрсәдер җитми...
Ике кулыма
Бер шөгыль җитми.

### *Аның васыяте*

Ир катында иләмсезлек
Иләс-миләс йөргәндә,
Иләслегең-юләрлегең
Илгә-телгә кергәндә —
Ир бул! Булма бер бәндә...

Ир кичмәслек Иделләр юк,
Йөр хет әллә кайларда.
Ил сүзе — Идел дулкыны:
Иркәләр дә, кыйнар да —
Үпкәләгән кыйланма.

Ирен тешләп ир булмассың,
Ир икән — син илгәзәк.
Иптәшләргә — иптәшләрчә,
Бер мәзәккә — мең мәзәк...
Халкыбыз җор сүзлерәк.

Иптәшләр ипи-тоз белән
Итсә илдә иләмән,
Ир акылың үзе белер —
Акыл шыта тирәннән.
Саклан буш сүз сөйләүдән.

Ирләр без. Иркәлибез дә:
— Иркәм! — дибез, яратсак.
Ил улы булабыз, бары
Ил уйларына батсак,
Ил өчен дә җан атсак.

Ирек сөйгән җан инәлер
Иләмсерәп, илереп...
Илсез-йортсыз ир — ирексез.
— Илем! — диген иң элек,
Илгә телә иминлек.

*1968*

## Ана

*(Элегия)*

Ак биләүдә елый сабый.
Сабыйга ни — төн булса ни!
— Җылы сөтем, суынмый тор!
Тукта, каты суырмый тор,
Улым, җаным, бәгърем, — ди-ди,
Ана көйли, биреп ими.
Улы елый — ана җырлый...
Ана җырлый — улы йоклый...

Ак биләү күк ап-ак кышта
Ак бураннар улый тышта.
— Җылы чәем, суынмый тор!
Сары сагыш, суырмый тор:
Керфекләргә төн кунса да,
Улым кайтыр, соң булса да.
Улы юлда — ана уйда...
Ана уйда — улы юлда...

Ак биләү күк ак мендәргә
Кай арада күмелгән дә:
— Җылы тәнем, суынмый тор!
Түз, түз, улым, сыгылмый тор.
Кайгың бетсен янып-көеп,
Яшә көлеп... — дигән кебек,
Ана йоклый — улы елый...
Улы елый — ана йоклый...
Ак биләү күк ак мендәрдә,
Төренгән дә кәфеннәргә...

*1968*

## Ак патшалык

Урман. Ак патшалык.
Каравылчы йорты
Көрткә кереп чумган биленнән.
Мин биредә сәер бер падишаһ!
Бик ерактан, шау-шу иленнән
Качып килдем.
Калды театрлар, неон утлар,
Трамвай-троллейбуслар чираты...
Мин — падишаһ!
Беркемгә буйсынмыйм.
Бар бик күндәм, йөгерек, җор атым —
Чаңгыларым.
Йорт хуҗасы кредит-нисез генә
Мылтыкның да бирде иң шәбен:

Дәүләтемдә, ап-ак патшалыкта
Куян атып йөрү исәбем.
Аттырса!
Ә кыш әйбәт...
Бохар песиедәй
Сырпалана аяк астында.
Ак чалмалы нарат — минем вәзир,
Тик ул миннән бераз ятсына —
Сөйләшми.
Менә шундый ап-ак патшалыкта
Мин — падишаһ! — гамьсез көн итәм.
Әйтегезче, мәгъруր патшаларның
Гомере кыска була ник икән?
Замана!
Әнә замана тавышы ишетелә,
Ерак түгел, Кама ягыннан:
Анда инде шәһәр салынган,
Утлар кабынган, газлар ягылган —
Үзе әкият!

*1968*

## * * *

А татарчонку хочется напиться...

*Дм. Кедрин*

Шагыйрь теленә кергәнсең икән,
И татар гынам, татар баласы!
Хәмерләр эзләп йөрергә кая —
Бер сынык юллап читкә баргансың.
Чәчелгәнсез дә дөнья буйлатып,
Милләтнең эшчән ир-егетләре,
Чәчрәгән сезгә иске тормышның
Шәрабы түгел, гел күбекләре.
Шундый булган ул синең сәрхушлек,
Дөнья ачысы сине исерткән.
Куган чактамы берәр ишектән,
Аһ-зарларыңны шагыйрь ишеткән.
Бәлки, син аңа, телең сындырып:
«Куалар... вот как...» — дигәнсеңдер дә,
Ул «водка» диеп аңлап калгандыр...
Юк, үпкәләмим аңа мин бер дә.
Төрле тел түгел, бер үк телдә дә
Кеше бер-берсен аңламаганда,
Казак камчысы, жандарм итеге
Кан-яшь эчерткән каһәр заманда,
Йөргәнсең читтә, кагылып-сугылып,
Тик бетмәгәнсең сынып-сыгылып...
Синең мескенлек, синең сәрхушлек
Тарих базына калды егылып.
И татар гынам, татар баласы,
Чәчелгәнсең лә син туган җирдән...
Тел очындагын әйтмәгән шагыйрь:
Хөрлек хәмерен эчәсең килгән.

*1969*

# Идел акчарлагына

Сине янә күрәм менә;
Тирбәләсең күркәм генә
Иркен Идел күкрәгендә,
Акчарлагым!

Акчарлагым, ак җилкән син,
Кай ара килеп җиткәнсең,
Ничә диңгезләр кичкәнсең —
Аргансыңдыр.

Аргансыңдыр илләр гизеп,
Илемнең аяз күк йөзен
Күрмичә син ничек түздең?
Иделләрсез?

Иделләрсез илләр ямьсез.
Сизгәнсең, кошым, белгәнсең,
Ашкынып кайтып килгәнсең —
Рәхмәт сиңа!

Рәхмәт сиңа, ак җилкәнем,
Илкәем дип ах иткәнсең...
Җитте зарыгып көткән көн —
Сөендердең!

*1970*

* * *

Яшелләнеп уҗым шыткан —
Кытыклаган тәпине.
Уҗымнарда — салкын чыклар.
Тапмый уен, тәтиме —
Эзләгәнмен этине...

Арыш буынга сикергән —
Күзләрне иркәләгән.
«Син китмә арышлы җирдән,
Сикермә... иртә әле», —
Дип, кем дә «киртләмәгән».

Арышлар инде баш кыскан —
Басуга бармаганмын.
Акылсыз хыял-баскычтан
Мин читкә караганмын...
Белмим, кем каргагандыр?!

Арышлар серкә очырган —
Баш әйләнгән исенә.
Күңел каядыр очынган
Бер җылы сүз тисә дә,
Кызлар егет дисә дә...

Арышлар агарып җиткән.
Арыш балавызланган.
Дөнья мине төпкә җиккән,
Язмышым явызланган
Һәм... суктырган бозлардан!

Арышлар күптән өлгергән —

Сугылган — көшелләрдә...
Сукмагым югалткан җирдән
Карыйм да кешеләргә,
Инде, димен, нишләргә?

Уйлыймын: «Ашыктым... Мин дә
Уҗымдай яшел идем.
Буыным катмаган көйгә
Серкә очырып йөрдем...
Газаплар гына күрдем!»

Уйлыймын: «Ашыктым... Иртә
Баш кыскан арыш идем.
Чәчләрем агарды бит, ә!
Агарсын, карышмыймын —
«Балавыз» Марс идем...»
Арышлы басуларыма
Яңадан барыш минем...

*1970*

## Ялта аһәңнәре

*(Шигъри бәйләм)*

Мин Ялтада ялда.
Як-ягымда —
Кипарислар матур, мәһабәт!
Ләкин ятлар,
Холыклары башка —
Юк аларга миндә мәхәббәт.

Алар җиргә гүя юри генә,
Уйнап кына кадап куелган.
Кипарислар көязләнә бирсен,
Каеннарым китми уемнан.

Язгы кар исеннән исерә-исерә,
Каен суы эчеп йөргәндә,
Умырзая зәңгәр ялкыннарын
Кызганмыйча юмарт биргәндә,
Кызлар чәчәк кебек ачылганда,
Яз җилләре кагылып китүгә,
Нәни кояш булып балкыганда
Алар йөзендәге сипкелләр,
Иделемдә бозлар ташыганда,
Актарылып,
Күкрәп,
Дөбердәп, —
Яшел орчык төсле салкын, җансыз
Кипарислармыни күңелдә?!
Хет кисегез!
Мин — сут җыйган каен,
Умырзая —
Минем ялкыннан
Бозлар түгел, кызлар эрер иде!
Зәңгәр ялкыннарым балкыган.
Мин — язгы җил —
Кызлар йөзендәге

Сипкелләрне сыйпап үтүче.
Мин ул — Идел бозы —
Кузгалырга
Ташкын суны зарыгып көтүче.
Кипарислар гүя юри генә,
Уйнап кына кадап куелган.
Алар әйдә көязләнә бирсен,
Каеннарым китми уемнан...

*** * ***

Суың зәңгәр,
Исемең — Кара диңгез!
Үз итмәссең, ахры,
Кагарсың.
Читтән килгән татар малаена
Чит йомычка итеп карарсың.
Эзләгәнем син түгелен тоеп,
Үчләнәмсең шулай, ярсынып?
Әүлия син!
Минем күз алдымда
Бормалана һаман ярсу Ык.

Юк, юк, үпкәләмим.
Искәртүең,
Кисәтүең әле ярады.
Мин — йомычка
Ыкта чайкалырлык,
Бер учакта дөрләп янарлык.
Ләкин,
Кирәк булса,
Диңгезеңдә
Батмаенча гомер агарлык.

**Шаулый диңгез...**

Диңгез дигән ярсу дию
Дулый да шаулый бүген —
Ыргытмакчы җилкәсеннән
Мең еллар җыйган йөген.
Ул йөгәнсез, кыргый тайдай,
Ярсый күбекләр чәчеп;
Ак яллары тузгый-тузгый...
Җан сорый кемне дәшеп?
Мәгърур таулар карый аңа
Мәһабәт биеклектән.
Таулар көлә: «Туймыйсың, — дип,
Шашудан, тилелектән!
Кыя-ташларга ташланып
Ни кырмакчы син, җаным?
Кайтарып алып буламы
Гасырлар, чорлар җанын?..
Ун мең еллык төпсезлектә
Тавр да скиф, сармат,
Румнар, һуннар, хазар-мазар...
Шашынып кая бармак?»
Дулкын йоткан каеклардай
Йотылган кабиләләр...
Йотылганнар урынына

Яңалары киләләр.
Киләләр дә төпләнәләр,
Мыжгыйлар кырмыскадай,
Шаулый диңгез, үрсәләнә —
Елмая тормыш агай!
Бүген ярсый Кара диңгез,
Иртәгә янә тынар.
Киткәннәр инде киткәннәр...
Исәннәр яратырлар.

**Ай-Петридә уйлану**

Тау баласы түгел,
Кыр баласы —
Мин тауларга мендем:
Җан тетри!
Кыя-ташлар кырыс, шомлы икән,
Серле икән бигрәк Ай-Петри.
Биеклектән куркам кечкенәдән,
Аска баксам, башлар әйләнә!
Нинди чорлар монда катып калган?
Ни-нәрсәләр ташка әйләнә?
Бер җавап юк...
Әче җилләр генә
Йолкып алмак булып елаша.
Әйтерсең лә ят бер планетага
Без иңгәнбез йөзәр ел аша.
Таулар, сыртлар...
Исемнәре серле...
Нидер искәртәләр күк тоям.
Нинди телдә хәбәрләшә икән
Соры Кыя белән Күк Кыя?
Ай-Петридән ары Чатыр-Дагы,
Кара-Дагы тагын, Карагач...
Аста — күз яшедәй Кара диңгез...
Ерак күренә моннан карагач.
Тау баласы түгел,
Кыр баласы —
Сәлам бирәм сиңа, Ай-Петри.
Җавабың юк...
Әче җилләр исә...
Күңел әллә нишли, җан тетри.

**Дельфиннар**

Әйтерсең дулкыннар —
Уйныйлар дельфиннар:
Ял иткән халыкка тамаша.
Инде төн. Караңгы.
Кешеләр таралды...
Дельфиннар калдылар таңгача.

Таң белән килделәр,
Кешеләр күрделәр:
Дельфиннар һаман да шаяра.
Уйныйлар дельфиннар,
Чәчрәтеп дулкыннар,
Ярга ук сикереп кай ара.

Өч тәүлек дигәндә,

Чумдылар тирәнгә,
Куркытып вак-төяк балыкны.
Киттеләр, киттеләр...
Һәм моңсу иттеләр
Яр буен, андагы халыкны.
Аларның уйнамый,
Дулкыннар кыйнавын,
Елавын сизмәде беркем дә.
Зар булып соңгы кат
Килгәндер дельфиннар:
— Аңлашыйк, кеше, — дип, — бер телдә!

* * *

Диңгез җәйрәп ята иркәләнеп,
Сукайлары зәңгәр фирәзә.
Чуерташлар җыеп яр буеннан,
Белгәнемчә итәм күрәзә.

Менә ак таш.
Түп-түгәрәк үзе.
Кемнең бәхетләре түгәрәк?
Дулкын ялмамасын.
Алып куйыйм
Бәхет ташын бераз түргәрәк.

Монысы — яшькелт.
Әле чарланмаган.
Бу кемнеңдер, ахры, яшьлеге.
Суга салам:
Әле сыналырга,
Кыйналырга тиеш яшь кеше.

Менә — кызыл.
Нәни генә тамчы.
Кан-яшьләрнең әллә тамчысы?
Җыйганмы ул диңгез төпләреннән
Кайгы диңгезенең ачысын?
Мин ыргыттым аны бик еракка.
Кире чыкмас булсын,
Югалсын.
Барыбер чыгар ләкин —
Кеше канын
Нинди сулар гына юалсын?

Ә бу — зәңгәр!
Үтә күренеп тора.
Мәхәббәткә аны юрыйм мин.
Оялтасым килми,
Аңа тимим.
Күрмәмешкә салынам юри мин.

Ә монысы — сары.
Миңа пары.
Сары сагышларым тамгасы.
Куеныма салам:
Миндә калсын,
Диңгезләрдә сагыш калмасын.
Кирәк булса,

Диңгез янә табар —
Диңгез бит ул изге, олы җан.
Сагыш байлык миңа бу көннәрдә,
Сагышларым белән җылынам.

Җәйрәп ята диңгез иркәләнеп,
Сукайлары зәңгәр фирәзә.
Чуерташлар җыеп яр буеннан,
Мин үземчә итәм күрәзә.

* * *

Таудан иңде болыт,
Кара булып.
Була икән кайчак танышы
Болытның да!
Хәтерләтте кинәт
Ай-Петридә күкрәү тавышы
Нәкъ шушындый кара бер болытны.
...Ык буенда идек,
Куышта...
Икәү генә идек...
Ә ул болыт
Метрәй тауларыннан шуышты.
И ишелде өскә!

Яшен телде
Утлы камчы белән күкләрне.
Гүя сине сукты —
Миңа аудың...
Кайнар иде синең күкрәгең...
Шомлы иде куыш.
Дөм караңгы.
Рәхмәт инде кара болытка:
Яшеннәрдән якты хисләр алдым,
Сине таптым караңгылыкта.

...Әле менә иңде дә болыт,
Йөрәк гүя куйды убылып.

**Очан-су**

Ташлар өстеннән йөгерә дә үтә,
Йөгерә дә үтә Очан-су...
Саф суларында синең шәүләңме?
Нигә соң әле уйчансың?

Күренми миңа Очан-суларның
Көмештәй чиста төбеннән:
Йөгерә дә үтә, йөгерә дә үтә
Гайбәтме әллә күңелеңнән?

Кемнәр тырыша күңелеңне шулай
Айкап, болгатып карарга?
Тау чишмәләре һәрвакыт сафлар,
Пычрак иярми аларга.

Йөгерә дә үтә, йөгерә дә үтә...
Ташлар өстеннән Очан-су...

Кеше сүзләре йөгерер дә үтәр —
Нигә соң әле уйчансың?

*1973*

## Йөрәгем

Кайгылы көннәрнең,
Йокысыз төннәрнең
Күпмесен күтәрдең,
Йөрәгем?
Күпмесен күтәрдең,
Күпмесен үткәрдең,
Яшендәй этәрдең,
Йөрәгем?

Сиңа сыйды җиһан,
Гавам,
Галәм —
Җанлысы да,
Җансызлары да...
Сиңа таныш шатлык-куанычлар,
Сиңа таныш җан сызлавы да.

Сөенеч яңгырлары яуды синдә,
Кайгы бураннары дулады.
Кояш чыкты,
Ай калыкты синдә —
Һич тормыштан туйган булмады.

Язгы карлыгачлар очты синдә,
Яңгырады гыйшык җырлары.
Өмет чәлпәрәмә килгәндә дә,
Зарыгып көттең килер елларны.

Ялган кермәк булды —
Юк,
Сыймады!
Мәкер кермәк булды —
Сыймады!
Тормыш кыйнады да иркәләде,
Бер сыйпады,
Йөз кат сынады.
Сынатмадың!
Ярылыр чиккә җитеп
Какканда да күкрәк читлеген,
Сиңа җиңел язмыш күтәрмәдем,
Һәрчак авыр булды йөк минем.

Сизәм: ардың...
Инде тормыш ритмын
Киметергә кирәк кирәген,
Син тибәсең ләкин:
«Юк! Юк!» — диеп,
Нагрузка сорап,
Йөрәгем,
Рәхмәт сиңа!

*1980*

## Тукайны сагыну

*(Шигъри бәйләм)*

**1**

Укыйм малайларны,
Укыйм агайларны —
        Заман шигыре,
        Заман фикере!
Көнләшәм дә сыман,
Тиргәшәм дә сыман —
        Көн-төн укыймын,
        Арып туктыймын.
Кыйнала вөжданым,
Мунча әзли җаным,
Эзли Тукайдан —
        Тукайга кайтам!

**2**

Тупырдашып торган пар атларда
Йә, булмаса, елгыр тулпарда
Тып-тып басып түгел,
Биштәр асып
Тукай моңы кергән йортларга.

Ул моң Кушлавычтан башланган да
Өчилегә күчкән, Кырлайга;
Инешләргә иңгән, урманнарга,
Томан булып сарган тугайга.

Тугайларда тайлар — байларныкы...
Тай саклаучы ялчы малайлар,
Тулган айга карап моңайганда,
Тукай моңы белән моңайган.
Тубалдагы орлык соңгы өмет
Булган чакта авыл картына,
Тургай булалмаган Тукай моңы —
Ул җил булган тәрәз артында.

Ул моң «ач үлемнең куркусыннан»
Ил елаган өчен елаган...
Тукай моңы — халык моңы шулай
Иңрәп торган авыр елларда.

Ул моң сыкраулардан, аһ-зарлардан
Халык ярсуына әверелгән;
«Илгә — азатлык!» дип аһ оручы
Ирләр йөрәгенә бәрелгән.

Бөек Тукай, моңы-җыры булып,
Туган теле булып халыкның,
Гасырлардан гасырларга шулай
Күкрәп барыр өчен калыктың.

Ирек алган илдә мөмкинмени
Онытылырга, тынып калырга:
Язган сиңа, Тукай, заман белән,
Шатлык җыры, Тормыш гимны булып,
Гасырларны кичеп барырга.

**3**

> На татарском кладбище,
> Среди старых плит...
>
> *И.Эренбург*

Татар зиратында Тукай ята.
Кара кабер ташы Тукайның.
Әйләнәм дә киләм шул кабергә...
Ахры, тормыш, ардым бугай мин.
Язмышына халык шагыйренең
Кара мәрмәр әллә ишарә?..
Ник җитмәгән икән илһам көче
Шул язмыштан аркан ишәргә?!
Җитәр иде, җитәр...
Гөлләр үсеп,
Җырларында былбыл сайраса.
Коеп куйган шагыйрь, салон шуты
Булырга да мөмкин ләбаса!
Булмаган шул.
Туры Тукай булган —
Халык җаны, халык вөҗданы.
Гел күтәргән арык иңнәрендә
Ил күтәргән кара нужаны.
Безгәме соң, ай-һай, ардым, диеп,
Тукай ышыгында калырга!
Безгә әле аның эзләреннән
Барырга да һаман барырга...
Татар зиратында Тукай ята.
Ул — үрнәге мәңге януның.
Татар йөрәгендә Тукай яши —
Үлеме юк халык җанының.

**4**

Җәйге Казан.
Ташаякта — Тукай.
Тукай агач атка атланган.
Җилә генә шагыйрь карусельдә!
Сабый бала кебек шатланган.
Ыгы-зыгы.
Шау-шу.
Җыр-музыка.

Нәрсә кирәк тагын дөньяга?
Аллы-гөлле,
Агач йөрәкле ат
Ярый әле Пегас булмаган.

Иҗатында агач атта җилгән
Бер ваемсыз мөтәшагыйрьләр
Бушбугазлар,
Купшы тутый кошлар
Һәр заманда булган,
Һәр илдә.

Ташаякта — Тукай,
Карусельдә...
Бер туйганчы, әйдә, әйләнсен!
Шатлык —
Кыска,

Бөтереп алыр аны
Тормыш каруселе аннан соң.

Ташаяктан ерак түгел чүплек.
Казыналар чүплек башында
Карт-корылар белән бала-чага:
Әллә хәзинәләр бар шунда?

Көн дә килеп казыналар алар.
Уйлый калсаң,
Ул да карусель!
Күңелеңдә ятлар казынмаса,
Хөр хәерче булу ярый шул.

Ташаякта төрле-төрле кибет —
«Кайсы алдый,
Кайсы алдана...»
Түгәрәктән сикереп чыгып булмый!
Еллар елга шулай ялгана.

Сукбай йоклый посып бер почмакта,
Шат карусель тавышы астында.
Йокла, сукбай!
Дөнья каруселе
Биргән өлешеңне азсынма.

Миллионнары булган байлар әнә
Интегәләр йоклый алмыйча.
Түгәрәктән сикереп чыгып булмый,
Миллионсыз йә башсыз калмыйча.

Түгәрәктән сикереп чыгып булмый:
Һәркем тырыша өскә,
Үргәрәк.
Егылып төшә,
Янә үрли башлый...
Бик азларга дөнья түгәрәк.

Гашыйк парлар менә карусельгә.
Ә «Болгар»да,
Кысан бүлмәдә
Бер бәхетсез соңгы сүзен яза —
Җыена ул атылып үлмәгә.
(Бер бай аңа кызын бирмәгән!)

Тормыш каруселе...
Тукай кайта
Ташаяктан,
Арып-ватылып...
Түгәрәктән сикереп чыгып булмый! —
Шундый миһербансыз катылык...

Тукай кайта...
Кай якта дыр шунда
Скрипка елый бер көйгә.

Тукта инде, җаным,
Сыкранмачы!
Янма инде, йөрәк,
Гел көймә!

Тукай кайта...
Урам тулы халык.
Ә ул ялгызлыктан гаҗиздер.
Ятим күңел,
Агач атың да юк...
Без ятимнәр кемгә газиздер?

Шигырь язар Тукай төн йокысыз,
Сердәшлеккә шигырь ярый ул.
Соңгы җәе аның...
Үзе белми...
Әйләнәдер тормыш-карусель...

*1969—1982*

## Балладалар, легендалар

Таш йөрәкле таулар исеменнән,
Кубарылып,
Сезгә килдем мин,
Сыны булып бастым батырларның,
Мин — хәтере Туган илемнең.

## **Тормыш әлифбасы**

**1**

Җир тарихы — тоташ көрәш, көрәш...
Килә шулай гомер-гомердән.
Азат хезмәт тәмен татыр өчен,
Тыныч тормыш ямен белергә
Өйрәнгәннәр кешеләр каннар коеп...
Шул каннардан
Көрәш байраклары аллана.
Юк, ышанмыйм: «Көрәшләрдән читтә
Шәхси бәхет», — дигән ялганга.
Бәхет туа бары зур көрәштә,
Зур көрәштә көннәр яктыра.
Көрәш авыр була барган саен,
Җиңү ләззәте дә татлырак.
Еллар безгә эшли.
Ләкин һич тә
Еллар җилкәсенә елышып
Утырыр чак түгел.
Әй, кешеләр!
Онытмагыз көрәш сулышын.
Кешелек бит әле биш почмакның
Һәр почмагы өчен көрәшә.
Юк, Җир әле Бәхет шары түгел,
Көрәш шары шушы көнгәчә.
Вакламыйча изге идеалларны,
Вакланмыйча гына бәһа бир:
Кешеләрне көрәш Кеше иткән,
Тик көрәштә Кеше — баһадир!

**2**

Кешеләр бит маймыл токымыннан.
Бармы моның оят-хурлыгы?!
Токым белән түгел,
Эше белән
Кеше исбат итә зурлыгын.
Тумышыннан кеше эшкә хирыс,
Кызыксынып карый дөньяга.
Хезмәт ләззәтеннән мәхрүм итсәң,
Якты дөньяларың ник аңа?
Ул маймылдан үсеп чыккан икән —
Аны бары Хезмәт үстергән.
Хезмәт аңа егәр генә түгел,
Акыл биргән, рухи көч биргән.
Кеше —
Хезмәт улы.
Шуңа күрә
Җир йөзендә һәрбер ил халкы
Сөрә-чәчә, эшли, иҗат итә...
Олуг хезмәт —
Кеше хакы, газиз Җир хакы!

**3**

Бик борынгы ыруг-кабиләләр
Һәр кисәкне тигез бүлгәннәр:
Тормыш өчен һәр кешенең хакы
Бер үк икәнлекне белгәннәр.
Иң беренче булып кайсы залим
Артык кисәк бәрабәренә
Кешелеген сатып юл салды икән
Килер дөнья бәлаләренә?
Булган бит ул — башлап җибәрүче.
Кем булса да берәү булган бит...
Юк, приоритет бирмим аңарга мин;
Ерткыч инстинкт
Кешеләр туганчы ук туган бит.
«Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» өчен
Кирәкмени кеше булырга?
Ярамаган шунда ул залимгә
Маймыллыктан чыкмый торырга!
Сабый фикер.
Ләкин менә никтер
Бутала да башта бутала...
Заман хөкем итсен — бүген аны
Мин уртага салам, уртага.

**4**

Нигә адәм кулы бик еш кына
Мылтык тәтесенә үреләә?
Җир йөзендә бар бит, яши әле
Кеше тиресе япкан бүреләр...
Алар бүлә ак һәм караларга,
Алар ясый Линч судларын.
Беләбез без милләтләргә алар
Кайсы яктан китереп сукканын!
Җир әйләнә, кеше каны сеңгән
Комачларга урап илләрне.

Комачлардан торган божра кыса
Бүреләшеп беткән миләрне.
Еллар әнә мылтык көпшәседәй
Төбәлгәннәр...
Калтырамый куллар, куллар нык.
Бүре белән Кеше көрәшендә
Туа халыкара туганлык.

*1965—1970*

# Кыз һәм Йөрәк

Әйтегезче, кайдан килде бу чибәр Кыз?
Кыз гынамы, Зөһрә кебек якты йолдыз.
Көтмәгәндә килде дә Йөрәкне алды,
Ләззәт белән газап катыш утка салды.
Канатларын кискән коштай калды Йөрәк,
Төн пәрдәсен алсулатып янды дөрләп.
Көннәр аның газапларын күрмәде шул,
Төннәр аны сизмәде шул, белмәде шул —
Киң күңелле гади егет Йөрәге ул.
— Горур Йөрәк һәрвакытта мине сөйсен,
Җылы нурын бары, — ди Кыз, — миңа сипсен,
Онытсын ул туган илен, халык исемен,
Күңеленә якын итсен мине генә!
Әмма Йөрәк, Кызны сөю белән бергә,
Оныта алмый, чын күңелдән сөя илен,
Әнкәседәй якын күрә Туган җирен.
Кыз, сандыкка зур Йөрәкне бикләп иртән,
Төнлә генә ачып карап китә икән:
Йөрәк һаман кешеләр өчен тибә икән.
Көнчелекнең утларында кара көеп:
— Кечкенәрәк йөрәк калса, ярар, — диеп, —
Кечкенәсе минем өчен янар, — диеп,
Кыз Йөрәккә гыйшкы белән яра сала,
Кыз Йөрәкне калҗа-калҗа телә бара.
Бу газаптан сыкранса да, Йөрәк түзә:
Чөнки һаман, кызый белән беррәттән,
Кешеләргә сөю яши зур Йөрәктә.
Кайнар каннан алсуланган көмеш чишмә:
— Мәкерле Кыз! Зур Йөрәкне харап итмә,
Үкенерсең соңыннан, — ди, — тукта, кисмә.
Эссе чүлне терелтүче көмеш тәнем
Йөрәк өчен — ал, туракла! — мин бирәмен.
Кызганудан яшьләр түгә зифа каен,
Кызганудан җилләр елый искән саен...
Йөрәк үзе үсә генә кискән саен!
— Исән килеш җибәрмим! — дип, Кыз күтәрә,
Күтәрә дә зур Йөрәкне ташка бәрә.
Чәчелеп китә Йөрәк шунда, нурлар сибә,
Әйтерсең лә күптән шуны көткән генә,
Кисәкләре йолдыз булып күккә менә.
Шуннан бирле халык юлын — хаклык юлын
Яктырта ул, сибеп күктән сөю нурын.
Тәкәббер Кыз ялгыз калып кан-яшь түгә:
— Йөрәк, кайт, — ди, — айлы кичтә киттең нигә?
Канлы кулын күккә сузып ул ялвара.
Тик файдасыз: Йөрәк инде кайтмый аңа...
Кайгысыннан Кыз тораташ катып кала.

Матур һаман, нурлы һаман җәйге көннәр,
Бакчаларда чәчәк ата назлы гөлләр,
Айның көмеш шәлен яба серле төннәр.
Халык өчен гомерен биргән Йолдыз-Йөрәк,
Аяз төнне нурга күмеп, яна дөрләп.
Аның сөю нурларыннан Җир яшәрә —
Көчле Йөрәк мәңге хаклы ул яшәргә!

*1956*

# Таш гасыр кыйссасы

Таш балта, таш пычак,
Кыскасы — таш гасыр.
Таш гасыр, кем сиңа
Кайтыр да баш ватыр?

Таш гасыр — бер тамчы
Тарихи кашыкта:
Кап та йот. Тукта, юк,
Ашыкма, ашыкма...

Анда да ел булган,
Көз арты кыш килгән.
Кешеләр яшәгән
Тир түгеп, эш белән.

Мамонтлар аулаган
Таш тотып кешеләр:
Чөнки бит булмаган
Игеннәр, көшелләр.

Менә шул заманда
Бер аучы юл тоткан
Еракка, тауларга,
Азыгы юклыктан.

Көн үтә, төн үтә —
Юк кош-корт, юк киек.
Аучы соң кайтсынмы
Буш килеш, баш иеп?

Кайтмый ул, таулардан
Үзәнгә юл ала.
Төн үтә, көн килә —
Ә аучы югала...

Чыгалар өч кеше
Эзләргә таң белән.
Юл озын, юл авыр —
Калганын кем белгән!

Баралар бер тәүлек,
Өч тәүлек, бер атна...
Һәм кинәт бер хикмәт
Күренә еракта.

Киләме зур җанвар?

Бу нинди пәһлеван?
Өч кеше: — Әҗәлдән
Сакла! — дип, баш орган.

Ни үле, ни тере
Ятканда куркышып,
Каршыга килә дә
Баса бит зур кеше.

— Туганнар, торыгыз, —
Бу мин бит, мин — аучы.
Бик озак кайтмагач,
Булгандыр елаучы...

Төшме бу, өнме бу?
Әллә соң сихерме?
Әйт, аучы, кем сине
Пәһлеван иттерде?

Ә аучы уң кулын
Куенга тыга да
Кадерләп, хөрмәтләп
Нәрсәдер чыгара.

Көтәләр, нишләр дип,
Торалар аптырап.
Ә аучы аларга
Өч бөртек каптыра.

Тын кала тегеләр,
Кыймыйлар дәшәргә.
Өчесе берьюлы
Яшәрә... Яшәрә!

— Туганнар, — ди аучы,
Мин булдым үзәндә.
Талчыктым, ачыктым,
Интектем үзем дә.

Бетте көч, — нишлисең?
Егылдым мин җиргә.
Иптәш юк, дуслар юк
Тамчы су бирергә.

Үлем ул, туганнар,
Кайда да бер үлем...
Ачлыктан үлгәндә
Ашадым бер үлән.

Чәйнәдем мин аны,
Бераз дым бирер дип;
Дымланса авызым,
Бәлки, хәл керер дип.

Ашадым... Шуннан соң
Йокыга киткәнмен...
Уяндым... Мин һаман
Үлмәгән икәнмен...

Тәнемдәниндидер
Җиңеллек сизәмен,
Тагын да талпынып
Үләннәр өзәмен...

Менә шул үләннең
Шифалы орлыгы
Миңа көч китерде,
Яңадан торгызды.

Әмма тик кызганыч:
Биш-алты бөртек ул.
Шифалы үлән бит
Булган тик бер төп ул.

Биш-алты бөртекне
Бүлгәләп ашыйкмы?
Өч тавыш: — Ярамас...
Хәл итик ашыкмый...

Бераздан беленә
Һәркемнең фикере:
— Бөртекләр сакланса,
Игелек китерер.

Үзебез аңарга
Күрсәтик игелек:
Яхшылап карарга
Өйрәник иң элек.

Төшәләр үзәнгә,
Эшлиләр интегеп,
Туфракны таш белән
Ерткалап, тир түгеп.

Яңа эш өйрәтә
Сукалар ясарга,
Өйрәтә икмәкне
Пешереп ашарга.

Ә икмәк ишәя,
Салына келәткә...
Дәрт арта йөрәктә,
Көч тула беләккә.

Акрынлап кешеләр
Игенче булалар,
Икмәкне кадерләп
Гел түргә куялар.

Ачлык та, кытлык та
Куркытмый кешене,
Булганда җирендә
Алтындай көшеле...

Таш балта, таш пычак,
Таш гасыр, кыскасы.
Онытмыйк әмма без

Таш гасыр кыйссасын.

Тарихи сабаклар
Гыйбрәтле, хикмәтле.
Хак сөйли бу кыйсса,
Алдамыйм, икмәктер!

*1963*

## Айзирәк ханбикә кыйссасы

Бу сюжет студентлык елларымда укылган берәр әсәрдән булса кирәк дип озак уйланып йөрдем, әмма анык кына хәтеремә төшерә алмадым. Ниһаять, очрак ярдәмгә килде: инглиз шагыйре Альфред Теннисонның (1809—1892) «Годива» исемле әсәреннән икән. Мин исә аны рус шагыйре Иван Бунин тәрҗемәсендә укыган булып чыктым. Безнең студентлык еллары («Хрущев чоры») Иван Бунин кебек бик күп тыелган әдипләрнең әсәрләре илгә яңадан әйләнеп кайта гына башлаган чор иде... Кызганыч, ул бик кыска булды...

*Автор*

Әллә кайчан гына әллә кайдан
Күңелемә калган уелып
Шушы кыйсса...
Еллар томанына
Күмелергә һич тә уе юк.
Сөйләп бирим әле —
Бәлки, шунда
Тынгы табалмаммы җаныма.
Бу — борынгы кыйсса.
Яхшы-яман
Борынгыда ачык чагыла.

Төгәл белмим —
Моннан меӊ еллармы,
Кай кыйтгада,
Кайсы тарихта? —
Шунысы мәгълүм:
Бик явыз хан булган,
Күп залимлек кылган халыкка.
Исемен ханның тарих хәтерләми.
Без кушканы булыр —
Җаһил хан...
Ханбикәнең исеме күңелемә
Айзирәк дип уеп язылган
Хан-сарайда.
Такыр башын кашып,
Йолыккалап кәҗә сакалын,
Хыялында гизә яшь кызларны
Кочкан-үпкән,
Сыткан чакларын.
Күз алдына килә кяфер кызы —
Талчыбыктай зифа Ульяша...
Фарсы кызы тагын...
Төрек кызы...
Тау кызлары... —
Ханның кулы аша,
Саный китсәң,
Ничә дистә икән?..
Дистә генә сиңа,
Ничә йөз! —
Узды алар —
Тик бер көнлек «маллар» —
Һәммәсе дә сылу бичә-кыз...

«Э-э-эх!» — диеп,
Татлы киерелеп,
Күзен генә йомган иде хан,
Аяк очындагы кара эте
Сискәндерде өреп кинәт:
«Һау!»
Этнең «һау»ы һәрчак ишетелә
Катгый кисәтүле «Хан!» булып.
Күзен ачты Җаһил —
Кызлар очты...
Чырае китте ханның бозылып.

Ханбикәсе кергән...
Ул гел шулай
Күләгәдәй йөри,
Шым гына.
Айзирәкнең сылу йөзендә ник
Пошынулы авыр шом гына?

Җаһил карап торды ханбикәгә:
Яшь тә чибәр...
Әмма тик менә
Бик үзсүзле!
Кыланмышларыннан
Бик интегә Җаһил, интегә...
«Йә, нәрсә бар?
Уйларымны бүлдең...» —
Тавышы кырыс иде Җаһилнең.

«Халык иңри...
Халык ачтан үлә...
Түземе бетте тәмам, хан, илнең!
Салган ясакларың...»

«Җитте!
Булды! —
Күкләр күкрәп куйды шикелле,
Дәһшәт белән күтәрелде Җаһил,
Гүя кара болыт ишелде:

— Инде ничәнче кат тукынасың:
«Халык... халык...»
Баксаң, үзең син
Ул мөртәтләр өчен, —
Җирләр йотсын! —
Черки тешләсә дә түзмисең».

Айзирәкнең күзләрендә шулчак
Ачу-әрнү уты кабынды:
«Мин үләргә әзер!
Ил-халыкка
Бирсәң мыскал өлеш малыңны...»
Һай түземсез Җаһил!
Аны бүлә:
«Бу сүзләрең әкият, Айзирәк!»

Айзирәкнең чигенер чамасы юк:
«Исбат итим ничек?
Әйт тизрәк...»

Ханбикәнең үҗәтлеге тәмам
Бәгырьсезнең бәгырен катырды:
«Мәйлең! — диде Җаһил. —
Сынап карыйк...
Син чынлап та шундый батырмы?
Шарт шул сиңа:
Ясак түләүләрдән
Азат булыр халык,
Шәһәрдән,
Алмачуарыңа бер атланып,
Син, Айзирәк, үтсәң шәрәтән...»

Җир ярылыр,
Җир йотармы, дисәм.
Оятсызны шунда, —
И Тәңрем! —
Юк, йотмады...
Ул этенә дәшеп,
Атлап китеп барды бик әкрен.

Айзирәкне гүя яшен сукты,
Зиһеннәре китте таралып,
Тулган айдай матур ак йөзенә
Тимгел-тимгел типте каралык...
Башы әйләнсә дә,
Егылмады,
Кулга алды үзен,
Турайды...
Чуалган уй-фикерләрен җыеп,
Игелекле эшкә юрады.
Чакырттырды бик тиз сөрәнчене,
Сөйләп бирде эшнең асылын:
«Чык шәһәргә.
Быргың хәбәр салсын,
Ишек-тәрәзәләр ачылсын:
Күрсен яше-карты —
Нинди хурлык
Кичерәчәк бүген Айзирәк...
Ник тораташ каттың?!
Күңел йомшап,
Кире уйлаганчы,
Бар тизрәк!»
Аннары ул хадимәсе аша
Боерык бирде:
«Алмачуарым
Китерсеннәр сарай капкасына...
Оятымны җиңеп, чыгармын...»
Кереп китте аулак бүлмәсенә,
Ашыкмыйча гына чишенде...
Көзгесендә күрде үзенең сынын —
Сыны иде аккош шикелле!
Тәгәрәде әллә кая читкә
Җаһил ханның затлы бүләге —
Бриллиантлар белән бизәкләнгән,
Мисырлардан кайткан беләзек...
Ефәк күлмәкләре шуыштылар
Ап-ак иңнәреннән...
Билләрдән...
Ике алмасын ике кулы кысты,

Тыеп үзен үксү-иңрәүдән...
Агарынып киткән чыраенда
Янып торды ике кара күз...
Авыр толымнары агып төште
Аягына кадәр...
«Карагыз!
Йә, күрегез минем мәрмәр тәнне...
Оялмагыз бер дә, оялма!
Ил хакына Җаһил хан алдына
Башка нәрсәм юк ич куярга...
Ихтыярым-рухым —
Үзе мәрмәр!
Аңламадың, ханым,
Белмәдең...
Ахрын уйла, ханым... —
Тәвәккәллим!» —
Ак нур-шәүлә чыкты бүлмәдән.
Кача-поса гына баскычлардан
Аска таба шуды нур-шәүлә.
Кача-поса гына бөтен сарай
Ярыклардан карап торды әллә?..

Ак нур-шәүлә капка төбендәге
Сөлек кебек Алмачуарның
Күзен кулы белән каплады да...
Һоп! —
Атланды...
«Җиңеп чыгармын...»
Сафлык-пакьлек алиһәсе булып,
Изге ак нур-шәүлә төсендә
Гүзәл ханбикәбез китеп барды
Буйсынучан аты өстендә.

Бу ни хикмәт?!
Тынган бөтен шәһәр,
Һәрбер урам,
Һәрбер тыкрык.
Йортлар гүя тезелешеп баскан
Сулыш алырга да куркынып.
Шылт тавыш юк,
Хәтта кошлар очмый,
Ишек-тәрәзәләр ябулы.
Шәһәр кадәр олы бер шәһәрнең
Үле чагы, диеп, йә, моны
Әйтеп булырмы соң?
Сәер мизгел,
Бу бер сагаюлы шомлылык...
Меңәрләгән комсыз һәм ач күзләр
Беткәндерме шулай йомылып?
Ханбикәбез уза шәһәр буйлап—
Ни үле дә җаны,
Ни тере...
Менә кинәт бик еракта гына,
Сискәндереп аны,
Эт өрә.
Тәне буйлап кайнар дулкын уза,
Ак йөзенә тама кызыллык:
«Һәр тәрәзә капшап калмый, димсең,
Һәр ярыкның, димсең, күзе юк?..»

Тып-тып баскан тояк тавышыннан
Уяныр бу шәһәр,
Уяныр.
Бу йорт түгел икән,
Икенчесе —
Арырагы түземен җуйгандыр.
Менә-менә бер-бер нәрсә булыр,
Атның шомырайган колагы...
Чү! Алдарак нидер селкенде күк... —
Җилдә тибри гөләп куагы.
Гөләп яфраклары лебердәшеп
Пышылдыйлар гүя:
«Шикләнмә...
Бөтен шәһәр күзен йомды шулай,
Илең сине хөрмәт иткәнгә.
Сөрәнченең быргы тавышыннан,
Коточарлык яман хәбәрдән,
Оятының бугазына басып,
Ил хакына бүген шәһәрдән
Ханбикәбез үтә шәрә тән!
Дигән шомлы сүздән тынды дөнья...
Юк, ханбикәм,
Түгел куркудан —
Сафлыгыңа синең баш июдән
Чыкмый халык үзенең йортыннан...»

Шәһәр чите.
Ханбикәбез атын
Кире борды кайтыр юлына.
Бөтен шәһәр бердәм күзен йомган... —
Ышансынмы икән ул моңа?
Сафлык-пакьлек алиһәсе булып
Ат өстендә кайта Айзирәк.
«Бөтен шәһәр» дигән идек тә бит...
Түбәнлеккә әллә күп кирәк?
Табылган бит шунда бер түбән җан:
Ул, кылтайтып тәрәз пәрдәсен,
Калтыранып күзәтмәкче була
Айзирәкнең мәрмәр гәүдәсен.
Алмачуар инде җитеп килә
Хыянәтчел хәтәр тәрәзгә,
Аяз көнне яшен сукты, дисәм,
Ул бәндәне шунда,
Әгәр дә —
Ышанмассыз...
Әмма шунысы хак:
Түбән җанның күзе чагыла,
Күзе күрмәс була —
Айзирәктән
Гүя кояш нуры агыла.
Алмачуар тып-тып узып китә
Хыянәтчел тәрәз турыннан.
Түбән җанның ике күзе чыга,
Гүя кайнар кояш нурыннан.
Сизми ханбикәбез...
Сафлыкка соң,
Пакьлеккә соң пычрак йогамы?
Бу дөньяда игелекле эшне
Каплап китәр пычрак юк әле.

Менә сарай.
Мәрмәр баскычлардан
Ак нур-шәүлә —
Мәрмәр Айзирәк
Күтәрелә үзенең бүлмәсенә...
Йә, Җаһил хан, тагын ни кирәк?
Айзирәкме мәсхәрәгә калды,
Әйт, Җаһил хан,
Әллә үзеңме?
Явызлыгың соңгы тамчы булды,
Ил-халыкның бетте түземе.

Шул мизгелдә шәһәр телгә килде,
Кайнап чыкты базар мәйданы:
Рәхмәт әйтте халык Айзирәккә,
Еракларга китсен, әй, даны!
Кайнады ил,
Ургып күтәрелде,
Килде халык сарай катына:
«Чык, Җаһил хан!
Әйт син,
Ни кыласың
Изге Айзирәгең хакына?
Чык, Җаһил хан!
Халкың алдына бас!»
Катты калды Җаһил тораташ...

Зәхмәт сукты аны —
Телдән язды:
Инде хәзер берни сорамас.

Ханбикәне ил анасы итеп
Таныды ил —
Тагын ни кирәк?
Халык күңелендә мәңге калды,
Үлемсезлек алды Айзирәк.

*1972—1987*

## Һәйкәл

Әйе, таш мин.
Салкын,
Җансыз,
Хиссез...
Тик гади таш түгел,
Мин — мәрмәр.
Таулар күкрәгеннән кубарылып,
Һәйкәл булдым батыр ирләргә.

«Тауга нәрсә,
Янмас-көймәс.
Барыбер —
Тыныч тормышың ни,
Сугыш ни...» —
Димәгез сез.
Таулар таулар инде!
Мәйданнарга таулар сыешмый.

Таш йөрәкле таулар исеменнән,

Кубарылып,
Сезгә килдем мин,
Сыны булып бастым батырларның,
Мин — хәтере Туган илемнең.

Антик заманнарда ак мәрмәрдән
Алиһәләр койган осталар.
Ә мин — кызыл,
Кара-кучкыл кызыл:
Каным саркыр кебек,
Кыссалар...

Суыта алмый мине кар-бураннар,
Яндыралмый ялкын-янгыннар.
Сынлаиалар,
Җанлаиалар миндә
Сугыш утларында янганнар.

Җанланалар миндә...
Мин аларның
Уе-хисе,
Хыял-өмете.
Көрешергә килгән чал Ананың
Кайнар яшен йотып,
Төн үтә...

Баш өстемдә —
Кояш,
Зәңгәр күк тә,
Итәгемдә —
Кызыл чәчәкләр.
Тик барыбер миңа килгәннәрнең
Күзләре моң-сагыш чәчәләр.

Күзләрендә сагыш...
Нигә һаман
Яна икән,
Сыкрый яралар?
Түзә алмас кебек таш йөрәгем,
Түзә алмас кебек,
Ярылыр...

Юк,
Кирәкми,
Кызганмагыз мине,
Кирәк түгел мине дәшәргә.
Кемнәрнеңдер аяк асларында
Мәрмәр баскыч булып яшәргә
Чакырмагыз,
Мәрмәр колонналар!
Мәрмәр заллар!
Мәрмәр туганнар!
Чакырмагыз мине,
Постым изге —
Мине һәйкәл итеп куйганнар.

*1984*

## Шәһре Болгар

Кара пулатлары,
Мунчалары
Күптән миңа таныш,
Билгеле...
Мин соң монда янә шул ташларны
Багар өчен генә килдемме?

Карап йөрим сине,
Шәһре Болгар...
Хәрабәләреңә юк кадер!
Ташландык та җимерек —
Битарафлык...
Ни зиратың синең,
Ни кабер...
Кабер ташларыңның кубарылып
Кычкырасы,
Нәгъръә орасы
Көне үткән микән,
Әллә алда? —
Ә кемнәрдән аны сорасы?

Ут-сөрем дә,
Көл-күмер дә хәзер
Күзгә кереп тормый —
Беткәннәр...
Бетмәгәннәр!
Алар безнең канда!
Безнең җанга-аңга күчкәннәр.

Күрәм әле, күрәм:
Ничә гасыр
Дөрләп яткан уттан-ялкыннан
Иңрәп, кулын суза карт-корылар,
Бала-чага һәм тол хатыннар...

Күтәралсаң, күтәр күз карашын...
Ачы җиңелү сөремен иснәгән,
Орышлардан шашкан һәм саташкан,
Әмма хурлык җамын эчмәгән

Фидакарьләр-фидаиләр әнә
Пыскып яткан бүрәнәләргә,
Кыздырырга салган бәрәннәрдәй,
Кул-аяктан бәйләнгәннәр дә —

Үлем көтә...
Көл-күмергә калып вәйран булган
Канлы ярам —
Шәһре Болгарым,
Хәрабәләреңнән күтәрелмәк,
Тормак була соңгы улларың...

Әмма батырларның аягына
Елан булып мәкер урала,
Хыянәт-мәкер...
Килер җиңүләрнең
Канын эчә —
Үлем юк аңа.

Батырлыкны без үлемсез дибез.

Хыянәтләр дә шулай үлемсез —
Гасырлардан гасырларга күчә...
Сезме хыянәтне белмисез,

Бүгенгенең гамьсез ир-атлары?
Сәясәткә кереп батканнар?
«Юлбашчы»ның корыч исеме белән,
Хыянәткә төреп,
Меңнәрне соң кемнәр атканнар?

Шәһре Болгар!
Һәлак булганнарның
Күккә ашты микән җаннары?
Җир дә, күк тә сыйдырып бетермәсә,
Кая барырбыз соң аннары?

Үлгәннәрнең рухы тынлык сорый...
Дөнья кумак була исәннәр.
Шәһре Болгар!
Хәрабәләреңдә
Тик битараф җилләр исәләр...

*1985*

## Ык әрәмәләренә карап моңлану

Югаласыз бигрәк әрәмгә лә,
Бала чагым үткән әрәмәләр!
Диңгез төпләрендә сез каласыз...
Мин каңгырыйм,
Гүя кош —
Баласыз...

Шауламагыз моңсу, ичмасам ла...
Инде һичкем сезгә һичкайчан да
Аяк басмас,
Килеп печән чапмас...
Язын кайткан кошлар оя тапмас...
Болыныңда күкрәп печән үсмәс,
Чәчәк исе килмәс,
Җиләк пешмәс...

Бомбовоздай төклетуралaрың,
Йоклаганда кышкы йокыларын,
Тончыгырлар су астында калып...
Кемгә барыйм аһ-зарларым алып?

Югарыда —
Түрә-гигантоман!
Кирәк, имеш, аңа гигант һаман.
Бу якларга килеп КамАЗ корды —
Ата-бабам җирен кырды...
Кырды...

Инде сезнең чират, әрәмәләр!
Калмас сездән хәтта хәрабәләр:
Диңгез йотар сезне,
Дулкын ашар,
Ислам байрагыдай яшел башлар!

Моңсу шаулыйсыз да шып тынасыз,
Янә шаулашырга тотынасыз —
Җыелгансыз гүя митингка...
Шаулашасыз әмма бер дә юкка:

Сезнең телне аңламый шул адәм...
Адәммени?
Ул бит гигантоман!
Бәгырьләрем,
Яшел ялларым ла,
Балачакның кыргый тайларыдай,
Өер-өер чабып китегез сез —
Дөньяларны хәйран итегез сез!

Киталмыйсыз...
Сезнең тамыр җирдә...
Тамырсызлар шундый әмер биргән:
Су астына сезне күмдерергә!
Гүя шулай гүргә иңдерергә...

Газизләр сез миңа,
Сез бик газиз!
Әмма сүзем көчсез...
Мин бер гаҗиз...
Мин җырларга тиеш ГЭСны мактап,
Дулкыннары киткәч сезне каплап.

Әмма чыкмый,
Беткән минем тавыш...
Йөрәгемдә —
Таллар,
Зифа камыш...
Тамагымда —
Төер...
Ничек җырлыйм?
Аһ орыйм да аны кемгә юллыйм?

Ишетмиләр...
Бар да саңгыраулар!
Кайтавазда тик буш яңгыраулар...
Әрәмәләр,
Сезне яклый алмыйм,
Күкрәкләрем белән каплый алмыйм.

Шаулашасыз бигрәк моңсу-моңсу...
Күземдә яшь —
Миңа бик ямансу...
Югаласыз бигрәк әрәмгә лә,
Кичерегез мине,
Әрәмәләр...

*1974—1986*

# Куропаты корбаннары

Белоруссиянең Куропаты урманында шәхес культы корбаннарының йөзләрчә каберлекләре табылды...
*Газеталардан*

Телгә килсә,
Һәр агачы сөйләр

Куропаты урманнарының:
Егерменче гасыр курганнары —
Шәхес культы корбаннарының,
Курганнары анда...
Йөзәрләгән...
Адәм башы агач санынча!
Бүген кемдер кача-поса гына
Иптәш Сталинны сагынса —
Шунда барсын!
Чокыр төпләреннән
Төннәрендә салкын өрәкләр
Күтәрелә...
Кем газизе алар?
Өзелеп төшкән кайсы йөрәктән?

Канлы таңнар...
Каһәрләнгән көннәр...
Кара төннәр булган бер тәмуг...
Куркып калтыранган яфракларга
Адәм каны торган гел тамып...
Сискәндереп...
Тамып түгел —
Агып!
Ул юынган сезнең каннарда!

И шәһитләр,
Күпләрегез һаман
Инанган бит әле аңарга.
Аның исеме беләм таң аткан да,
Аның исеме белән көн туган.
Һәр күңелгә аның исемен шулай
Даһи исем итеп кем уйган?
Үзе!
Мөритләре!
Аның исеме белән бала көлгән...
Шул көлүдән алгы елларда
Курку-өркү катыш нәфрәт үскән
Безгә калган илереп еларга...
Көлү — каһәр!
Көлү — каргыш-ләгънәт!
Көлү — зәһәр!
Көлү — үч-ачу!
Көлү — үлем...
Үлем лагерьлары
Булып шыткан көлү, кыскасы...

Илгә ябырылып яу килгәндә,
Ут ташкыны ялмап барганда,
Ватан-ана йөзе шул ялкыннан
Үткен кылыч төсле янганда,
Авыл-калалары —
Күкрәк яралары, —
Яралардан ал кан тамганда,
«Ватан-анам!» диеп,
Аны яклап
Кул сузасы асыл ир-атлар,
Ил калканы булып өлгермичә,
Тутырылган һаман тураклап...
Тутырылган...
Хәзер инде алар,

Кубарылып,
Гомум кабердән
Кабер тынлыгында күтәрелеп,
Саф-саф булып,
Горур һәм бердәм
Яуга китсеннәрме?
Ни әйтсеннәр?
Өн-авазы кемгә меңнәрнең?
Искән җилгә бары...
Аккан суга...
Корбаннарның —
Асыл ирләрнең
Рухлары соң ничек әрнемәсен:
Алар да бит Җиңү көнендә
Теләгәндер медаль чыңы тыңлап
Утырырга өе түрендә...

Куропаты...
Шул ук тирәләрдә
Ватан өчен изге сугышта
Башын салган тагын күпме ирләр
Алар бар да бер үк сулышта...
Бер тын, бер сулышта...
Алар өчен
Үлем — изге,
Үлем — хөрмәтле...
Ә болары —
Культның корбаннары
Үлемне дә артык күрмәкме?
Ул өрәкләр илереп ялварадыр
Төннәрендә:
«Илем, арала
Нахаклардан...
Без дә тугры балаң —
Үги балаң итеп карама!»
Бер гаепсез күпме җан кыелган,
Исәннәре Алла итсенгә,
«Бөек юлбашчы!» дип,
Бер тиранны...
Тарих, шулай диюен дисең дә...
Халык хөкеме булыр гадел хөкем:
Ачыласы серләр, һай, тирән...
Җавап тотар өчен җитәр микән,
Җитәр микән бары бер тиран?

*1988*

## Балыкчы һәм дулкыннар

Көзге көн, ямьсез көн,
Салкын җил үкерә.
Иделдә балыкчы
Җилкәнен күтәрә.

Күбекле дулкыннар
Бу хәлне күрделәр,
Балыкчы бабайның
Янына килделәр.

— Исәнме, карт! — диеп
Дәштеләр аңарга.
Дулкыннар тавышы
Бәрелде ярларга.

Салынды эшләпә,
Иелде карт башы:
— Саумысыз, дулкыннар,
Минем хәл бик яхшы.

Дулкыннар шаулады:
— Тыңла син, тыңла, карт!
Бу безнең, ахрысы,
Сөйләшү соңгы кат.

Актарып, җимереп
Иделнең бозларын,
Килдек без дөньяга,
Тудык без язларын.

Бер ярсып, бер тынып
Талпындык җәйләрен;
Көттек без көймәләр
Җилкәнен җәйгәнен.

Мәһабәт кораблар
Тибрәттек күкрәктә;
Яшәдек ашкынып,
Яшьнәп һәм күкрәп тә.

Нигәдер арыдык,
Авырайдык көзләрен;
Яратмый башладык
Көймәләр йөзгәнен.

Йөрәктән ярсу дәрт,
Кыюлык, көч китә;
Чалардык, агардык —
Кыш җитә, кыш җитә.

Ачудан ятьмәңне
(Тыңла син, тыңла, карт!)
Ярларга чыгарып
Атабыз соңгы кат.

Көймәңне кыйныйбыз
Котырынып, яңаклап...
Нигә без үләбез? —
Табалсаң, җавап тап.

Дөньяны күп күргән
Син, Хода бәндәсе:
Бармы соң, әйт әле,
Яшәүнең мәгънәсе?

Балыкчы болай дип
Сөйләде аларга:
— Күрәмсез, минем дә

Чәчләрем агарган.

Минем дә бар иде
Ярсулы чакларым;
Ә быел, туганнар,
Сиксәнгә атладым.

Ай озын, һай озын
Үтелгән юлларым;
Кипшенгән кытыршы,
Сөялле кулларым.

Тормыш ул — каршылык:
Сөю бар, нәфрәт бар,
Туу бар, үлү бар,
Шатлык бар, хәсрәт бар.

Әгәр дә дөньяга
Килгәнсез икән сез,
Иртәме йә соңмы —
Барыбер китәрсез.

Аңламыйм, дулкыннар,
Мин сезнең аһ-зарны;
Монда соң еларлык,
Сыкрарлык эш бармы?!

Киң Идел, ярсынып,
Ташканда ярлардан:
Шат, шаян дулкыннар
Шауларлар яңадан.

Үлемнән куркып, ник
Шыңшырга, еларга?
Гомерегез ялкынын
Бирегез шуларга.

Сорагыз хет кемнән,
Әйтерләр һәммәсе:
— Тик шунда, туганнар,
Яшәүнең мәгънәсе.

*1962*

## Күз яшедәй күл яше

Син, яшь егет, нигә
Минем янга килдең?
Нинди уйлар белән
Өстемә иелдең?
Күрергә телимсең
Яшьлегемне минем?
...Кызлар күзе кебек
Зәңгәр сулы идем.
Төшәр иде кызлар
Коеныргa кичен —
Тезелешеп йөзгән
Аккошлармы дисең!

Тыгыз күкрәк төсле
Тыгыз дулкыннарым
Тыгыз күкрәкләрен
Юды ул кызларның.
Булыр иде шунда
Берәр ялгыз көймә,
Ә көймәдә... икәү...
Серләшсеннәр — тимә.
Шул сылу кызлардан
Һич тә калышмады
Матур җырлар белгән
Зифа камышларым.
Кояш яктысында
Янды төнбоеклар,
Нәни кояш булып
Янсын — төнен йоклар.
Уйнар иде җәйнең
Айлы төннәрендә
Айдай сазаннарым
Камыш төпләрендә.
Кыр казлары язда
Каңгылдашыр иде,
Авазлары дөнья
Яңгыратыр иде.
Йон йомгагы түгел
Камыш арасында —
Тырпылдашып үсә
Үрдәк баласы да.
Чоңгылымда җәен
Суны бутар иде;
Үрдәк кенәме соң,
Казны йотар иде.
Якын урманнарга
Барып кер әле син:
Адашырлык иде
Тукай шүрәлесе!
Бала-чага килсә,
Куркып торыр иде —
Әкияттәге дию
Миндә булыр иде.
Әкият тыңлап үскән
Зәңгәр күзле кызлар,
Зәңгәр суым мактап,
Җырлар иде җырлар...
Син, яшь егет, нигә
Минем янга килдең?
Нинди уйлар белән
Өстемә иелдең?
Тынчу суларымда
Кул-битеңне юма;
Алтын балык көтеп,
Кармак атма миңа.
Сорап торма миннән:
«Үләсең, — дип, — нидән?»
Җавабын үзең тап —
Кибәм һаман, кибәм.
Әйт үзең: бу әллә
Бозлыклар чорымы?
Урманым кырылды,
Камышлар корыды.

Күл түгел — сазламык...
Тапталдым, тапландым,
Бака үлән катыш
Ләм белән капландым.
Хәзер инде килми
Авыл кызлары да,
Миңа сәлам бирми
Авыл казлары да.
Әллә соң зәңгәр күл
Заманы үттеме?
Заманча кешегә
Кирәгем беттеме?
Аңламыйм мин генә,
Мин генә юләрме:
Хөрмәтлимсез әллә
Тик үле җирләрне?
Хак булса, кач син, кач!
Кыйнама җанымны...
Китмисең... Кем елый?
Әллә вөҗданыңмы?

*1968*

## Ай нидән сары, нигә салкын?

Ул заманда
Якты җир йөзендә
Кешеләр булгандырмы-юктырмы?
Җылытканмы Кояш бер файдасыз
Йокымсырап яткан буш кырны?
Сугарганмы яңгыр ел да үсеп,
Ел да черегән ятим игенне?
Гөлләр чәчәк аткан кирәксезгә,
Кошлар сайраганнар тигенме? —
Белмәгәнне белмим,
Гөнаһына кермим,
Һич алдарга сезне теләмим.
Айның менә нидән сарылыгын,
Нигә салкынлыгын беләм мин.
Картлар сөйли,
Димәк,
Халык сөйли —
Халык сүзе һәрчак хак була.
...Борын заманнарда Ай тапсыз һәм
Яңа яуган кардай ак була.
Ай-яй матур булган җирнең кызы —
Гүзәлләрдән гүзәл Айбикә.
Нәрсә-нәрсә,
Әмма матурлыкка
Җир дигәнең гаҗәп бай бит, ә!
Ә дөньяга көнне кем тудыра?
— Мин! —
Дип җавап бирә шар-Кояш.
Һай,
Ул ут шар!
Һаман кайнар,
Якты —
Үзенә бит инде шактый яшь.
Кояш-картлач шундый хәйләкәр ул.

Акыллы Җир аны бик белә.
Яхшы белә,
Шуңа күрә менә
Якынайсын аңа ник кенә!
Тик Айбикә-гүзәл киңәшләргә
Колак салырга да теләми:
— Кояш миңа гашыйк,
Минем өчен
Шулай нурлы итеп көлә, — ди.
— Ерактагы Кояш җылы була,
Якын барсаң —
Өтә,
Яндыра.
Син, кызкаем,
Артык мавыгасың,
Җир-әнкәңне онытып калдырма.
Тыңла сүзем... — диеп,
Җир никадәр
Үгетләгән аны.
Ә теге...
Тыңламаган.
Җаен китереп, ул
Качып киткән, диләр, бер төнне.
Ана күңеле һәрчак балада шул,
Кем соң белми ана йөрәген.
Җир уянган шомлы сискәнүдән:
— Айбикәм!
Ай...
Балам...
Юләрем...
Моңа кадәр беркем ишетмәгән
Үзәк өзгеч андый тавышны.
Кояш хәтта калтыранып куйган,
Айбикәне,
Көткән табышны
Нур-куллары тота алмый калган, —
Җирнең кызы артка сикергән...
Сикерсә дә,
Барыбер ычкынмаган
Сөю дигән усал сихердән.
Шар-Кояшны сөю хисе белән
Ана сагышы көче бертигез.
Урталыкта калган Айбикәбез
Үкереп елый!
— Ярдәм итегез!
Әнкәсенең җылы кочагына
Атылыр иде —
Кояш җибәрми.
Кояшына табан очар иде —
Ана сагышын соң җиңәрме?!
Ачы кайгысына түзә алмый
Җир упкыннар ясап уелган;
Айбикәнең кайнар күз яшьләре
Яңгыр булып шунда коелган.
Океан-диңгезләрнең суы тозлы,
Җир кызының яше аларда.
Җир йөзенә чыккан җыерчыклар
Әйләнгәннәр, диләр, тауларга.
Елап яше беткән,
Төсе киткән,

Сары лимон кебек саргайган,
Йөрәге туңган мескен Айбикәнең...
Кояш исә алтын сарайдан
Һаман көлә биргән...
Аңа нәрсә
Җирең,
Айларыңның газабы...
Хәсрәт белән шулай тәмамланган
Бу акылсыз гыйшык азагы.

*1963*

## Сагыш йорты — шәһәр бакчасы

Яшел шәл бөркәнгән карт юкәләр
Моңаешып тезелеп торалар:
Бүген янә бакча аһәңенә
Бетмәс сагыш килеп урала.
Бүген янә,
Ябык иңнәренә
Кара шәлен салып,
Ул килде.
Ел да шулай килә,
Ел да килә...
Ярты гасыр килә бит инде!
Кара шәлгә салмак карлар ява —
Чәчәк койган чагы сиреньнең.
Ул утыра ялгыз утыргычта,
Сүзсез мыймылдатып иренен.
Төштә түгел,
Өндә...
Өндә иде —
Шаһит менә шушы утыргыч:
Танышканнар иде алар монда,
Бакча фонарьлары ут алгач.
Җылы июнь иде.
Яшьлек кебек
Гүзәл иде дөнья,
Шат иде.
«Иркен минем туган илем!» диеп
Җырлап кына йөргән чак иде.
Таныштылар...
Аннан кавыштылар —
Чәчәкләре сулды сиреньнең,
Сирень исе сулап йөрер көне
Беткән булган икән иренең...
Ике атна яшәп калды алар!
Кичләрендә шушы бакчага
Көн дә килә иде бәхетле пар...
«Нинди күркәм алар, баксана!» —
Дигән төсле шаулап,
Яшь юкәләр
Иеләләр иде сиреньгә.
Ә ул, —
Күбәләк җан, —
Җылы эзләп,
Сыеныр иде һаман иренә.
Көн килде дә,
Шушы утыргычта

Йолкыдылар аны иреннән.
Өзгән сиреньмени?! —
Ятып калды
Һушы китеп ауган җирендә...
Бер гаепсез гаип булды ире —
Хәбәр дә юк аннан,
Кабер дә...
Ә ул, —
«Халык дошманы»ның тол хатыны, —
Илле елдан соң да,
Хәзер дә
Өметләнеп көтә...
Аның өчен
Сагыш йорты —
Шәһәр бакчасы.
Сүнәр-сүнмәс янган өмет шәме —
Сагышыннан кая качасың?..
Ул утыра ялгыз утыргычта.
Сибәли дә июнь яңгыры,
Тартынгандай итеп тынып кала.
Ә карчыкның битен яндырып
Сагыш агып төшә...
Ачы сагыш...
Шәһәр шау-шулары ерактан
Килеп керә —
Котсыз тимер чыңы
Телеп үтә гүя йөрәктән.
Шырык-шырык килеп,
Шәрран ярып,
Яшүсмерләр уза йөгереп.
Парлар үбешәләр,
Көлешәләр... —
Уза шулай тормыш җилдереп.
Гамь-хафасыз битарафлыклардан
Аралачы, тормыш,
Арала!
Сиреньнәрнең чәчәк койган чагы —
Сагыш койган чагы ярага...
Яшел шәлле карт юкәләр йотар
Ул сагышны алгы көннәрдә:
Кичке эңгерләрдә эри инде
Кара шәлле ялгыз күләгә...

*1988*

# Ярымшарлар

*(Триптих)*

**I**

«Озата барма, бәгърем,
Озата барма...»
Әй, җыр!
Үчекләмә мине,
Котыртма.
Гыйшык арбасыннан тартып алып,
Сагыш арбасына утыртма.
Җыр туктый да,
Кызый туктамый бит,

Адымы белән
Йөрәк тибешемне кабатлый.
Тук-тук, тук-тук! —
Биек үкчә мине
Тротуарга гүя кадаклый.
Кем ул?
Нинди кызый?
Әллә инде
Такташ шигыреннән төшкәнме?
Йә булмаса бөек Рафаэльнең
Полотноларыннан күчкәнме?
«Таныш түгел елмаючы»мы ул,
Әллә миңа күптән танышмы?
Туганнан ук йөрәк эзләп йөргән
Бердәнберем,
Асыл табышмы?
Тук-тук, тук-тук!
Тукта!
Ишетми лә...
Подъезд.
Ишек.
Ишек ябылды.
Ишек тавышы телде җанымны —
Һәм...
Җир шары шартлап ярылды!
Ах,
Нәрсә бу?
Төннең киңлегендә
Тирбәләме ике ярымшар?!
Алар, ахры, безне аерырга
Бер-берсеннән көнләп ярыша.
Кызны йоткан ярымшарга карап,
Үз җиремә ныграк сыенам;
Исән калуыма сөенәм...
Сөенәм дә
Тагын көенәм...

**II**

Төн.
Тар бүлмә.
Тәрәзәдән салкын ятагыма
Китек айның нуры коела.
Нур коела ак төтеннәр булып,
Аннан тула ачык куенга.
Их, ай нуры,
Әгәр үзең белән
Шул кызыйны алып керсәңче!
Ак төтенле бушлык юрганыңа
Икебезне бергә төрсәңче...
Төн.
Тар бүлмә.
Кемдер тәрәз кага...
Бәлки, улдыр?!
Шашынып кузгалам.
Тәрәзәмдә —
Өрәңге ботаклары...
Алар, ахры, мине кызгана.
Аның тәрәзен дә шакыйлардыр...

Тыңла, кызый,
Тыңла:
Ул — сагыш.
Минем сагыш...
Бераз миһербаның булса, төш!
Калтыранган кулың белән тиз-тиз
Ачык изүеңне капла да
Барып кара —
Кем ул анда шулай?
Өметләрен аның таптама.
Өрәңгеме?
Ә ул өрәңгегә
Минем сагыш калды сарылып...
Әллә өрәңгенең яфраклары
Тикмә сулган,
Тикмә сарымы?
Мин саргайттым аны сөялеп торып...
Айга кара —
Сары китектән.
Ул гомерендә барлык гашыйкларның
Газапларын җыеп интеккән...
Гүзәл кызый!
Сары өрәңгенең
Бер яфрагын өзеп ал әле,
Өзеп ал да
Иркә көтә торган
Күкрәк өстеңә үк сал әле!
Ала...
          сала...
                 тыңлый...
                    аңлый...

Аннан,
Бик кадерләп куеп учына,
Ирененә тидерә,
Ирененә...
Ярымшарлар кабат кушыла...

**III**

Тын.
Таң ата.
Таң йокыны куа.
Алда —
Таза иртә,
Кояшлы.
Төнге хисләреңнән айну өчен
Хет чыгарып җиргә куй башны!
Тукта!
Җир икегә ярылмаганмыни?
Әй, ягымлы,
Матур җиркәем!
Исән икәнсең бит,
Кил,
Кил әле:
Кочагыма алып иркәлим...
Икебез дә бер үк планетада —
Ярымшарлар түгел,
Тулы шар...
Алай гынамы соң —

Бер шәһәрдә...
Йөрәккәем,
Йөрәген яулар өчен
Сугыш, бар!

*1962*

# Поэмалар

Кайгылы көннәрнең,
Йокысыз төннәрнең
Күпмесен күтәрдең,
Йөрәгем?
Күпмесен күтәрдең,
Күпмесен үткәрдең
Яшендәй этәрдең,
Йөрәгем?

## Шәймәт карт

**Көз**

Туктамаска түнде яңгыры да,
Күкнең төбе, ахры, тишелгән;
Икенче ай коя, хәерсезең,
Оялырга иде кешедән.
Урсаң — сугып, суксаң, җыеп булмый...
Ат тезеннән пычрак юлларда;
Күңелләргә шомлы хәбәр салып,
Икмәк үреп ята кырларда.
Алласы да артык картайды шул,
Акылы да кими барадыр;
Бер дә юньләп көнне бирә белми,
Ахры, эшләмичә арадыр.
Әйтче, Акбай, әллә һич булмаса
Алмаштырыйк микән Алланы?
Тәүбә, тәүбә!
Кара, Ходай үзе
Шаярганны бер дә аңламый.
Яшен белән куркытмакчы була,
Исем китте!
Әйдә, дөбердә.
Тик онытма:
Күккә хуҗа булып
Торалмассың әле гомергә.
Миннән булмас,
Әмма оныкларым
Күптән көлә инде үзеңнән;
Ракет белән бәреп төшерерләр,
Бик кәпрәеп торсаң, күгеңнән...
Их!
Амбарларым буш капчыктай әле.
Нәрсә саклыйм,
Коры амбармы?

Тукта, Акбай, икмәк китерәләр,
Җилләтергә салыйк.
Аннары...
Акбай, Акбай...
Картайдык шул бераз,
Син дә
Тоталмыйсың хәтта куян да.
Ярар...
Көзге яңгыр кояр-кояр да
Кышка керер.
Без дә шулай инде:
Кышка кердек.
Сакалга да карлар яудылар;
Яшьлек дәрте, кызу чаклар, туган,
Күптән инде артта калдылар.

**Кыш**

Тышта буран.
Морҗа башларыннан
Сызгыра ул явыз, котыра.
Тышта буран...
Минем күңелемдә
Кара мәче чинап утыра.
Шулай, туган, савытларда инде
Дарың беткән, диләр, тотылып.
Пенсиягә чыктым — ял итәргә,
Мич башында гына утырып.
Пенсиягә чыктым —
Персидәтел:
— Ял ит инде, Шәймәт бабай, — ди, —
Яшең инде сиксән бишкә җиткән,
Бик борчылма, яме, алай, — ди.
Мошенникны әйтәм, сөйли белә!
Саклык белән юкә чөй кага.
Эх,
Бер ун яшьне ташлап булса иде,
Күрсәтер лә идем мин аңа.
Юк шул, булмый.
Инде койрыкны
Сыртка гына калды саласы.
— Яшь яшәлгән, ашың ашалган бит —
Үлсәң, вакыт, — диме Алласы...
Акбаем да санга сукмый хәзер:
Чыгып китсә — кайтмый, хәерсез!
Йортта ямь юк,
Тәм юк тормышымда,
Күңел боек, никтер кәефсез.
Кая, карчык, бирче киез ката:
Барыйм әле Гайфи янына.
Парторг бит — аңлар.
Якасыннан алам:
— Эш бир, туган, — димен, — ялынам. —
Шәймәт бабаң әле — иске балта —
Кирәк булыр сөяк чабарга.
Ашыкмагыз, — димен, — бик тиз генә
Мич башына тотып ябарга...
Тышта буран.
Әйдә, котырсын ла!
Түбә кыекларын тутырсын.

Киттем, карчык.
Кичке намазыңны
Миннән тынычланып укырсың.

**Яз**

Тамчы тама.
Яз ул, туган, карны гына түгел,
Каткан йөрәкне дә эретә.
Эх!
Чыгасы иде колхоз кырларына,
Туймас идем йөреп-йөреп тә.
Әле ярый Гайфи аңлап алды:
— Эш табарбыз, — диде, — боекма.
Күңелеңнең чите кителмәсен,
Һич пошынма, — диде, — син юкка.
Аңламаска, коммунист ул, туган,
Әйбәт кеше, рәхмәт төшкере!
Сөялләнеп каткан кулларга шул,
Тик эш булса гына, көч керә.
Әйе, Акбай, тиздән чәчү өсте —
Сабанчылар чыгар басуга.
Авызыннан сөте кипмәсә дә,
Тракторда.
Бераз гына килә ачу да.
Ник, мин әйтәм, без яшьрәк чакта
Булмады соң шундый мөмкинлек?
Йөрер идек без дә тимер атны
Акыл белән җигеп, ду килеп.
Һәй,
Ул гына булыр идемени,
«Сугыш» дигән каһәр булмаса;
Валла, коммунизм төзер идек,
Кайбер этләр киртә кормаса.
Нәрсә, Акбай, риза түгелмени?
«Эт» дигәнгә кәефең киттеме?
Үпкәләмә.
Этләр төрле алар...
Шул шул, туган, барып җиттеме?
Ярар.
«Үткән эшкә салават», — дип
Түгәрәклик сүзне монда да.
Теләк шул бер: инде янә
Тыныч кына булсын дөньялар.

**Җәй**

Кояш, Акбай, ай-һай, шәп кыздыра!
Кырда халык янган-пешкәндер;
Авыл тып-тын.
Бер җан иясе юк.
Мире белән эшкә төшкәннәр.
Ә без монда арка кыздырабыз,
Калкавычка карап утырып.
Син дә ялкау.
Яле, өр, ичмасам,
Ятма әле корсак тутырып.
Ярый әле бу эш җайга килде —
Безнең кулда колхоз буасы.
Шулай инде, Акбай, аягыңны

Юрганыңа карап сузасың.
Нигә?
Әллә начар эшме, туган?
Балыкларга башлык иттеләр.
Тама торгач, тамчы ташны тишә —
Безнең эшләр хутка киттеләр.
Карп бит ул, мәйтәм, ит капчыгы,
Нигә үрчетмәскә?
Суы бар...
Әһә, Акбай, әбәт җиткән икән,
Каланчада әнә сугалар.
Ут яңартыйк, балык салыйк әле,
Карчык-мыштыр килеп җиткәнче,
Пешә торсын.
Ул да ашап китәр,
Үзебез генә авыз иткәнче.
Шулай, туган, безнең эш түгәрәк, —
Утыр шунда балык сагалап...
...Ә дөньяда күпме үзгәрешләр!
Бетерерлек түгел чамалап.
Шулай, Акбай, без картая диеп,
Тормыш картаймый бит ул, туган.
Иделне дә әнә диңгез, диләр;
Казан, диләр, бик зур порт булган.
Әйтик, нефть.
Әле кайчан гына
Исемен дә белми идек бит.
Сукыр лампа өйдә пыскыганда,
Почмакларны күрми идек бит.
Хәзер әнә вышка дигәннәре
Борын чөеп күккә караган;
Дога укып түгел, фәнне җигеп
Нефть чыгаралар аңардан.
Спутнигы йөри, ракеты бар,
Инде әнә айга менәләр.
— Шәймәт бабай, ташла буаңны, — дип,
Шуннан торып бездән көләләр...
Кояш өтә, Акбай!
Кыздырсын ла!
Зыяны да шуның кадәрле.
Нигә шунда баш-баш ташлар яумый —
Тормыш без дигәнчә тәгәри.

*1956—1961*

# Яңа җыр

**I**

Яратам мин Казанның
Мәшһүр Кабанын.
Урамнарның асфальт яңагын
Сыйпый-сыйпый аргач табаным,
Салмак адым белән
Мин бирегә киләм:
Яшькелт дулкыннарның уйнавын,
Ишкәкләрнең суны кыйнавын,
Чуар яр буйларын —
Барын күзәтәм.
Аннан

Тукай бакчасына юл алам.
Анда
Яңа газетларга борын төртеп
Тынып калам.
Бу бакчаның беләм мин һәр кешесен:
Олысын, кечесен.
Чал профессор,
Озын буйлы маляр,
Студентлар,
Эшчеләр, —
Мехкомбинаттан алар, —
Билгеле,
Һәр бакчада булган кебек,
Бар парлылар,
Парсызлар...
Һәм бар оныкларын комда аунатучы
Пенсионер карчыклар.
Без —
Бер гаилә:
Бу бакчага һәм Тукайга гашыйклар.
Дөрес,
Бирегә керүче, үтеп-сүтеп йөрүче,
Кыскасы, очраклы халык
Аз түгел.
Ләкин бүген
Мин аларга тормыйм тукталып.

**II**

Бүген мин сөйлим...
Тукта!
Нигә соң әле бакчада мин
Мулланурны күрмим?
Әллә тагын бер-бер хәл булганмы?
Эшендә күңелсезлекме, өендәме?
«Тагын», — дидем.
Әйе, ул минем...
Бик еш боза канны:
Мин аның өчен көенәмен,
Аның өчен сөенәмен,
Сәер кеше ул
Ташчы Мулланур.
Кайберәүләр әйтмешли,
Тәмам прокурор булган ул.
Прокурор җир йөзенә —
Аның йөрәгендә Алжиры да,
Кубасы да,
Конгосы да...
Прокурор үз-үзенә —
Туктаусыз камчылый вөҗданын да,
Кызганмый үз данын да,
Бирергә әзер газиз җанын да —
Саф дөреслек, тугрылык өчен.
Ул прокурор.
Ләкин җитми көче...
Мулланур — ташчы.
Бригадада девиз:
Коммунистларча
Эшләргә, укырга, яшәргә!
Без шулай дибез.

Бу җиңел тоела кайбер яшьләргә,
Ләкин Мулланурга
Килә авырга.
Аны кызыктырмый
Яңгыравык һәм ялтыравык исем;
Аңа кирәк
Бөтен тормышында,
Кол булмыйча бары эш нормасына,
Янып яши торган җисем.
Ә җисем —
Кеше булып калу һәр эштә.
Билгеле,
Көндез кирпеч өйгәндә,
Кичен дәрестә
Яки урамда,
Иптәшләрең белән булганда,
Мөмкин кызылланырга
Һәм,
Вакытлыча булса да,
Бу исемне алырга.
Юк,
Алай түгел ул Мулланурга!
Аңа кирәк
Исемнең йөрәккә үтүе — кан булып,
Кирәк әверелүе вөҗдан булып.
Эштә Мулланур бирә ике норма.
Ә менә вөҗданның нормасы бармы?
Булса,
Үлчәнә ул ничек?
Менә шушы мәсьәләне
Бир син чишеп.
Мулланурны исә
Тагын бернәрсә кисә:
Хатыны Рәмзия
Тәмамлады вузны,
Ә Мулланур
Кичкедә укый әле тугызны,
Рәмзия укытучы,
Мулланур укучы,
Ни әйтсәң дә —
Аерма!
Ничек кенә каерма,
Сизелә-ә-ә...
Әйе,
Бетәр димә
Каршылыкларны тиз генә.
Алыйк гаилә тормышын.
Гаиләне бит
Ызгыш-талаш өчен кормыйсың,
Шулай да
Савыт-саба шалтыратмый тормыйсың.
Дөрес,
Кайберәүләр энәдән ясый дөя,
Ә икенчеләре дөяне дә энә дия.
Менә бер вакыйга.
Сорау туры да, катгый да:
Энәме бу, әллә дөяме?
Әйтегез,
Мулланур
Хаклыга янып-көяме?

**III**

Алсу иртә.
Әле җил дә кузгалмаган, черем итә.
Мулланурның кызы,
Дүрт яшьлек күз нуры,
Әлфия
Ак мендәрдә ята җәйрәп,
Аңа рәхәт, әйбәт!
Кичә ул
Кәримә апасы белән
Би-и-и-и-к озак уйнады,
Арып бетте.
Әниләрен инде кайтмас диеп уйлады.
Әниләре кинода иделәр,
Киткәндә
Кәримә апасына:
— Әлфияне карап торчы! — дииделәр.
Ә Кәримә апасы
Карап тормады:
Әлфиягә «Тамчы, там»ны җырлады.
Аннан икәү бергә
Әй тотындылар биергә!
Аннан качыш-качыш,
Аннан туп атыш,
Аннан
Ул Әлфияне кызык иткән:
Алдына алып тирбәткән,
Әлфия йоклап киткән.
Кәримә ул — күрше кызы,
Унда укый.
Болай бик сөйкемле үзе,
Һәрвакыт көләч, шаян.
Әлфияне бик ярата:
Күрсә,
Йөгереп килә әллә каян.
Шукланып аңа:
— Әлпи! — ди, —
Әйдә безгә, бирәм тәти, — ди.
Бала бит —
Керсез күңел,
Аңа ачык йөз, тәмле тел
Җитә:
Әлфия дә аны үз итә.
Алар уйнарга әзер икәүләп
Көндез дә, кич тә.
Әйе,
Кәримә Мулланурларда үз кеше,
Рәмзия дә үлеп тора аның өчен —
Бу гаҗәп түгел һич тә.
...Әле иртә.
Әлфия «бәү-бәү» итә,
Ә Мулланур эшкә китә.
Рәмзия бераз соңрак җыена
Һәм юл уңаенда
Әлфиясен бакчага илтә.
Менә шулай башлана
Бу гаиләнең хезмәт иртәсе.
Гади гаилә, гади кешеләр,

Миллионлаган алар ишеләр.
Ләкин тормыш булмый киртәсез.

**IV**

Мулланур сак кына иелеп
Кызын үбә дә
Урыныннан кузгала,
Үтешли комод өстенә күз сала
Һәм...
Туктап кала.
Юк,
Булмады бернинди хәвеф-хәтәр —
Комод өстендә
Бары берничә дәфтәр.
Мулланур башка вакытта
Тормас иде баш ватып та:
Укытучының аз буламыни
Өйгә, тикшерергә алган эшләре.
Тик бүген Рәмзия әллә нишләде...
Дәфтәрләрне ала Мулланур,
Укый:
— «Яшь гвардия»,
«Күтәрелгән чирәм»...
Тыныч кына сорап куя:
— Рәмзиям,
Бу ни бу?
Әллә инде әзер иншалар?!
— Ул... ни... Мулланур...
Кәримәгә кирәк алар.
Үзең беләсең бит,
Рус теле йомшак ул кызның.
Ә син, ахры, шикле нәрсә диеп укыдың...
Мулланурның тынычлыгы
Рәмзиянең телен ачты,
Баштагы аптырау, курку качты —
Ул ашыга-ашыга тезеп китте:
— Ләкин...
Син мине аңларсыңмы?
Грамматикада сай йөзә дип,
Кәримә соң
Көнен күрсен, көлдә аунасынмы?
Әнисенең институтка кертәсе килә.
Завод-мазарга бик яшь,
Авыр булыр, диләр.
Сочинениедән яхшы үтсә,
Кызның
Медальлек чамасы бар...
— Эх Рәмзия!
Утырдың кем чанасына?
Җырлыйсың түгелме
Базар хатыннары җырын?
— Кызма әле...
Сөйләп бетермәс борын.
Бүген мин мәктәптә дежур торам,
Кәримәләр этажында.
Ә бу дәфтәрләр...
Болай гына...
Бөтенләй яза алмаса,
Шул чагында...

— Кәримә үзе беләме?
Әллә эшләнәме бу эш
Ул белмәгән килеш?
— Әнисе
Мәүлидә апа аңа
Мәктәпкә киткәндә әйтергә тиеш.
— Димәк,
Астыртын гына кызга баз казыйсыз?
Сүз әйтерлек түгел, ярыйсы...
— Мулланур!
Ни сөйлисең?
Нинди баз?
— Рәмзия, оял бераз!
Кәримә зур тормышка,
Яңага аяк баса тиздән.
Ничек уйлыйсың:
Ул нәрсә көтә
Өлкәннәрдән, бездән?
— Мулланур,
Борчак кадәр мәсьәлә
Һәм...
Җир шарыдай фәлсәфә.
Күпертәсең болай нәрсәгә?
Үзең үк бит,
Берәр йомышың булса,
Хәзер Кәримәгә кушасың...
Онытма,
Без Әлфия өчен дә бурычлы.
Әйдә, әнисенең күңеле бушансын.
«Медаль алса,
Институтка кертергә
Җаен табар идем, — ди. —
Кайдадыр, ниндидер доцент
Танышым да бар минем», — ди...
Әгәр хәзер җир убылса,
Мулланур кереп китәр иде.
Бәлки, хатыны өчен кызаруы
Шунда эреп бетәр иде:
— Җитәр!
Шартлап ябылды ишек.
Чыркылдап уянган баласын
Юатсын соң ана ничек?

**V**

Әнә
Мулланур җил-җил бара,
Күзенә күренми ак һәм кара.
Мулланур,
Алдыңа кара,
Саклан —
Машина борылды чаттан.
Юк,
Ул карамый.
Ярый ла шофер шәйләде
Тормозга басарлык араны.
Кемдер этеп җибәрде читкә:
— Хатыныңны ятим итмә!
Кепка каядыр төшкән очып,
Шофер йодрык күрсәтә ишеген ачып.
Эх шофер!

Йодрык белән генә
Булса икән көйләп,
Тормыш булыр иде кура җиләк.
Менә Мулланур,
Юләр булган ул:
Ышана иде хатынына
Үзенә ышанганнан да артык.
Һәм күпме гомер
Мәҗнүндәй йөрде яратып!
Күзгә-күз карашып,
Ярты сүздән аңлашып,
Биш ел гомер сөргән Рәмзия,
Укытучы —
Шулай эшләсен, имеш?!
Ялган бу!
Саташу, төш.
Мулланур, ачуланма,
Өн бу, өн.
Ә синең уйларың —
Ярсуыңны капларга тырышучы
Зәңгәр төтен.
Ташла папиросыңны,
Күтәр башыңны.
Ачы булса да,
Хакыйкатькә туры кара —
Дөньяда юк төзәлмәслек яра.
Ләкин җиде үлчә, бер кис:
Бәреп япкан ишекне ачып
Кайтып керәсең дә бар ич.
Рәмзияң
Ачыргаланып кычкырып калды,
Ишеттеңме?
— Без Кәримәгә бурычлы!
Әллә ул алдый?
Әйт шигеңне.
Әйе,
Кәримәгә бурычлы алар,
Моны һәркем аңлар.

**VI**

Мулланур исенә төшерде
Беренче Май көнен.
Ул көнне сулышын өрде
Аларга үлем.
Алар, елдагыча,
Әлфияне күтәреп
Ирек мәйданыннан үттеләр
Һәм, елдагыча,
Кабан күленә киттеләр.
Кайчандыр шул күл буенда
Алар таныштылар.
Беренче Май иде,
Алар табыштылар...
Сөештеләр,
Көештеләр
Һәм кавыштылар.
Аннан соң күп сулар акты.
Күп җилләр исте —
Гаиләдә бер нәни артты...

Ә гадәт, булса да иске,
Калды:
Кабан күле аларны һәр майда
Кочагын җәеп каршы алды.
Әйе...
Алар шулай бу майда да
Кабан күленә киттеләр.
Аларга
Кәримә дә иярде бик теләп.
...Атаклы Болак күпере.
Ул көненә күпме кешеләрне үткәрә,
Ничәмә-ничә гашыйклар
Очраша бередә.
Бигрәк туры килгән шул җире дә:
Кольцо,
Тукай бакчасы,
Кабан,
Күпме трамвай-троллейбус җепләре
Биредә үрелеп туктаган.
Кыскасы — җиде юл чаты.
Синең тынгысыз йөрәгең
Шушыдыр ул, Казан!
...Атаклы Болак күпере —
Кабанның бетон маңгае.
Әйтче,
Каян туры килеп тора диң җае?
Мулланурга очрады Зөфәр, —
Алар бергә эшлиләр.
— Май белән, Мулланур!
Әйдә, бер көйрәтеп җиффәр!
«Җиффәрделәр»...
Ә Кәримә белән Әлфия
Йөгерделәр Кабанга.
Янәсе, барып җитәләр
Алданрак анда.
Менә Әлфия
Кәриманең кулыннан ычкына
Һәм йөгереп керә
Тар басманың аргы очына.
Бигрәк шаян бала!
Әнә ул иелеп учына су ала,
Әнә...
Югала!
— Әлфия!!!
— Кәримә!!!

**VII**

Машинада —
Ике юеш гәүдә,
Шофер, ку әйдә!
Урамда — бәйрәм.
Урамда — тантана.
Машинада —
Ике юеш гәүдә.
Кан тама... кан тама...
— Әл-фи-я-ә-ә!!!
Рәмзия кызына ташлана
Һәм үксеп ялвара:

— Кызым!
Ач күзеңне... йә, кара...
Үлмә, яме...
Бүген Май бәйрәме...
Үлем,
Үлем,
Кызым калсын инде!
Үлем, үлем,
Ал син мине!
Утыра Мулланур,
Көл төсле булган ул:
«Алганда судан
Юк иде,
Кайдан соң кан?..»
Шофер, мөгаен, уйларын укыган!
— Иптәш, кара:
Кулыңда яра.
Беткәнсең буялып,
Мә кулъяулык.
Димәк,
Кан тамган кулдан,
Мулланур аны каядыр бәргән булган!
— Кәримә, туңмыйсыңмы, үскәнем?
— Юк... җылынды инде тәнем.
Кәримә елмая, аңа рәхәт...
Мулланур аның беләген кыса:
— Кәримә, рәхмәт...

## VIII

Менә шундый бурыч турында
Сүз бара.
Йә, Мулланур,
Инде уйлап кара:
Әйтик, дөньяда
Диңгезләр, елгалар, чишмәләр
Берьюлы кибеп бетсәләр —
Су булмаса,
Ә кызың үләрдәй булып сусаса,
Рәмзия,
Бер тамчы чык тапса,
Нишләр иде?
— Әлфиянең иреннәрен юешләр иде!
Әгәр кызың сукырайса,
Күрмәс булса шат җир йөзен?
— Бирер иде ике күзен!
Әгәр җирне туфан басса?
— Кызын тагаракка салыр,
Барыбер аны коткарыр —
Батар иде үзе, батса!
Димәк, хаклы:
«Без Кәримәгә бурычлы», — дию?!
— Әйе, хаклы.
Ләкин укытучы намусы...
Мондый хурлыкның
Булганы бармы соң?!
Кәримәгә бит син дә бурычлы.
Нindидер сочинениеләр...
Бу соң шулай ук зур эшме?

Гаилә тормышына бармы зыяны?
Яки
Алдынгы ташчы исемеңне
Буяп куямы?
Иптәшләреңнән
Бу вакыйганы белми кем дә,
Үзең хуҗа түгелмени үз өеңдә?
— Әйе, берәү дә белми.
Әйе, берәү дә күрми.
Әйе, үзе хуҗа.
Ә соң вөждан?!
Мулланур төкереп куйды ачудан.
Юк!
Хәзер үк телефонга керәм
Һәм бу хәлне
Директорына җиткерәм!
— Мәктәп тыңлый.
— Миңа...
Рәмзия килмәдеме?
Шундый таныш,
Ягымлы тавыш
Ишетелде бераздан,
Ишетелде тонык булып,
Әйтерсең баздан:
— Кем бу?
— Уңыш телим «изге эшеңдә»! —
Мулланур сүзләрен
Сыгып чыгарды теш арасыннан.
Трубка шалт! итеп төште дә
Суккан кебек булды йөрәге ярасына.

**IX**

Һәрвакыт якты, киң коридор
Нигә соң бүген караңгы һәм тар?
Төссез, әллә нинди
Кояшның да нуры.
Баш та сызлый кебек,
Рәмзия әллә инде
Авырырга маташа?
Дәшсә телефон аша,
Килер иде микән Муллануры?
Кинәт ул күргәндәй булды
Иренең кырыс йөзен,
Ишеткәндәй булды усал сүзен:
— Уңыш телим!..
— ...Уңыш телим! —
Директор тынып калды,
Күзлеге белән сөзеп,
Классны барлап алды.
Утыз пар күз.
Үзенчә һәркайсы:
Берәүләренең бар кебек кайгысы.
(«Әгәр дә яза алмасам?»)
Икенчеләре гамьсез.
(«Өч булса җиткән.
Ярар утырып калмасам».)
Андыйлары карарга ук ямьсез.
Бар бик тынычлары.

(«Һичшиксез дүрт йә биш —
Яхшы беләм ич».)
Болары — ел буе тырышлары.
Ә менә бу кыз
Нигәдер тынычсыз.
Директор Кәримәгә карады
Һәм бик кыска арада
Тотып алды
Күзләренең як-якка йөгерешен,
Укыды ул алардан
Тойгылар көрәшен.
Директор чыкты.
Күзләр тактада,
Һәркем кирәкле теманы эзләп таба.

**X**

Коридор тып-тын.
Класслар тып-тын.
Рәмзия, нигә курыктың?
Директор
Күңелеңдә нәрсә барын
Белсен кайдан?
Кәримәгә
Тиярме бүген файдаң?
Намус һәм бурыч бәрелешсәләр,
Бигрәк читен лә!
Рәмзиянең фикерләре бүленә икегә.
Бүген Кәримәнең язмышы хәл ителә:
Яки заводка, яки вузга.
Кул сузарга кирәк ул кызга.
Тукта!
Син аңа
Сочинениеләр генә бирәсеңме?
Рәмзиянең күзе капшады
Стенадагы рәсемне:
Көләч көньякның тау-ташлары.
Биек кыя.
Кыяда оя.
Бөркет балалары.
Алар
Сары авызларын ачалар,
Күрәсең, ач алар.
Ә аналары тотып кайткан куян
һәм аны балалары алдына куйган.
Әйе,
Ерткыч ерткычлыкка өйрәтә.
Оясында ни күрсә, ни күрсә...
(Тәненнән көчле ток йөгерсә,
Анда да
Үзгәрмәс иде Рәмзия болай.)
...Шул була очканда да!
Шундый ук оя бит мәктәп тә,
Ә Кәримәләр —
Сары авызлы чебешләр.
Белем дә,
Тормышка мәхәббәт тә
Мәктәптә салына
Чебешләр авызына.
Укытучыдан башка

Бу эшләрне кем эшләр?
Ә Рәмзия, —
Әйтми булмый дөресен, —
Әзер сочинениеләргә төреп,
Кәримәгә укыта түгелме
Намуссызлык дәресен!
Нишләргә соң?!
Минутлар үтә,
Кәриманең чыгар вакыты җитә.
Рәмзия, бирерсеңме-юкмы?
Баса алырсыңмы йөрәгеңдәге утны?

**XI**

Класс.
Кичәге шук, шаян балалар
Сочинение язалар.
Алар
Дәфтәр юлларыннан
Тормыш юлларына
Күпер салалар.
Алар — егерме тугыз.
Утыз түгел нигә?
Чөнки язмый бер кыз.
Ул — Кәримә.
Директорның ягымлы карашына
Хыянәт итәрме ул?
Иптәшләре ышанычына,
Үзенең намусына,
Мулланур абыйсына —
Барысына
Төкереп үтәрме ул?
...Әллә соң язып карарнгамы?
Ул арада әнисе күзенә күренә:
— Кара эшче булып калыргамы?
Синең урын институтның түрендә.
Рәмзия апаң...
Ах, әни, әйттерерсең әллә ни!
Дәфтәргә беренче калтыравык хәреф
Һәм, кайнар терекөмеш төсле,
Күз яше төште.
Әйе, Кәримә үзе яза!
Ике юл яза да берсен сыза,
Ачу белән кат-кат боза.
Озакка чыдармы ул?
Әллә хәерче кебек теләнеп,
Рәмзиягә сузармы кул?

**XII**

Эш бетә.
Инде кич җитә.
Ах, кайтасы килми, килми;
Берәү дә
Мулланурның хурлыгын белми, белми.
Йөрәкне нәрсәдер кыса, баса.
Әллә соң борчулы уйларын
Аракыга күмсенме, булмаса?
Йә, нишләргә?
Салкын акыл, өйрәт.

Акыл рәхимсез:
Кайтырга кирәк!
Мулланур буйсына.
Ә аяк тартмый,
Бер туктый да бер атлый.
Мулланур хатынына дәшәргә сүз эзли —
Ләкин тапмый.
Иртәнге ярсу, ачу сүрелгән,
Бары тик кайдандыр тирәннән,
Йөрәк түреннән
Сыкраулы, әрнүле авырлык калка.
Һәр адым саен үсә ул, зурая,
Ирек бирми атларга алга.
Белмичә ару-талуны, йончуны,
Канатлар үскәндәй очынып
Өйгә ашкынган шат көннәр кайда?
Әйтегез, кайда?
Нигә ул болай,
Атлар-атламас өенә кайта?
...Кабан ягыннан җил исә,
Яңгыргамы әллә югыйсә?
Булсын иде.
Яуганы юк инде күптәннән.
Артык эссе —
Асфальт эри,
Эзләр төшеп кала үткәндә.
Асфальттагы эзләр бетәр лә!
Йөрәктәге әрнү үтәрме?

**XIII**

Кичке табын.
Кара-каршы ир белән хатын.
Шунда ук йөрәк җимеше —
Бала.
Инде ни кирәк тагын?
Ләкин
Тамак төбенә утырган таш —
Үтми аш.
Күзләр бер-берсенә карамый,
Авызлар йозакта.
Ир белән хатын уйлыйлар:
«...Мулланур, болай ярамый.
Сузма озакка:
Ачулан, кыйна — тик дәш!»
«Әйт, ни булды мин киткәч?
Рәмзия, сөйлә!
Ни йөз белән кайттың өйгә?!»
«Гаебем зур, Мулланур, кичер!
Театрга бармакчы идек кичен,
Билетлар кесәдә...»
Авыр тынлык.
Дәшмиләр берсе дә.
Әлфия түзмәде,
Чыраен сытты, елап җибәрде...
Мулланур атылып урамга чыкты,
Йөзенә җил бәрде.
Менә ул капка төбендә
Папирос пыскыта, уралган төтенгә.
Каршында шаулаша юкәләр,

Ахрысы, яңгырны көтәләр.
Камырдай кабара-кабара,
Болыты җыелган кай ара?

**XIV**

— Юк!
Болай калдыраммы соң?
Кызымны заводка алдыраммы соң?
Чәчрәп китим менә!
Иртәгә үк барам мәктәбенә.
Ах Кәримә, Кәримә!
Харап булдың, балам!
Рәмзиясен әйтер идем.
Юньсез!
Йа Аллам,
Нәрсә, ди.
Намуссызлык була, имеш.
Ә бала карату,
Бер тиен бирмәгән килеш,
Намуслымы?
Кәримәсе дә
Нигә табынадыр шуның Әлфиясенә.
Җебегән!
Үз дәфтәрләрен дә
Сорап ала алмаган,
Нинди эшче чыга инде аңардан?
Йа Аллам, йа Аллам!
Нишләр инде балам?..
Һаман кайтмый,
Йөри икән кайда?
Катырак бәрелдем шикелле,
Күңеле китек иде болай да.
Нишләп утырам соң,
Кара инде мин юләрне!
Капка төбенә булса да
Чыгып керим әле. —
Мәүлидә апа чыкты.
Мулланурны күрде,
Башта дәшмәде,
Күзенә тыгылды ачулы яшьләре.
Аннан ярсып пышылдады:
— Нишләп тора бусы тагы?
— Өстәде ишеттереп:
— Рәхәттер шул...
Кеше интектереп...
Их сез, күршеләр, ярдәмчеләр!
Ник Кәримә сарылып йөри сезгә,
Юләр...
Җилләнеп һәм җенләнеп
Кереп китте.
Чү, чү!
Нигә ул алай итте?
Димәк... димәк...
Һәм кинәт
Чатырдады яшен.
Ул, ертты да болытны икегә,
Күңелдәге авырлыкны
Юган кебек итте дә.
Юган кебек итте...

Ә йөрәктә
Утырып калды саргылт юшкыны.
Шулай инде,
Күңел яралары
Озак яши алар еш кына.
Мулланур ул бүген
Үзе белгән,
Бик менәсе килгән
Тауга тагын бераз үрләде.
Ул тау биек,
Алгы көннәрендә
Бик күп әле аның үрләре.

**XV**

Менә шулай үтте Мулланурның
Кешеләр өчен гади ул көне.
Кешеләр өчен гади, үзе өчен олы.
Дусларыннан аңа, йә, кеме
Әйтер икән:
— Молодец син! — диеп, —
Тагын җиңеп чыкты вөҗданың.
Бу көрәшне бирәү сизмәде бит.
Хәер,
Мулланурга
Мактауларның
Һичбер кирәге дә юк ла аның!
Аңа хаклык кирәк.
Ә тормыш ул синнән сорап тормый,
Бик еш кына
Кабыргасы белән баса ул.
Һәр гаиләдә бригада төзеп
Мөмкинмени контроль ясавы?!
Өч норма бир!
Кичке мәктәпкә йөр!
Болай итеп
Лозунглар ташлау җиңел эш.
Ә тормышта яшәү законнарын
Өйрәтергә, әйтче, кем тиеш?
Менә әле
Мулланур юк тагын...
Бакчага ул нигә чыкмаган?
Җиңел түгел табу
Һәрбер көннең
Үзеңә кирәк дөрес сукмагын.
Кайвакыт ул сине
Шәпләп кенә
Өстери дә китә бер читкә.
Менә — яхшы,
Менә — начар, — диеп,
Бүл тормышны, иптәш, йә чиклә!
Алай булмый.
Һәр яңа көн безнең кешеләргә
Табып тора яңа проблема.
Менә шуңа
Ташчы Мулланур да
Көн дә сорау,
Билгесезлек булып тора миңа.
Меңәрләгән Мулланурлар бүген
Омтылалар якты, яңага.

Ә яңалык
Каршылыклар белән,
Көрәш белән килә аларга.
Шулай туа бездә яңа кеше,
Шулай туа җирдә яңа чор.
Бу чор әле бер дә җырланмаган,
Ишетелмәгән, матур, яңа җыр.

*1960—1961*

## Сине эзлим...

Ничек итеп башлыйм?
Кайдан башлыйм?
Ничек итеп сиңа эндәшим?
Миңа —
Сигез,
Сиңа утыз иде,
Бүген инде сиңа тиңдәш мин.
Без яшьтәшләр хәзер.
Арабыздан
Егерме ике ел гомер җуелган.
Егерме ике ел тормыш яфрак ярган,
Егерме ике ел яфрак коелган...
Мин улың бит.
Синең яшьтәш улың:
Син —
Утызда,
Мин дә —
Утызда.
Кырык бердә китеп
Кайтмаганнар,
Вакыт көчсез,
Картлык, юк сезгә.
Сез хәтердә һаман шул бер килеш,
Үзгәрмичә-нитми торасыз...
Миңа менә кырык,
Илле җитәр —
Еллар үтә бер дә сораусыз.
Күңелдәге иң-иң нечкә кыллар
Чиертелмичә кала,
Өзелә…
Ел томаны аша сине эзлим,
Томаннарда ялгыз эз генә...
Чыклы үләннәрдә ярылып калды
Шул ялгыз эз —
Синең эзләрең.
Син кояшка кереп күмелдең дә,
Ахры, белмәдең
Үзәгемне ничек өзгәнең...

Олау-олау китте ил ирләре,
Батырлыкка таңнан юл алып;
Йөзгә берәү кайтты...
Кайтмаганнар
Ерак меридианнарда югалып
Калдымыни?
Юк,
Калмады алар.

Һәркайсысы үзенең өендә,
Алар кемнәрнеңдер йөрәгендә
Бәйрәм итә Җиңү көнендә.
Алар бергә,
Алар безнең белән,
Тик һәркайсын эзли кемнәрдер.
Мин дә эзлим...
Сине соңгы тапкыр
Кемнәр,
Кайда,
Ничек күргәндер?
Кояшны мин һәрчак көтеп алам,
Таңнар белән торып каршылыйм,
Нурларына карап сокланам да:
— Бигрәк ерак алтын шар шул... — дим.
Алып китте алып китүен дә,
Кайтармады сине,
Югалтты.
Зәңгәр тәхетеннән төшми генә
Күзли мине,
Үзе югартын.
Син —
Бер дөнья миңа.
Кояш та син;
Син,
Эз салып чыклы үләнгә,
Шул кояшка кереп күмелмәсәң,
Кояш булмас иде түбәмдә...

Үләннәрдән чыклар күптән кипкән,
Күзләрдән дә чыклар кипкәннәр.
Кайда,
Нинди үлән булып шыткан икән
Кырык бердә чыгып киткәннәр?
Чыгып китеп кире кайтмаганнар
Исәпсез дә алар,
Хисапсыз...
Хаклы булыр иде,
Һәрберсенә
Мәңге яшәр һәйкәл куйсак без.
Бар ул һәйкәл,
Ул —
Үткәне илнең,
Бүгенгесе,
Килер көннәре.
Тик иң яхшы һәйкәл булыр иде,
Җир онытса солдат һөнәрен.
Авыр һөнәр.
Ләкин кирәк әле,
Изге әле солдат исеме.
Әти булган өчен генә түгел,
Эзлим, ахры,
Солдат булганга да мин сине.

Син —
Бер дөнья миңа.
Туган як син:
Ак Минзәләм,
Ыкта —
Агымсу,

Җаны булган кеше онытамы,
Сагынмыймы
Туган ягын соң?!

Әй,
Саумысыз,
Усай болыннары!
Исәнмесез,
Тупач таулары!
Уйнап йөргән,
Кайчак елап йөргән
Мин калдырган эзләр бармы әле?
Эзләр бардыр.
Балачагым гына
Күмелеп калды язгы басуда...

Тугызынчы Май.
Упалнамуч абый:
«Җиңү!» — диеп
Авызын ачуга,
Әллә кайдан җан өшеткеч сорау
Пуля булып атылып чыкты да:
— Әтиең кайда,
Кайда,
Кайда? — диеп,
Буразнага сугып екты да...
Җиңү таңы туган бер иртәдә
Балачагым шулай җан бирде.
Күрмәделәр аны...
Туфрак кына
Ике бөртек тозлы яңгырны
Сәерсенеп эчте.
Язгы җилдә
Кыштан калган камыш-флейталар
Матәм маршын өзелеп сызгырдылар...
Ә солдатлар яудан кайталар...
Балачакны аткан сорауларның
Йөрәгемдә калды берсесе,
Йөрәгемдә калды иң кайнары,
Иң авыры, кургаш төслесе.
Мин тауларга килдем.
Таулар биек,
Таулар ерак күрә дөньяны.
Таулар таш бит:
Түзәр алар диеп,
Йөрәгемнән сорау-пуляны
Ыргытмакчы булдым шул тауларга.
— Әтием кайда,
Кайда,
Кайда ул?
Таулар мине кызгандылар, ахры,
Алдадылар:
— Әти-е-е-ең... кай-та-а-а-а-а...
Кай-та-а-а-а-а...
Кай-та-а-а-а... у-у-у-ул...
Алдадылар...
Соравымны алмадылар...

Син —
Бер дөнья миңа.

Кайтаваз син:
Күңелемдә һаман чыңлыйсың:
Тотыйм дисәм —
Эреп югаласың…
Синсез яшәү өнме,
Чынмы соң?..
Еллар менә эри.
Әкрен генә
Еллар белән эри гомер дә,
Ә мин һаман эзлим кайтавазны...
Кинәт кенә бер көн килер дә —
Табылырсың кебек бер ялгансыз...

Әй,
Өметләр!
Бала кебек сез.
Сабый булып калсам,
Кала бирим, —
Кыен яшәү бер дә өметсез.
Үткәнемнең саран архивыннан
Синең хатны, —
Ә ул хатың синең бердәнбер! —
Бик кадерләп кенә алып укыйм,
Бәлки, яңа сүзләр кергәндер?
Шакмак-шакмак басма хәрефләрең
Өстәлгәндер, бәлки, кәгазьгә?
Өстәлсә —
Ни гаҗәп:
Бер-беребезгә
Сөйләр сүзләр бүген азмы әллә?
Бердәнбер хат.
Миңа адресланган,
Хәрефләр зур,
Үзе...
Кош теле.
Килгән иде ул
Буран уйнап торган
Зәмһәрирдәй салкын кыш көне.
Утлы күмер кебек бер сүзең бар,
Бер сүзең бар хатта:
«Урлашма!»
Бик хәтерем калган иде сиңа.
Хәзер аңлыйм инде —
Ул башка...
Ул башканы истә тотыбрак,
Күрәзәлек белән язылган.
Уйлагансың:
«Ятим калса-нитсә,
Бозыклыкның кара базыннан
Ерак йөрсен балам,
Багалмам,
Кабат язар вакыт табалмам...»
Бердәнбер хат.
Бераз дары исе
Һәм кыш исе килә аңардан.
Син —
Бер дөнья миңа.
Буран да син,
Хат калдырып киткән кыш-буран...
Шуңа күрә,

Бураннарда калсам:
— Мин улың бит! — диеп кычкырам.
Бураннары белән тормыш атлый,
Ул туктаусыз ерак сәфәрдә.
Ә син кайда?
Кайда туктап калдың?
Авылдамы
Яки шәһәрдә?

Әнкәй сагынып сөйли иде сине:
Юл йөрергә яраткансың син,
Армый йөрүләрең белән генә
Аны үзеңә караткансың син.
Әни —
Тәкермәндә.
Син —
Байсарда.
Сөйгәннәргә ерак арамы?
Велосипед көн дә килеп сарган,
Җил-яңгырга бер дә карамый.
Тыйнак кына,
Оялчан гына итеп
Сөелә һәм сөя белгәнсез.
Минем күңелемә Мәҗнүн-Ләйлә,
Таһир-Зөһрә булып кергәнсез...
Таһир сандыгында акмасаң да,
Юлларың шул синең киселде.
Исемнәре йөрәк тетрәтерлек
Сандыкларда күрәм мин сине.
Син —
Бер дөнья миңа.
Син —
Майданек.
Дахау.
Маутхаузен.
Освенцим.
Ул коточкыч үлем сандыкларын
Ничек кенә,
Ничек ачыйм соң?
Ничек азат итим
Номер сугып
Яндырылган меңнәр-меңнәрне?
Моабитта җәлилчеләр белән
Кунгансың күк соңгы төннәрне...
Карбышевлар белән боз-һәйкәлдә
Бергә күрәм,
Күрәм сине дә...
Һәм,
Син булып,
Бүген тәрәзәмнән
Сирень чәчәкләре сибелә...

Эзлим сине.
Без бит аерылгысыз:
Бер тән,
Бер җан,
Бергә — гомергә.
Мин китсәм дә фани бу дөньядан,
Мөмкин түгел сине күмәргә.
Син —

Бер дөнья миңа.
Балам да син
Улым Илшатымның канында,
Мин дә агам аның венасында —
Без икебез бергә тагын да.
Буыннардан буыннарга кеше,
Каннан канга күчә,
Югалмый.
Ул —
Мәңгелек.
Ул бит материя.
Материяне үлем,
Юк,
Алмый.
Син —
Мәңгелек.
Алсу таңнар белән
Син һәр көнне кабат туасың;
Җәе —
Яңгыр,
Кышын битләремә
Кар бөртеге булып кунасың.
Һәр җирдә син,
Илнең тормышында
Әкият кебек кабатланасың.
Киләчәктә башка дөньяларга
Юллар ачар кораблар да син.

Син —
Бер дөнья миңа.
Үзем дә син:
Гаҗәп түгел миңа бу бер дә.
Бар барлыгым,
Көчем,
Эшем белән
Сине раслап яшим бу Җирдә,
Таптый алмас һичкем,
Һичбер кайчан
Чыклы үләннәрдән эзләрең,
Мин таңнарда һаман сине эзлим,
Актык сулышкача эзләрмен —
Югалмаслар чыклы эзләрең...

*1965*

# Җирән Конрад

Көзге яңгыр
Җилсез,
Төссез яңгыр...
Ачы хәсрәт яшьләредәй авыр,
Кургаш болытлардай күңелсез.
Йолдызлар да никтер күренмиләр,
Синнән куркып
Эреп акканнармы, бер эзсез?
Көзге яңгыр,
Йә әйт,
Ни телисең?
Агачларга нәрсә сөйлисең?

Зират агачлары ник баш игән? —
Әллә һаман —
Әйт син! —
Әллә һаман
Шыксыз үлем җырын көйлимсең?!
Юк,
Күралмыйм вак-вак тамчыларың —
Елан агуы күк һәрбере.
Күпме тырышсаң да
Юалмассың,
Җуялмассың син бу каберне...

Көзге яңгыр!
Ул елны да шулай төссез идең,
Тавыш-тынсыз гына сибәләп,
Кесәлләнгән авыл юлларыннан
Алып килгән идең син бәла.
Әйе,
Безгә,
Сугыш каккан-суккан
Ятим малайларга үч итеп,
Китердең син авыл мәктәбенә
Җирән чәчле немец «учитель»!
Аңа кадәр үткән усал өч ел,
Өч гасырдай озын ул еллар
Безнең күңелләргә
Шәфкать-нисез
«Немец — фашист» сүзен уйдылар.
Немец —
Фашист!
Ә син,
Елак яңгыр,
Аны «учитель» дип атадың...
Син үзең дә Герман ягыннандыр,
Булмагандыр синең Ватаның.
Дөрес,
Завуч аны «үзе теләп
Плен төшкән» диеп аңлатты.
Ышанмадык.
Чөнки белми идек
Плен төшә торган солдатны.
Безнең солдат андый түгел иде,
Безнең солдат —
Әти-абыйлар...
Алар инде, —
Кая үзе теләп! —
Беркайчан да плен бармыйлар.
Алар җиңә.
Үлсә —
Җиңеп үлә,
Йә хәбәрсез кала — югала.
Югалса да,
Ул партизан була,
Герой була,
Аннан илебезгә юл ала.
Ә бу —
Немец.
Немец,
Димәк, фашист!
Ике сөйләшергә урын юк.

Без малайлар шулай дошман иттек
«Җирәнчәч»не күрмәс борын ук.

Дошман иттек аны,
«Фриц нәселен» —
Үлем теләп озак каргадык.
Завуч апа күпме пешерсә дә,
Юньләп дәресенә бармадык.
Ул гынамы,
Әтиләрнең канын
Түләтмәкче булдык без аннан.
Уймак-уймак дары сатып алдык
Соңгы сумга аучы Биҗаннан.
Шул дарыдан «мина» ясадык без,
Шартлатырга җирән бүрене.
Исәп —
Мунча кергән чагын саклап торып,
Җәһәннәмгә озату тегене.
«Мина» шартламады...
Явыз яңгыр,
Син чылаттың безнең дарыны!
Немец исән калды,
Без еладык гаделсезлек күреп...
Йә әйт инде,
Шулай ярыймы?!

Ә «Җирәнчәч»,
Берни булмагандай,
Кереп йөрде безнең өйләргә.
Бераздан соң...
А, ни хурлык!
Оят сөйләргә! —
Әниләрне сихерләде немец,
Көпә-көндез буды күзләрне.
Авыл телендәге кушаматы —
«Җирән бүре»
«Җирән Конрад»ка үзгәрде.
Оста иде үзе:
Берәүләргә
Мич чыгарды,
Икенчегә
Сәгать төзәтте,
Өченчегә...
Нәрсә өченчегә?!
Юхаланып шулай ул һаман да
Өзгәләде безнең үзәкне.
Без буталдык.
Каршылыклы хисләр —
Ерып чыгалмаслык лабиринт...
— Әни,
Әни,
Кемгә ышанасың?
Немецкамы?!
Ә син,
Конрад,
Баскан туфрагыңны кабер ит!

...Кинәт сугыш бетте.
Көтмәгәндә.
Кем соң әйтте?

Җирән Конрад.
Конрад инде Конрад түгел иде,
Авыл өчен күптән —
«Камрад».
Сугыш бетте!!!
«Җирәнчәч»нең үзе ясап куйган
Приемнигы шулай сөйләде.
Без шатландык —
Ул елады.
Бүрек чөйдек,
Конрад чөймәде...
Ул елады тавыш-тынсыз гына,
Бөкрәеп,
Сыгылып,
Сулыгып.
Кеп-кечкенә,
Хәлсез карт иде ул.
Нишләп безгә
Күренгәндер ямьсез,
Зур булып?!
Нигә елады ул?
Кайгырыпмы,
Шатланыпмы сугыш беткәнгә?
Аңламадык.
Дөресе,
Соң аңладык...
Ах,
Кайтып булса икән үткәнгә!
Кайтып булса,
Барыбыз исеменнән
Гафу үтенер идем мин аннан...
Ничә еллар буе үкенүемне,
Юк, юк, яңгыр,
Әйтеп биралмам.
...Конрад үлде.
Аның үлеме дә
Килүедәй шомлы,
Серле иде.
Сугыш беткәч,
Бер атнада үлде.
Ә фикерләр һаман төрле иде.
Без малайлар:
— Җиңелү хурлыгыннан
Дөмеккәндер, — дидек,
Шатландык.
Балаларча беркатлылык белән
«Учитель»не
Йөрәктән үк сызып ташладык.
Без ташладык.
Авыл ташламаган —
Моны хәзер генә белдем мин.
Төссез яңгыр,
Менә шуңа бүген
Конрад каберенә килдем мин.
Җирән Конрад...
Ул янәшә ята
Минем бабам белән зиратта;
Нәсел-нәсәбеннән,
Германиядән,
Дус-дошманнарыннан еракта.

Мин яңадан ишеткәндәй булам
Авыр сулышын үткән елларның.
Мин ишетәм
Кабер астында да
Тына алмаган фатер[1] елавын.
Юк,
Бу юлы Җирән Конрад түгел,
Бөтен Германия үкседе.
Бөтен Германия фюрерына
Йодрык төйнәп әйтте:
— Ух, сине!!!

Маркс,
Тельманнарның шәүләләре
Фатерланд[2]ка төбәп карады:
Күренеп китте шунда гестапоның
Конрад улын аскан дарлары...
Мин ишеттем менә шундый елау,
Мин ишеттем бүген...
Ә анда —
Бүлгәләнгән Берлин урамында,
Бонnда
Ишетмиләр.

Анда башка тавыш,
Анда кабат яңгырый:
— Нах Остен![1]
...Бабам белән Конрад каршысына
Шуның өчен килеп мин бастым.
Шуның өчен килдем...
Ә син,
Яңгыр,
Көнбатышка табан агып кит;
Германиягә барып җитәр булсаң,
Конрад күз яшьләрен алып кит.
Бранденбург капкаларын үткәч,
Түк син аны Берлин өстенә.

Мин ышанам:
Андый күз яшьләре
Йөрәкләрдә нәфрәт үстерә.
Нәфрәт тулган шул йөрәкләр әгәр
Сугышларга каршы берләшсә —
Димәк,
Конрад һаман солдат әле,
Димәк,
Конрад һаман көрәшә.
Кит син,
Яңгыр, —
Мине ялгыз калдыр,
Ә мин монда калыйм беразга...
Менә кабер ташы.
Һәм ул таштан
Карап тора миңа бер язма:
«Конрад — камрад.
Ер вар айн гутер манн,
Вайль ер цу унс гекоммен ист»[1].
Бу —
Немецча.

Һәм татарча язу:
«Укытучы.
Немец.
Коммунист!»
*1962*

## Кына гөле

**1**

Үткән көннәр алар ярылып ята,
Килер көннәр генә сер тулы.
Шуңадыр шул күпләр ясый хата,
Ах, белсәңче барын берьюлы!
Гаҗәпмени?!
Бер дә гаҗәп түгел,
Кинәт дөнья нурлы күренгәч.
Һәрбер егет чибәр,
Һәр адымы
«Сөям!» сүзе белән үрелгәч.
Нишләсен соң йөрәк, әй, Рәшидә!
Акыл югалмыйча нишләсен?!
Андый чакта яшьлек-юләрлекнең
Шашкын хисе белән килешәсең.
Яшьлеккә бит көн дә сердәш кирәк,
Әгәр инде анысы булмаса,
Серләреңне шук җилләргә сөйлә,
Кайгы-хәсрәтләрне шул баса.
Рәшидәнең яшьлеге дә менә
Бөреләнде һичбер сердәшсез.
Авызлыксыз яшьлек тилергәндә:
— Саклан! — диеп аңа кем дәшсен?

**2**

Рәшидә ул үскән ярым ятим
Һәм әтисен гомер күрмәгән.
Бар әтисе аның, һаман исән...
Ятимлекнең ямьсез күлмәген
Кидергән дә нәни Рәшидәгә,
Ташлап киткән аны, таш бәгырь!
Ә атасыз бала — канатсыз кош:
Күп булса да җәбер, юк кадер.
Малайлар да сиңа таш аталар,
Булмаганын сизеп яклаучың;
Кызлары да сиңа сүз аталар:
— Әтиең кайта, — диеп, — йә, кайчан?
Рәшидәнең теңкәсенә тиде
Бигрәк тә күрше Галимҗан.
Күрсен генә — мыскыл итә башлый,
Ай рәхимсез инде, явыз җан!
Бер бәйләнә:
— Тишек ботинка! — дип,
Бер үчекли:
— Җанлы карачкы!
...Көн дә шулай кимсетелеп торып
Син кайгысыз яшәп карачы!
Шуңа, ахры, бер иптәшсез үсте,
Ялгыз булды укып йөргәндә.
Эч серләрен бары сөйли иде

Үзе кебек уйчан,
Тиз сынучан,
Тиз сулучан кына гөлләргә.
Йомылып үсте кызый һәм үзе дә
«Кына гөле» диеп аталды.
Тирә-юньдә ягымлылык белән,
Эшчәнлеге белән макталды.
Акылны ул җыйды әнисеннән,
Күрше-күлән хатын-кызлардан...
«Бай ир — бәхет» дигән сүзләр эчеп,
Кына чәчәк тулган, кызарган.
Кем күргәндер аны иң беренче,
Кем әйткәндер:
— Сөбханалла! — дип?
Кем сөйгәндер аркасыннан кагып:
— Күз тимәсен, — диеп, — алма бит! —
Аны хәтерләми Кына гөле,
Хәтерли ул җәйге бер көнне.
Шул көн аңа яшьлек ишек какты.
Иркә оялчанлык бөркәде.
Болай булды:
Иптәш бер кызының
Әҗәткә алып ефәк күлмәген,
Бер әйләнеп чыккач ишек-түрен
Ялгыз гына кысан бүлмәнең,
Күптән җыеп килгән сумнарына
Театрга китте Рәшидә.
Юлда тагын Галимҗанны күрде,
Ә тегесе...
Үчекләшү кая, дәшми дә.
Кына гөле, көтеп мыскыл сүзе,
Кечерәйде шунда, бөреште.
Ә Галимҗан —
Аңа нәрсә булган? —
Исәнмесез!.. — диеп күреште.

**3**

Галимҗан ул башка сүз әйтмәде.
Хәер, сөйләү нигә кирәк соң?
Күңелләрнең ачык тәрәзәсе —
Күз дигәннең телен өйрән син.
Күз кешедә — илаһи бер патша,
Болай гади, тыйнак йөрсә дә.
Күз ул безгә татлы хыялны да,
Яшерен газапны да күрсәтә.
Күз юата, кыйный, шатландыра,
Кайгы диңгезенә ыргыта;
Күз чакыра, куа, вәгъдә бирә,
Көтмәгәндә яки куркыта.
Күз аера, куша, кире кага,
Кирәк булса өзелеп ялвара;
Күз боера, тыя, рөхсәт итә... —
Буйсынмыйча кара, бар аңа!
Рәшидә дә менә Галимҗанның
Кинәт йомшап калган күзендә
Очкын күрде, күрде шул очкында
Гүзәллекне.
Ә гүзәллек...
Яши икән аның үзендә!

Әҗәт күлмәк белән генә түгел,
Яшьлек белән чибәр Рәшидә.
Табылыр иде микән ул вакытта
Бу матурлык белән көрәшергә
Көче җитә алган ир-егетләр,
Табылыр иде микән андыйлар?!
Галимҗанны әнә «усал» диләр,
Бер дә түгел икән, алдыйлар.
Усал булса, аның күзләрендә
Кояш көлә алыр идеме?
Һәм ул күзләр, матурлыкны тоеп,
Сөеп озатып калыр идеме?!
Кешеләрне әгәр белим дисәң,
Күзләренә кара һәрвакыт.
Күзләр сөйли тик дөресен генә,
Ялган булганнарын таратып.

**4**

Рәшидәгә кара: ничек әле
Ул үзгәрде болай кинәттән?
Анысын инде сора кимсенүдән
Азат булган япь-яшь йөрәктән.
Кичә генә үги иткән дөнья
Аңа башын иде:
— Гүзәл! — дип.
Шуңа күрә көләч Кына гөле,
Шуңа шатлыгына түзалмый.
Менә шулай Кына чәчәк атты,
Яшьлек шулай канатын какты.
Кичә генә соры булган дөнья
Берьюлы мең кояшын якты.
Берьюлы мең кояш Кына гөлгә
Нур өстенә нурлар койдылар;
Алар таш атучы малайларның
Барлык усаллыгын җуйдылар.
Ул малайлар —
Кая таш ату ди! —
Рәшидәгә
Күз атарга хәзер кыймыйлар.
Озын телле бистә телефоны
Ул вакытта шулай сөйләнде:
— Моңа кадәр дөнья яратмаган
Һәм яратмас андый чибәрне.
Күрше урамнар, имеш, бушап кала,
Ул кайтканда безнең урамнан,
Һәммә егет, имеш, сукмак сала
Рәшидәләр өе турыннан...
Юк, Рәшидә — Зөһрә кыз да түгел,
Һәм шулай ук түгел Ләйлә дә —
Бик сөйкемле генә татар кызы.
Ә кызларның башы әйләнә...

**5**

Үткәннәрне уйлау авыр, ахры —
Рәшидәбез йотылып су эчә.
Әйтерсең лә аңа кабат кайтты
Әҗәт күлмәк кигән шул кичә.
Кирәк саен алып эчкән судан
Мең мәртәбә рәхәт, тәмлерәк

Үлеп сусаганда бер йоткан су.
Шул күлмәкне кигәч, әй, йөрәк,
Ник шашындың икән, ник сикердең?
Сусауларың басар өченме?
Әллә инде күптән көткәнеңә
Сөю серен ачар өченме?
...Яшьлек килде...
Яшьлек үзе белән
Мәхәббәткә сусау китерде.
Рәшидәкәй, сөю-сөелү көтеп,
Яшьлек белән бергә иserде.
Кызлар...
Сөелү өчен яратылган алар.
Ә бит сөю, диләр, авыру...
Авыр дими йөрәк, теләп ала —
Терелү дә юкса авыр ук.
Тарих әйтсен:
Мәхәббәткә буйсынмыйча калган
Кеме булды икән дөньяның?
Шайтаны да юктыр...
Кешеләре —
Сөю җимешләре инде аның.
Ах, мәхәббәт!
Тиле акыллылык.
Синең өчен
Юмартланган күпме саранннар,
Бу дөньяның күпме куркаклары
Тиңсез батырлыкка барганнар.
Күпме таш йөрәкләр эрегәннәр,
Күпме яшьнең чәче агарган,
Күпме картка яшьлек кире кайткан
Бар да исән булса,
Җирең тулар иде алардан!
Рәшидә дә мәхәббәтен көтте,
Һәр яшь күңел көткән шикелле.
Егет-җилән күп чуалган саен,
Йөрәк ярсып-ярсып җилкенде.
...Әйе...
Унсигез яшь тулар-тулмас иде.
Кулын сузса — әнә мәктәбе,
Югалмаган әле, ерак түгел...
Эшче исемен тәүге мәртәбә
Мехкомбинат цехларында аның
Беренче ай ишетүе иде;
Рәшидәнең үзен коллективта
Кыяр-кыймас хис итүе иде.
Укыганда вакыт җитмәгәндер,
Чын мәхәббәт һаман килмәгән,
Бер тапкыр да әле егет-җилән
Озатмаган, бер дә үпмәгән,
Шаярткалап, уйнап-көлмәгән.
Кыз кешедә күп чак шулай була:
Тешләр елтыравы һәркемгә.
Ә йөрәкнең ихлас елмаюы —
Тик берәүгә...
(Анысы да булмый һәр көндә.)

**6**

Рәшидәнең күңеле көтә, көтә
Йөрәк елмаерлык кешене.

Ә әнисе аны игәп тора:
— Егет сайлау кызлар эшеме?
Мин үстердем сине тол көенчә,
Кияүне дә үзем табармын.
Кемдә байлык, шунда бәхет, кызым,
Дәрәҗәле ишек кагармын.
— Әни, нигә андый сүзең?..
Иртә миңа...
Эшлим әле... укыйм заочно.
— Менә шашкан!
Белемең алып ашкан.
«Укыйм» диеп авыз да ачма!
Чибәрлегең гыйлемнәрдән олы,
Любой егет акылдан шашар.
Дәрәҗәле ирдә дәрәҗәңне
Белеп кенә яшәү ни начар?!
Күршедән дә табыла «киңәшчесе»,
Салпы якка салам кыстыра:
— Шулай булмыйча ни, ахирәтем,
Артыңда бит нинди кыз тора!
Кына гөле!
Әле менә Сәмигулла абзый
Килгән иде безгә Акташтан.
«Улым инженер», — дип сөйләп торды.
Алар безгә бераз якташ та.
Рәшидәне күргән:
«Кем кызы?» — ди.
Би-и-ик мактадым сезне, ахири.
Шаярткандай итеп әйтеп куйды:
«Әнвәремә
Соратмыйча булмас, ахры!»
— Ах, кирәкми... Уемда да юк бит...
— Әнкәң белән син сүз көрәштермә!
Кем үстерде сине? Кеше итте? —
Нишләсен соң, дәшми Рәшидә...
Тәрәзәгә карый, күзендә яшь.
Шул томанлы яшьләр аркылы
Галимҗанны күрә:
«Төтәтәме...
Ник ташламый икән тартуны?»
Ә Галимҗан-шофер бу көннәрдә
Тәмәкедән чыккан төтенгә
Уй-хисләрен урап йөри әле —
Рәхәт тә күк аңа, читен дә.
Ничә талпынмасын, Рәшидәгә
Сүз катарга җитми кыюлык.
Гүя башы тишек кузов аның —
Әйтәсесе бетә коелып.
Малай чакта ничек җиңел иде...
Кай арада егет булынган?
Уйлый микән Рәшидәкәй көлеп:
«Пыскытудан, руль тотудан башка
Берни килмидер, — дип, — кулыннан!»
Машина ул тимер!
Күндәм әйбер.
Шул кызны син менә буйсындыр.
Телең сандугачтай сайрамагач,
Килгән булсын иде буй-сының...
Ә бүлмәдә сизгер күрше хатын
Әнисен дә

Һәм кызын да һаман «өйрәтә».
Әнвәр исеме тамчы-тамчы булып
Тама тора япь-яшь йөрәккә.
Рәшидәбез Галимҗанны күзли,
Уе ләкин никтер читтәрәк.
Кына гөлгә җылы җитми, җитми,
Иртәрәк шул әле, иртәрәк...
Үзе уйларында Әнвәр белән
Урамнардан үтә гөрләшеп;
Таныш-белеш кызыгып карап кала,
Карап кала, имеш, көнләшеп.
Көнләшмәскә!
Гади эшче килеш
Зур инженер белән йөр дә син!
Ә күршесе һаман эссе өсти:
— Яшьләрнекен инде белмәссең...
Ахири, дим, әллә җаен табып,
Чакыртыйкмы икән Әнвәрне?
Күреп китәр безнең хәлләрне дә,
Күреп китәр сезнең хәлләрне...

**7**

Чакырттылар.
Килде, керде, күрде...
Тик Рәшидә күрә алмады.
Акылы качты аның, зиһене китте,
Курку катыш каушау алдады...
Әнвәр әнә нинди: озын, таза!
Рәшидәне
Бала гына икән димәсме?
Әнвәр көлә:
— Апа, кызың бик яшь.
Кына гөлгә кырау тимәсме?
Әнисе дә көлә:
— Кем тисен, — ди...
Күрше хатын:
— Алай димә бер дә, ахири.
Хәзер бала-чага бераз үссә,
Ата-анага инде баш бирми.
Алар шулай сүз куерта бара,
Ә Рәшидә уйлар эчендә:
«Ямьсез түгел үзе... ипле сөйли...
Иш булырмы йөрәк өчен дә?
Чәче саргылт... күзе нинди икән?
Зәңгәр микән, соры, карамы?
Ә Галимҗан... һаман читләп үтә,
Миңа борылып та карамый!
Ул бит шофер, эше күптер...
Бу — инженер!
Ничә яшь икән?
Беренче кат күрешкәнгә, ахры,
Сөйләшүе кыен эш икән».
Уйлар белән мавыгып, Кына гөле
Шикәр савытына үрелә...
Җиңе белән шунда чынаякны —
Чылтырт!
— И ахири, эшләрегез изге күренә!
Бусагадан кергән ир алдында
Савыт-саба төшеп ярылса,
Ул ир, имеш, сиңа кияү була...

— Белмәссең дә,
Тәкъдиреңә шулай язылса...
Ә Рәшидә оялып, читенсенеп
Чыгып китә тиз-тиз бүлмәдән:
«Булачак ир, имеш...
Бер-берләрен
Алар әле гел дә белмәгән...
Бераз йөрү кирәк, сораштыру...
Ничек инде болай кинәттән?..»
...Әнвәр китте.
Күрше хатын:
— И Рәшидә,
Тугансыңдыр, җаным, күлмәкчән!
Булачак ир...
Бу сүз Кына гөлне
Бөтереп алды, сулу бирмичә,
Мендәренә ауды битен каплап,
Ни әйткәнен белер-белмичә...

**8**

Галимҗанга күпереп килде хәбәр:
— Укымышлы кияү... инженер!
Буталганны ныграк буталдыру
Җиңел эшләрдән дә иң җиңел.
Акыл урынына дуамаллык
Рульгә менде егет башында.
Шофер бүген шалтыр-шолтыр йөри,
Командировкага ашыга.
Мәхәббәттән качып булмый аннан,
Качып булмаган күк үлемнән...
Көрәшмичә, ялгыш адым ясап,
Күпме баһадирлар җиңелгән!
Машинамы сиңа, Кына гөле? —
Яшерен яну бирми «права».
Китсен, китсен!
Нәрсә өмет итсен?
Җебегән булды... полный провал...
Чү, Галимҗан!
Киметә төш газны.
Бер ычкынсаң, абау, явыз син!
Рәшидәне нигә күрмисең дә,
Китеп барыш абайламыйсың?
Китте...
Төтен генә калды...
Бигрәк ачы шуның төтене...
Казан гына түгел,
Йөрәктән үк
Әллә гел кайтмаска киттеме?
Күрше хатын:
— Кыз алырга китте...
Рәшидә (үз-үзенә):
— Күрмәс булды менә ни өчен!
Кычкырып:
— Тапкандыр шул
Өлешенә тияр көмешен...
...Төн йокысыз узды.
Кына гөле
Сулып торды иртән...
— Бәбкәчем,
Әнвәр килгән, синең кулны сорый.

Риза булчы! — диеп әйткәчтен,
Теле:
— Ярар... — диде,
Уе ера-а-ак иде...
Ахры, куып җитә алмады
Галимҗанны барыбер...
— Ярар... — диде.
Аңа башка чара калмады.
Хыялында бөреләнгән идеал
Әнвәргә бик охшаш түгел дә...
Ятим яшьлегенең
Күпме көне, күпме төнендә
Мендәр чите тешләп елаулардан
Туйды инде, туйды Рәшидә.
Әнвәрне дә кире какса әгәр,
Кем өчен соң аңа көрәшергә?
Барыбер инде булмый булмагачтын,
Хатын-кызның язмыш билгеле...
Тыныч, таза тормыш бирсә Әнвәр,
Шунда күренер яхшы ирлеге.

**9**

Такси белән генә барды алар,
Әнвәр кызганмады акчаны.
Килүчеләр шактый күп күренгәч,
Рәшидә уйлады: — «Баксана!
Бер мин генә түгел икән әле.
Керәләр дә көлешеп чыгалар.
Ник куркам соң?
Барын Әнвәр эшләр,
Барысын да үзе чамалар...»
Чират җитте.
Ять-яшь секретарь кыз
Гаризаны үрелеп алды да,
Аны-моны сораштырып тормый,
Бер читенә билге салды да:
— Бер атнадан килерсез бит? — диде.
Һәм ишеккә:
— Тагын кемнәр бар?
Рәшидәләр чыкты, ә алмашка
Керә калды анда яңа пар.
Әйт, секретарь кыз!
Нигә ашыгасың?
Борчак куырасыңмы табада?
Аңламыйм мин:
Загсларга шундый җансызларны,
Гамьсезләрне кайдан табалар?!
Азмыни соң бездә гомер юлын
Сокланырлык матур үткәннәр;
Сөю кайнарлыгын суытмыйча,
Алтын туйда
Берсен-берсе суырып үпкәннәр.
Семья бусагасын атлаганда,
Нигә шулар һәрбер яшь парга
Сөйләмиләр:
— Кызыкмагыз, — диеп, —
Җыен ялтыравык юк-барга?
Ник әйтмиләр:
— Күңелләр, — дип, — шундый сизгер була,
Берсен-берсе әгәр таныса,

Кавышалар
Яки аерылалар,
Ят күңелләр әгәр тарыса.
Әҗәткә алган ефәк күлмәкләрне
Балаланып, кызыгып кисәң дә,
Сөюне бит әҗәткә дип алып
Яки биреп булмый,
Әй, Рәшидә,
Нәрсә дисәң дә!
Сират күпере кылдан нечкә,
Кылычтан үткен, имеш, —
Берәүнең юк аны кичкәне.
Тик мәхәббәт күпере аңардан да
Йөз кат үткен, йөз кат нечкәдер.
Ник әйтмиләр:
— Кайтып торыгыз, — дип, —
Бер-берегезне ныклап белегез.
Бер-берегездән башка торалмаслык
Булгач кына безгә килегез.

**10**

— Бер атнадан... бер атнадан...
Үтеп бара инде ул атна.
Хис кая ул!
Иялэшеп тә булмый:
Әнвәр һаман ят та, ерак та.
«Отелло»ны карый Рәшидәләр.
Кызның башы — уйлар тубалы:
«Әнвәре дә шулай көнче булса...
Буып алса тупас куллары...
Юк, юк, булмас!
Юк, юк, бумас!
...Ничек әле теге чит ил фильмы?
Яшь баласы белән яшь хатын...
Ир хыянәт итә, ташлап китә...
Караңгы төн...
Әй, анысы аның башка төн!
...Ничек әле тагын бер китапта?
Шулай яратмыйча өйләнеп...
Ничек шулай?
Димәк, Әнвәре дә...
Тиз качарга!
Йөгерергә хәзер өйгә үк!
Куа чыга Әнвәр Рәшидәне:
— Йә, ни булды?
— Күңелем болгана...
— Билет әрәм. Әйтү кирәк иде
Кергәнче үк алай булганда.
Менә парк.
Шомлы аллеядан
Алар икәү атлап баралар.
Әнвәр план кора:
— Яхшы квартир алмый,
Кирәк булмас безгә балалар.
Әти чакыра чакыруын да бит,
Нәрсә калган анда, районда?
РТСта баш инженер, имеш...
Рус әйтмешли, безнең «рай» — монда.
Әтигә аңа минем акчам кирәк...
Вообщем, туйдым ла мин алардан!

Туйга бераз сыгып булса үзен —
Фьють! —
Эзләсеннәр җилне даладан.
Кызның каны ката, кычкырмакчы:
— Ни сөйлисең? Тукта! Җитәр! — дип,
Ләкин тел әйләнми, күңел бавын
Җирәнүме тоткан, җибәрми.
Кына гөле артык түзә алмый,
Кайту якка тарта Әнвәрне...
Ә өендә ана көтеп тора,
Сорашырга булган хәлләрне.
— Әй, син тиле, тиле!
Соң, Әнвәрең
Синең өчен шулай кайгырта.
Янып торган таза ирең булгач,
Нигә кирәк сиңа каената?!
Үзең үк бит риза булмас идең,
Бар тапканын торса таратып.
— Булмый, булмый, әнкәй, аптыратма!
Яши алмам кебек яратып...

**11**

Ә иртәсен эштә, цех эчендә
Эшче кызлар кылын чиртәләр.
Сүз аралаш уен-көлке кушып,
Бер-бер артлы тезеп китәләр:
— Килгәнеңә, дускай, кайчан гына —
Ычкынырга икән исәбең...
— Әй егете, кызлар, әй егете!
Ялгыш кына күрдем кичә мин.
Валлаһи дим, Равилемне менә
Онытa язып куйдым, алдамыйм...
— Инженер ди үзе.
— Шулаймыни?! Рәшидәкәй,
Авызың йөзәр инде балда, дим!
— Ну, чукынчык, кайдан таптың аны?
— Төшмәгәндер инде галәмнән.
Юк инде, юк, минем Җәүдәтемнән!
— Юк инде, юк, минем Галәүдән!
Әй сез, кызлар, әй сез, шаян кызлар!
Нигә икән шулай һәрвакыт
Хурлагандай итенәсез икән
Равил, Галәүләрне
Йөрсәгез дә үлеп яратып?!
Нигә икән кеше бәхетеннән
Көнләшкәндәй була күбегез?!
Рәшидәне аңлагыз сез бүген,
Йөрәгенә үтеп keрегез!
Юк, кермиләр.
Әллә инде шунда
Яңа килгән кеше итәләр:
Дуслашып та өлгермәгән булгач,
Бер сердәшсез ташлап китәләр.
Ә Рәшидә тагын икеләнә,
Яраткандай була Әнвәрне:
«Чынлап та бит сөймәс егет түгел.
Башкаларга тоз сипкәннәрме?
Нигә, әйтик, шул ук Галәү өчен,
Кара эшче була торып та,
Менә дигән кызлар ут йоталар?

Әнвәр кимме әллә?
Курыкма —
Биш Галәүне сатып җибәрерлек.
Белеме бар, килгән буй-сыны...
Бик басынкы, кул да салганы юк —
Нәрсә әйтсәм, шуңа буйсына.
Ә... Галимҗан нинди ипсез иде...
Иде... иде... Юк шул инде ул...»
Рәшидә һич ялгышмастыр кебек...
Әнвәргә бит вәгъдә бирде ул.

**12**

Без — кешеләр.
Галимҗан да кеше,
Рәшидә дә,
Коллектив та бездә — кешеләр.
Кайвакытта без нигәдер көчсез,
Ә кайвакыт гаять көчлеләр?
Шактый катгый, кырыс сорауларын
Тормыш безгә көн дә куймаса,
Һәм аларны дөрес чишмәгәндә,
Тирән-тирән яра уймаса, —
Ялгышулар булмас иде җирдә,
Кимер иде бераз кайгы да...
Һәрвакытта гел бертөрле якты
Сибеп тора салкын Ай гына.
Чөнки Айның, җаны булмаган күк,
Нурлары да булмый үзенең:
Кояш нурын үзгәртмичә генә
Җиргә түгә —
Бер төре ул гигант көзгенең.
Ә Галимҗан андый көзге түгел.
Гади кеше — хисле, йөрәкле.
Һәрбер йөрәк кайнар вулкан үзе,
Әмма һәр кайнарлык бирми кирәкне.
Кирәкмәгән өчен кан кайнатып
Үткәргәли кеше еш кына.
Менә инде нәкъ шул минутларда
Хата арты хата ычкына.
Галимҗан, син шундый хата кылдың.
Ашык, дускай, төзәт хатаңны.
Рәшидәнең күңеленә Әнвәр
Синең ялгыш аша атлады.
Әле туй узмаган — тун тузмаган,
Вөҗдан эшең булыр калганы...
Кына гөлнең өмете алдануы
Ул безнең дә,
Ах, безнең дә бүген алдану!
«...Машинакай, машина ла, очар
Канатларың икән булсачы...
Ни дип болай иттем, ни дип качтым
Миннән тиле бармы бу чаклы?..
Командировкага иптәшләрдән
Теләсә кем китә ала иде...
Рәшидәкәй...
Ничек карады ул миңа өзеп!
Үземнеке итә ала идем...
Менә хәзер чап Казанга, чап, чап!
Бәлки, җитешерсең... туена...»
Һәм Галимҗан газга ныграк баса,

Ярсып тыгыла да уена.

**13**

Рәшидә бит бүген соңгы тапкыр
Кызлар булып чыга бакчага.
Соңгы тапкыр егет белән йөри...
Их, кызларның дәртле, яшь чагы!
Шулай инде үтәрсез дәмени,
Кайтмассыз дамыни яңадан!
Чынлап укмы закон иртәгәдән,
Ир хатыны итеп,
Җавап таләп итәр аңардан?
Ашыкмыйммы икән бу Рәшидә
Кияү кочагына керергә?
Унсигезе тулар-тулмас әле...
Яшьтәшләре уйнап, шаярышып,
Гыйшык тотып шактый йөрерләр.
Сөю тәмен, сөелү ләззәтләрен
Алар инде белсә белерләр.
Төннәрендә курка-курка гына
Ишек ачып өйгә керүләр...
Йокласа да, күңеле уяу булган
Әниеңнең сынап карашы...
Һаман әле китә алмый торган
Тәрәз төбендәге җанашың...
Иркәләүгә сусап башын төрткән
Күкрәкләрнең рәхәт сызлавы...
Кеше сокланырлык оялчанлык,
Гүзәл итә торган кызларны...
Рәшидәкәй,
Болар шулай бер дә булмасмы?
Капрон оек белән кышларында
Башкалардай зарыгып, егет көтеп,
Калтыранып, өшеп тормасмы?
Рәшидәбез белми шушы кичтә
Галимҗанның Кама кичкәнен;
Кына гөле белә үз хисләрен,
Ул кич күпме газап чиккәнен.
Анысын белә, әмма белми бит ул:
Чынлап сөю булса күңелдә,
Кыз чак кынамы соң, гыйшкың өчен
Гомерең дә әрәм түгел лә!
Рәшидәгә кара, Әнвәренә —
Нинди берлек бар соң аларда?
Бер-берсенә уйда бәя биреп,
Бакча гизә,
Товар сайлыйлармы базарда!
Алар икесе дә соңгы кичне
Тизрәк үтсен диеп телиләр.
Сөйләшергә сүз юк, болай гына,
Эч пошканнан гына йөриләр.
Тагын кемдер йөри...
Әллә... әллә...
Галимҗанмы инде бу шәүлә?
Йөрәк никтер тырный:
— Тизрәк өйгә
Кайт, Рәшидә, — диеп куша әллә?

**14**

Язылышалар, язылышалар бүген!
Шаулап тора загс тирәсе.
...Йөрәк тибә, шундый көчле тибә...
Рәшидә:
Әйт син, йөрәк, нигә тибәсең?
Йөрәк:
Тибәм шуңа, шуңа дөп-дөп киләм —
Бу ишеккә керер алдыннан
Туктатасым килә сине, ләкин
Саклый алмыйм соңгы адымнан.
Чөнки миңа ирек бирмәдең син,
Каршы килдең, тыйдың баштан ук;
Акыл белән тотып йөгәнләдең...
Ә мин Әнвәреңне
Яратмадым теге чактан ук...
Рәшидә:
Җитте, басыл, юләр!
Сиңа ирек куйсаң,
Бәлки, икене сөй, диярсең...
Йөрәк:
Юк, басылмыйм, ярсыйм! Алдалама,
Бүген акылың белән юләр син!
Беләсең бит кемне яратканым...
Син кыйнап та мине, ватып та,
Акылың белән буып үтереп тә,
Мәҗбүр италмассың юатып та.
Һәр кешедә йөрәк тик бер була,
Сыйдыра ул бары берәүне;
Ул һич күтәралмый, кача-поса,
Ирексезләп, көчләп
Аның түрләренә керүне.
Бәлки, Әнвәр төскә матур дадыр,
Тик йөрәге аның миңа ят...
Рәшидә:
Тсс! Шаулама! Безне чакыралар...
Йөрәк:
Бар да бетте...
Нинди хурлык миңа, нинди оят...
Мескен йөрәк, сулык-сулык килеп,
Кан-яшь түгә-түгә үкседе...
Өзгәләнде...
Рәшидә, әйт: нишләттең син аны?!
Ух, сине!!!
...Чәчәк букетлары... шампан шавы.
Тәбрикләүләр... такси гөрләве...
Бар да томан, томан!
Якты дөнья инде һич юк сыман.
Килен кеше берни күрмәде...
Рәшидәнең паспортына шулай
Мөһер сугылды да — ә йөрәккә,
Ә йөрәккә сөю кермәде!

**15**

Өйдә инде әзер һәммәсе дә,
Һәр кешенең роле билгеле —
Спектакль башланырга тора.
Мулласы да шунда,
Муены асларына килгере!
Менә шартлар... шартлар...
Тыелмаган йөрәк

Бомба кебек әзер тора монда,
Тормыш кулы үзенең төзәтмәсен
Китереп кертте шушы драмага.
Күзләр очраштылар.
Очкыннары
Китереп сукты һәр икесенә.
Галимҗан карашы:
Ах, ялгыштың...
Рәшидә карашы:
Ах, ялгыштым...
Нидер төште бугай исенә.
Нидер шунда безнең Рәшидәнең
Күңеленә килеп кадалды —
Мираж бетте, томан таралды,
Күз алдында Галимҗан калды.
Һәм Рәшидә үзен белештерми,
Бәреләсугыла читкә ташланды...
Ә йөрәге аның, ә йөрәге
Шундый типте, шундый шатланды!
Күз яшьләре көчле аккан саен,
Йөрәк типте ярсып, сөенеп:
«Ела, ела, ела, Рәшидә, син,
Татымыйча кайнар сөюне,
Сөйкемсезгә буйсынып яшәгәнче,
Елап яшәү артык мең тапкыр».
Ә Рәшидә яшь аралаш көлә:
«Әй, йөрәгем, әй, юләрем,
Бераз гына тынып, туктап тор.
Үтерәсең бит инде юкса мине,
Давылларың чүт-чүт баса төш.
Димче-имче, Әнвәр, загслар ул —
Чын түгел бит, бары начар төш».
Йөрәк кинәт шомлы тынып калды.
Аннан тагын ярсып сикерде,
Үрсәләнде... үлем алларыннан
Бәргәләнгән лачын шикелле:
«Загс — төшме?! Төшме соң, Рәшидә?!
Паспортыңда әнә печатең...»
Сыгылып төште кызый:
— Ах, әнием...
Нишләттең син мине, нишләттең?..

**16**

Өйдә ыгы-зыгы, шау-шу, тавыш.
— Килен качкан! Килен, тирес бит!
Әнвәр утыра түрдә башын тотып.
А, нәрсә бу?!
— Әйе, дөрес... — дип,
Бусагада калкып, үсеп чыкты —
Кем дисезме? —
Үзе Рәшидә!
Утлы күмер кебек карашлары,
Кемнәр булса бүген шушы өйдә,
Һәммәсен дә нәфрәт белән өтте.
Аннан ул Әнвәргә төртелде.
Кызның калтыравык тавышыннан
«Ах!» иттеләр, бүлмә дер килде.
Әнвәр шунда кинәт күтәрелде,
Бер атлады... ике... үтерә!
Юк, үтерми, күрше хатынының

Лач иттереп йөзенә төкерә:
— Син, сволочь, мине рисвай иттең!
Фәрештә ул, дидең, мактадың.
Ә фәрештәң минем ирлегемне,
Дәрәҗәмне
Пычракка салып таптады.
Сөйрәлчек ул синең Кына гөлең,
Азгын хатын,
Бик беләсең килсә, менә кем!
Ә Рәшидә,
Бу сүзләрдән егылып китәр булып
Чайкалса да, тотып йөрәген:
— Ялган... — диеп пышылдады гына.
Егылмады, түзде, турайды.
Чөнки каршысында кеше түгел,
Ике аяклы җанвар тора иде.
Шулай булды, әйе, шулай булды...
Әйтеп бетермичә сүзләрен,
Башын түбән иде шунда Әнвәр,
Яшерергә теләп күзләрен...
Аннан шыпырт кына чыгып китте,
Беркем туктатмады, дәшмәде...
Рәшидәнең тирән күзләрендә
Балкыдылар җиңү яшьләре.

**17**

Үткән көннәр алар ярылып ята,
Килер көннәр генә сер тулы.
Шуңадыр шул кешеләр ясый хата,
Ах, белсәңче барын берьюлы!
Ах, белсәңче...
Инде ул көннәрдән
Рәшидәне аера ике ел.
Әнвәр белән булган вакыйганы
Онытылыр, үтәр, диде ул.
Юк икән шул, онытып булмый икән...
Көчләп кергән иде күңелгә.
Шик-ышанмау шырпыларын, дуслар,
Чүпләп бетерү җиңел түгел лә!
Галимҗанның аңа сузган кулын,
Юк, алмады кызый, алмады.
«Тәкәббер!» — дип гаепләмәгез һич,
Аның кичерешләрен аңлагыз.
Күңел сынган, хис ватылган чакта
Галимҗанга нәрсә бирсен ул?
Үз гаебе — үзе газаплансын,
Сынау үтсен, янсын-көйсен ул.
Галимҗанны яратамы-юкмы —
Әйтә алмый әле йөрәге.
Комачаулый, комачаулый һаман
Теге җанвар... Әнвәр өрәге...
Эшкә чумды садә Кына гөле
Онытырга теләп газаплары,
Йөрәк яралары турында;
Сагышларын басты Рәшидә тик
Эштә янып булган урында.
Сагышларын басты...
Ай-һай, белмим —
Басылып ук бетте микән соң?
Еллар түгел, гомереңә җитсә,

Гомереңә... ни хәл итәрсең?
Читкә китеп барды аннары кыз,
Озатып калды аны Галимҗан.
Хатлар килеп тора, китеп тора...
Ниләр ул хатларда язылган?
Әйтә алмыйм, белмим —
Ни дисәм дә,
Ялгышырмын: тормыш катлаулы.
Вакыт җиткәч, бәлки, Рәшидәбез
Укытыр безгә әлеге хатларны.
Яшьлек — ярсу, үзенекен итә,
Яңа хисләр белән төренә.
Соңлабрак килер, ләкин килер
Якты көннәр Кына гөленә...

*1962—1972*

## Артист

...Исән калсын киноң, театрың,
Карт артистың — данлы Шункарың.
Тик, ахрысы, хәзер театрны
Аз уйный ул, каһәр сукканың!

*М.Җәлил*

**1**

Ә минемчә, театрны
Күп уйнады ул карт.
Тормыш үзе зур театр.
Вакыйгага юмарт.
Хәтеремдә сакланмаган
Шункар портреты.
Безнең якның үзенчә ул
Хуҗа Насретдины.
Минзәләдә һаман әле
Сугыш елы чорын
Искә төшерәләр җырлап
Артист Шункар җырын.
Аңа һәрчак авыл саен
Түрдә иде урын.

**2**

Минзәлә ярлары биек,
Текә булып менгән.
Минзәлә яры буена
Кем хәзинә күмгән?
Кызыл ярны көрәк белән
Малайлар чокыйлар.
Чокыйлар да кәз-балчыкны
Коялар чокырга.
Көнаралаш бу тирәдә
Атыш булып тора;
Көнаралаш кызыл ярга
Кургаш тулып тора.
Өйрәнәләр сугышчылар,
Атып мишеньнәргә,
Ярты дөньяны яулаган
Фашистны җиңәргә.

— Әйдәгез, әйдә, егетләр,
Көрәкләрне уйнат!
Аксын-тамсын тозлы тирләр
Ач яңаклар буйлап.
Капчыгымда чылтырамый
Минем алтын-көмеш.
Авыр кургаш, саллы кургаш
Булыр безнең өлеш.
Кызыкмыйбыз малга да без,
Кызыкмыйбыз данга.
Өч грамм кургаш җитә бит
Фашист дигән җанга.
Өч килодан өч мең фашист
Җәһәннәмгә китәр.
Әйдәгез, әйдә, егетләр,
Көрәкләрне күтәр!
Һәркайсыгыз өч мең мимеч
Башын кыйса әгәр, —
Герой исеме алырсыз
Әткәгезгә кадәр.
Мәскәүгә медаль-фәләнгә
Барган чакта ләкин,
Мине дә онытмагыз дип,
Юк, әйтмимен, әйтмим.
Гозерем шул: онытмагыз
Капчыгымны бары.
Кирәк булыр —
Кургашынга
Бай Минзәлә яры.
Бүген шәпләп җыеп алыйк,
Ял сезгә иртәгә.
Иртәгә ярны яңадан
Мишеньле итәрләр.
— Пли-коли! Коли-пли!
Төз атарга өйрән...
Ә хәзер шабаш, егетләр,
Биш минут ял бирәм.
Телогрейкам кесәсен
Бушатыгыз әле:
Көлдә аунаткан бәрәңге
Тәмле дә соң, тәмле!

Малайлар тәгәрәп төшә,
«Ура» кычкырышып.
Кош оясымыни, чыр-чу
Килә чокыр эче.
— Фокус күрсәт!
— Фокус! — диләр.
Күрсәтми дә булмас:
Карт кулында бәрәңге һәм
Яньчек пуля-кургаш.

— Коли-пли!
Пли-коли!
Син, бәрәңге — фашист.
Ә син, кургаш, күзне йомгач,
Шул фашистны шап ит!
Әфсен-төфсен,
Җилләр күрсен,

Малайлар күрмәсен
Бәрәңгенең уртасына
Кургашның керәсен.
Сындырдылар бәрәңгене:
Пуля —
Уртасында!
Ярар, фокус кызык булды,
Шунда туктасын да.
Шункар үзе,
Кирәк тапса,
Куяр ноктасын да.

**3**

Данлы Минзәлә базары
Тора гөрләп-кайнап.
Усайлар[1] итек сатсалар,
Байлар[2] сата каймак.
Алыш-биреш, ызгыш-көлеш
Соң ноктага җиткәч,
Сараннар да бер мизгелгә
Юмартланып киткәч,
Кинәт тавыш ишетелә
Базар уртасыннан.
Шундый тавыш —
Һәр кешене
Яшен суккан сыман:
— Янасызмы-пешәсезме
Сату-алу итеп?
Ә миңа соң кем китерер
Җылы киез итек?
Күзләр шунда сөйләүченең
Аякларын капшый:
Аякларда брезент шиблет,
Ул да карны «ашый».
Тыйтак-тыйтак басып менә
Берәү якын килә:
— Сиңа туңарга ярамый,
Шункар туган, ки, мә! —
Капчыгыннан менә дигән
Итек алып бирә.
Шункар, аңа башын иеп,
Ала итекләрне:
— Кая, абзый, атыңны син
Бире китер әле?!

— Кимәдеме?
— Ошатмады...
— Мировой бит итек!
Шункар баса үрәчәгә,
Тора бераз көтеп:
— Рәхмәт сезгә, якташларым!
Итек җылы, һәйбәт.
Ләкин кимим,
Аякларым
Түзәр әле, әйдә!
Ни әйтсәң дә, без бит өйдә,
Окопларда түгел.
Сугыштагы тугандашлар
Туңалардыр бүген.

Кышы да шул бигрәк яман,
Куырып кына ала...
Ә бу итек — бүләк итек —
Ул фронтка бара!

Бер сәгатьтән ике олау
Җылы кием белән
Райком ишеге төбенә
Артист Шункар килә.
— Менә, иптәш секретарь, — ди, —
Базар халкы бирде.
Рөхсәтсез җыйганым өчен
Хет ас, хет кис мине!
Секретарь аның «рапортын»
Тыңлый честен биреп.
Үзе уйлый:
«Йончыган карт.
Исән булсын берүк!»
Аннан түзми, кочаклый да
Рәхмәт әйтә үбеп.

**4**

Әллә сугыш беткән микән? —
Урам тора тулып.
Яше-карты шатланыша:
— Упалнамуч булып
Безгә Шункар үзе килә!
Сынатмаска кирәк.

Килде.
Күрде...
Бер күрсенде:
— Әйдә, туган, көйрәт...
Кемдер чиккән, бүләк иткән
Янчыгын чыгарды.
Төтен бөркеп әйтеп куйды:
— Гармунчыгыз бармы?
— Бар, бар! — диеп йөгереп килде
Юеш борын Хәмит.
Гөжли кызлар:
— Шункар әллә
Күрсәтәме кәмит?
— Упалнамучка ярамас...
— Ярамасын ә ник?
— Вчү-тәки артист кеше.
— Артистын артист та...
— Җырласа, көн дә кирәгер
Йомырка бер дистә...
— Сораса, тапмый да булмас.
— Син, Гайни, бирерсең!
— Апалнай чүмечләрнең без
Беләбез төрлесен...
Мыегына чорный бара
Шункар халык сүзен.
Эшсез көне микәнни соң —
Теле никтер түзем.
Әйтер сүзе булмаганда,
Сөйләнсен нәрсәгә?
Хәмитне җитәкләп алып

Юнәлде кәнсәгә.

— Шункар да үзгәргән бит, әй,
Упалнамуч булгач.
— Бер көлдерсә ярамады...
— Тыгылгандыр умач!
— Уен-муенлык чакмыни,
Рәнҗетмәгез юкка.
— Кара, яклый Гайникамал:
Кертмәкчедер йортка!
— Чиратка куйыйк Шункарны!
— Салырбыз жирәбә!
Ниндидер солдатка түзми,
Кычкырып җибәрә:
— Башкае бетсен Гитлерның!
Ирләрсез дөньямы?!

Һәркем үзенең якынын
Телгә алмый куямы?
Кичке тынлыкта тирбәлә
Әрнү-ыңгырашлы,
Өметле дә, сагышлы да,
Сәер яңгырашлы:
— Сабирым...
— Мансур...
— Вагыйзем...
— Сәйфетдинем...
— Габду...
Искә алу гына түгел,
Әйтерсең дога бу!
Чыдамады Шункар, япты
Кәнсә тәрәзәсен;
Тамактагы төер китсен,
Яшьләр тәгәрәсен...

**5**

Иртә таңнан солдаткалар
Ашыгалар кырга:
Ирләр юк дип торып булмый,
Кирәк бит урырга.

«Солдаткалар, сынатмагыз!
Фронт икмәк көтә.
Һәрбер бөртек —
Пуля бүген...
Йә, дөресме, түтәй?»
Юк, ярамый болай башлау —
Шункар уен боза.
Әле дә бит мескенкәйләр
Агитлауга түзә.
Сүз боткасы тәмле була
Тук чагында карын.
Бәрәңгесен һәм катыгын —
Хәзинәдә барын,
Балалар белән бүлешеп,
Капкалап килгәннәр.
Карасана, сагыштан һәм
Кайгыдан көйгәннәр.

Болар белән күпме генә
Урып була, сугып?!
Кайтырлык хәлләре калмас
Пүтәт чокырын чыгып.
Ач-ялангач эшлим диеп
Нигә маташырга?
Бүген урып, бүген сугып,
Кирәк ашатырга.
Сугыш чоры — закон кырыс:
Фронтка һәр бөртек!
Ишетелсә, куюың бар
Момент Себер китеп.
Ә башкача кая чара?
Бармы техникасы?
Урак белән ачлы-туклы
Еракмы китәсең?..

— Әйдә, — диде председатель, —
Сөйлә, Шункар иптәш.
Эшләве дә җиңеләя
Җылы сүз ишеткәч.
Яшьлек дусты — уракларын
Иңнәренә салып,
Уракчылар да көтәләр
Түгәрәкләп алып.

— Нәрсә әйтим, чибәркәйләр?
Хәлегезне күрәм, —
Шункар сүзен дәвам итә,
Башын иеп түбән:
— Бүген урыйк беркавым без,
Таратып киптерик...
Кыскасы, иртәгә ботка
Ашарлык иттерик.
Бәлки, бу җинаятьтер дә,
Бәлки, ялгышамдыр.
Аванс күк булсын сезгә
Арыш яртышар пот.
Ләкин инде урлау-нитү,
Кесәләргә салу,
Эшләгәндә ялкаулану
Яки соңга калу...

— Булмас! Булмас! — дип бүлделәр
Сүзен Шункар картның.

— Чү-чүегез!
Бер үтенеч:
Карап алдын-артын,
Озын колак ишетмәслек
Итеп эшләү кирәк.
Намусымны-язмышымны
Сезнең кулга бирәм...
Солдаткалар, сынатмагыз!
Соңгы сүзгә күчәм:
Һәрбер бөртек —
Пуля бүген
Илбасарлар өчен!

**6**

Кул тегермәне ярдырган
Арыш боткасыннан
Урамнарга туклык-муллык
Бөркеп чыккан сыман.
Балаларның корсаклары
Футбол тубы кебек.
Әниләре эшкә бара
Шаярышып-көлеп.
Күп кирәкме соң аларның
Күңелен күрергә?!
Тырык-тырык Шункар атлый
Алар белән бергә.
Солдаткалар эшләр бүген
Баш күтәрми кырда.
Моның шулай икәнлеген
Күрерлек сукыр да.
Озын сугыш елларында
Тагын әле күпме,
Ах, хатыннар, сез тартырсыз
Атлар тартмас йөкне!
Шункар шулай көрсенә дә,
Күңеле пошына.
Эче тулы ут үзенең,
Чыгармый тышына.
Солдаткалар сизмәсеннәр
Эшнең ни икәнен:
Районга Шункар өстеннән
Жалоба киткәнен.
Кем җибәргән?
Семьяда
Гарип бетәмени?
Гариплекне белү хәлне
Җиңел итәмени?
Коткарсалар коткарырлар
Солдаткалар гына.
— Икмәк кирәк фронтка! — дип,
Җан атсалар гына...

**7**

Эңгер-меңгер...
Дыңгыр-дыңгыр
Бара чытыр арба.
Солдаткалар мышык-мышык
Озаталар бар да.
Чытыр арба уртасында
Шункар...
Башын игән.
Як-ягында ике конвой
Винтовкалар белән.
Шункар картның, мескенкәйнең,
Ирене селкенә.
Пышылдый ул:
— Озын колак
Ишеткән бит менә...
Солдаткаларның йөрәген
Авыр кайгы баса:
— Яртышар пот арыш өчен
Атарлар лабаса!

Чытыр арба эреп бетә
Басу капкасында.
Китте башы...
Шункар артист
Кабат кайтмас монда...

Атмадылар Шункар картны,
Япмадылар аны;
Солдаткалар якладылар,
Акладылар аны.
Баш ватарлык нәрсәсе юк,
Шунда бөтен хикмәт:
Унбиш көндә урып-җыеп
Тапшырылды икмәк.

**8**

Мәчет-клуб.
Дөм сукыр ул,
Ишегендә йозак.
Кызлар читләп үтә аны
Һәм үтәрләр озак...
Мәчет-клуб — клубмыни,
Амбар инде күптән:
Председатель симәнәне
Сакларга дип керткән.
Иске гадәт буенчадыр —
Стенада игълан:
«Зур тамаша —
КОНЦЕРТ.
Безгә
Шункар үзе килгән!»

Шункар картка сәхнә нигә?
Ярар әле мәктәп.
Колхозчылар утыралар
Парталарга рәтләп.
Ягылмаган салкын класс,
Стенада сыкы.
Толыплылар — бәхетлеләр
Бишәү булып чыкты.
Катлы-катлы шәл уранган
Апалар-әбиләр:
— Туңабыз, — дип, —
Башласын! — дип,
Шункарны әрлиләр.
Стеналар елый башлый,
Сыкы эри бара.
Чаршау корган почмак яктан,
Кара әле, кара! —
Атылып чыкты...
Тик майкадан,
Нинди юләр икән?
Әллә соң ул тән эченнән
Җылы кием кигән?
Яулык белән битен сөртте,
Аннан сүз башлады:

— Туңасызмы, апакайлар? —
Биеде кашлары. —

Сез туңасыз, миңа эссе!
Юк, уен сүз түгел.

Кем ишетте, ни сөйләде
Информбюро бүген?
Эссе...
Эссе...
Металл эри
Идел буйларында.
Ирләрегез ут эчендә,
Гел сез уйларында...
«Халидәм бирешми микән?» —
Дип борчылса Мансур,
Вагыйз окопта күрсенә:
«Туңадыр, — дип, — Алсу...»
Габдулла, Әхмәт, Гаязлар
Автоматын кысып
Хыяллана:
«Эх, кайтырга
Кошлар кебек очып...
Малга — печән, йортка — утын,
Балаларга — азык
Әзерләп киләсе иде,
Буыннарны язып.
Дошман тагын атакага
Күтәрелә инде.
Баш очында үлем-пуля
Бөтерелә инде.
Бирешмәбез,
Нык торырбыз,
Нык торса хатыннар...»
Солдатларның сездән ныклык
Сорарга хакы бар!
Аклыйк алар ышанычын,
Сыгылмыйк, егылмыйк.
Ирләр анда, ә без тылда
Батыр солдат булыйк.
Катлы шәлләр чишеләләр.
Толып төшә шуып:
Солдаткалар торып баса,
Бил каешын буып.
Күзләргә очкыннар куна,
Йодрыклар төйнәлә.
Эссе...
Эссе...
Эссе...
Эссе
Тарала өйләргә.

Үзе уйнап,
Үзе җырлап,
Үзе биеп, Шункар
Янып чыккан —
Йөрәкләрне
Яндыргандыр шуңар.

**9**

Шункар артист күптән вафат,

Исеме —
Кыйссаларда...
Ул кыйссалар кай тарафка
Килеп чыксалар да,
Табалмассыз Шункар картның
Тышкы портретын.
Сугыш чорында тылдагы
Ул бер Вася Теркин.
Берәү сөйләр:
— Пеләш иде...
Берәү сөйләр:
— Чәчле...
Җыеп буламыни сүзнең
Барын түкми-чәчми?
Шункар хакында кыйссалар
Күбәү алар, күбәү.
Инде миңа да кирәктер
Сүзне түгәрәкләү.
Уйнады карт ул елларның
Иң баш рольләрен.
Бик үкенеч:
Муса батыр,
Син шул күралмадың.
Озак гомер үткәч, менә
Җырда күрештегез...
Халкымның кайгы-шатлыгын
Озак бүлешегез.
Кыйссаларда мәңге яшәү —
Сезнең өлешегез.

*Казан—Минзәлә—Казан*
*1966*

## Көмеш әкият
## (балалар өчен шыгырьләр)

Ак кәгазьдәй кыр-басуда
Төлке-куян эзләре...
Күчер дә ал хәтереңә —
Шигырь гүя үзләре.

## **Йөгерек гөрләвек**

*(Җыр)*

Гөрләвек йөгерә
Якты язны күрергә.
Йөгереп кенә уйный торган
көннәр лә!
Дәртләнеп, гөлдерәп,
Йөгер тизрәк, гөрләвек,
Гөлдерәвең көенә җырлыйк бергә.
Әй матур да көндер,
Дөнья аллы-гөлледер!
Йөгер, гөрләвек,
Лә-лә, лә-лә-лә...

Йөгерик, йөгерик, йөгерик,
Кояш нурларын күрик,
Йөгерик бергәләп,
Йөгер, гөрләвек.

Һавалар зәп-зәңгәр,
Әйтерсең бизәгәннәр.
Сайрар кошлар куанган,
кинәнгәннәр,
Ияреп җырласын,
Бик оялып тормасын
Безнең белән бергә җырлыйк, дигәннәр.
Әй матур да көндер,
Дөнья аллы-гөлледер!
Йөгер, гөрләвек,
Лә-лә, лә-лә-лә...
Йөгерик, йөгерик, йөгерик,
Хыялга ирек бирик,
Йөгерик бергәләп,
Йөгер, гөрләвек!

## Ташу

Ташу җиткән, боз ага!
Боз өстендә яз ага!
Чаптык елга ярына:
Анда бозлар ярыла,
Боз ярыла шарт та шорт —
Без торабыз шаккатып.
Кайнар кояш нурлары
Ашый гына бозларны:
Кәрәз-кәрәз боз челтәр
Коелып төшә челтерәп.
Менә бу боз нык әле,
Өстендә уйныйк әле!
Утырып агыйк әле,
Зур учак ягыйк әле!
Ләкин сак булыйк берүк:
Боз эчкә агып кереп
Йә сиздермичә эреп,
Коелып төшмик суга —
Коенмыйлар ташуда.
Җәйдә тын гына елга
Җимерә барын юлда,
Карап тормый бернигә,
Сорап тормый: ник? Нигә?
Агыза кибәннәрне —
Аксынга өйгәннәрме! —
Агачларны аудара,
Ком-ташларны актара—
Суны, бар, тотып кара!
Ул котырган, ул ярсу —
Менә шундый ул ташу!

## Яз бүләге

Яз — шук бала!
Җир-әнкәнең
Кар тунын

Әй ерткалый,
Шәп һөнәре
Бар аның.
Ачуланмый
Әнкәсе дә
Улына:
«Эшчән бала!» —
Дип сөенә
Ул моңа.
Кат-кат теккән
Туны күптән
Искергән;
Көне җиткән:
Тузып беткән
Төс кергән.
Тырыша яз
Җан-фәрманга,
Карачы!
Тормышта яз
Гел яңага
Барасы.

Әнкәсенә
Нинди бүләк
Яшергән?!
Әйтми генә —
Тегә күлмәк
Яшелдән!

## Мөгез нигә кирәк?

Озын мөгезле булсаң да,
Усал түгел бит үзең:
Әллә безне куркытырга
Кирәкме соң мөгезең?
Кәҗә, кәҗә, мәкәрҗә!
Мөгез нигә, ә, кәҗә?

Челтәрләнгән язгы бозны
Тоягы белән ватып,
Кәҗә килә вак-вак атлап,
Кәҗә килә тып та тып.
Кәҗә әйтә:
— Үртәшсәгез,
Күрсәтермен мин сезгә:
Нигә икәнен белерсез,
Эләксәгез мөгезгә!
Тизрәк йөгерегез, йә!

## Сыерчыклар туган көн

Уң якта да «чи» дә «чи»!
Сул якта да «чи» дә «чи»!
Аптырый безнең мәче:
Бер имәнгә менмәкче,
Бер чормага кермәкче,
Шомландырып йөрмәкче! —
Очып куна сыерчык —
Мәчегә тик таяр чак!

Кошлар бала чыгара...
Ә ул бала-чагага
Никадәр азык кирәк!
Сыерчыклар тизрәк
Эләктерә чебенен,
Эләктерә черкиен,
Таба ул суалчанын...
Балалар булгач, җаным,
Аларның һәрберсенә,
Алтысы-җидесенә,
Иртә белән утыз кат,
Көндезен дә утыз кат,
Кичкегә дә утыз кат
Чебен-черки тотып кайт!
Кайчан үсеп җитәрләр,
Кайчан очып китәрләр?
Ә хәзергә «чи» дә «чи»
Ни эшлисең, чиләнми!
Уң якта да «чи» дә «чи»,
Сул якта да «чи» дә «чи»!
Чиелдәшеп торган көн,
Сыерчыклар туган көн!

## Тырый-тырый-тарый!

*(Җыр)*

Тырый-тырый-тарый!
Җыр җырларга ярый.
Күктән кояш карый,
Чәчне җилләр тарый...
        Ай-ли, һай-ли-лә,
        Бер сүз әйтми әни дә!
Тырый-тырый-тарый!
Уйнап йөрү ярый.
Өйдә яткан арый,
Җен-пәридәй карый...
        Ай-ли, һай-ли-лә,
        Безнең урам ямьле лә!
Тырый-тырый-тарый!
Урам безгә тар, ди.
Котыпларда кар, ди,
Ак аюлар бар, ди...
        Ай-ли, һай-ли-лә,
        Шунда китмим мин нигә?
Тырый-тырый-тарый!
Хыялландык, ярый.
Инде эшләп карыйк,
Эшләгәндә армыйк.
        Ай-ли, һай-ли-лә,
        Эшле дөнья ямьле лә!
        Ай-ли, һай-ли-лә,
        Эшләү үзе тәмле лә!

## Казлар очканда

Кыйгачлап-кыеклап,
Каңгылдап-кыйгылдап
Үткәнен кыр казы кәрваны,
Йолдызлар эзеннән,

Зәңгәр күк йөзеннән
Иртәнге һаваны ярганны
Күзәтә балалар,
Туктап тын калганнар —
Хыялы-уйлары казларда:
«Их, шулай очсаң бер!
Күкләрне кочсаң бер
Күңелне җилкеткән язларда!»
Как-кыйгак!
Юл ерак,
Юл авыр,
Юл озак —
Түземлек, көч кирәк очарга.
Тормыш ул — озын юл,
Чыдам бул, түзем бул,
Теләсәң казларга охшарга.
Һич түгел юләрлек
Кошларга иярү,
Ашкыну хыялың күгенә.
Канатлан син, рухлан,
Максатны куй зурдан,
Әзерлән очарга бүгеннән.
Как-кыйгак!
Кыр казы
Күкләргә җыр яза,
Йөрәкне кузгата җырлары.
Көтәләр йолдызлар
Малайлар-кызларны,
Көтәләр Киек Каз Юллары.
Как-кыйгак...
Как-кыйгак...

## Дачага бару

— Шәһәрдә җәй җәймени!
Бер яме юк, — ди әни.
Әти әйтә әнигә:
— Бармыйбыз әле нигә
Үзебезнең дачага,
Дачадагы бакчага?!

Булат бии, кул чаба,
Мин дә бииm, кул чабам.

Бик тәти минем әни,
Бик тәти минем әти.

«Булат тәти» дип әйтмим:
Үзе абый, ә үзе,
Йомган була да күзен,
Минем чәчемнән тарта,
Шулай гел аптырата.

— Безнең бакча кай якта?
— Поездлар йөргән якта.
— Поездлар йөри кайдан?
— Кайдан булсын, вокзалдан!
Шулай сөйләштергәләп:
— Әни, булыш! — дигәләп,

Киенеп тә беттек без,
Өйдән чыгып киттек без.

Ул вокзалда күп халык!
Ничек бетми буталып?
— Адашып кала күрмә!
Бик алга да йөгермә!
Абыең белән бергә
Шушы вагонга кер дә
Утыр тыныч кына, — ди.
Кем булсын инде? Әни!

Өйрәтсә мине әни,
Тәти түгел әллә ни...
Әти — тәти! Әрләми.

Безгә билетлар алып,
Мо-ро-же-но-е алып,
Әти дә килеп керә,
Керүгә безне күрә...

Мо-ро-же-но-е тәмле!
Йотарга мөмкин телне.

Юлданиләр күрдемме?
Күрмәдем... белдеңме?!
Мо-ро-же-но-е кебек,
Бик тиз киткәнмен эреп.
Әйе инде, йоклап шул,
Мин бик, бик, бик йоклак шул.

Бу әти дә кызык бик:
— Килеп җиттек, кызым! — ди.
Имеш, килеп җиткәнбез—
Тик поездда төшкәнбез.

Поезд — бакча арасы—
Барасы да барасы!
Барабыз урам буйлап,
Барабыз урман буйлап,
Барабыз басу буйлап,
Барабыз без су буйлап...
Тимер күпер чыгабыз,
Туктарга юк чамабыз...
Имәнлекне үтәбез,
Наратлыкка җитәбез...
Калкулыкка менәбез,
Уйсулыкка төшәбез...
Әлсерәшеп бетәбез...
Уф-ф-ф!

— Атлый алмый аягым,
Бирче, Булат, таягың...
И, таяк миңа нигә?—
Күтәртәмен әтигә.

Инде елыйм дигәндә,
Мышык-мышык килгәндә,
Булат кычкыра: — Ура!
Капкабыз ачык тора. —

Ул безне ашыктыра.

## Исәнме, бакча!

— Исәнме, әй, алмагач!
Моңсумы без булмагач?
Яңгырларны эчкәнсең,
Зуп-зур булып үскәнсең.
Пешәме алмаларың?
Пешкәннәрен аларның
Дүрт күз белән көтәбез
Булат белән икәү без.
Булатның күзе ике,
Тагын ике — минеке!
Дүрт була ике икең—
Моны кем белми икән?!

— Исәнмесез, чияләр!
Әллә сезгә тияләр?
Куяннар кимермиме?
Кояш бик көйдермиме?
Башыгызны имәгез,
Җиргә кадәр тимәгез—
Кортламасын, черемәсен,
Тәмсез тәмнәр кермәсен,
Чиягез күп-күп булсын,
Кызарып-пешеп торсын,
Без икенче килгәндә!

— Исәнме, кура җиләк!
Торалар, әй-яй, гөжләп
Тирәгездә шөпшәләр—
Балыгызны эчәләр.
Бармак яныйм шөпшәгә:
«Баллы булып пешәргә
Җиләкләргә бал кирәк.
Ә сез комсызлар бигрәк—
Эчәсез дә эчәсез,
Туймас тамак шөпшә сез!
Кулга чыбык алырмын,
Курыкмыйча барырмын,
Хәзер түгел, көз җиткәч,
Сез очып китеп беткәч...»

Ә хәзергә мин әле
Сиңа, кура җиләге,
Ерактан гына дәшәм,
Курка-курка сөйләшәм—
Чакмасыннар шөпшәләр!

Онытып калдырганмын:
— Исәнме, карлыганым!
Карлыганның агы син—
Бер генә куагым син,
Суны үзем сибәрмен,
Иркәләрмен, сөярмен,
Пеш кенә син тизрәк,
Синең пешүең кирәк.
Кайтканда ерак өйгә—
Авылдагы әбигә

Җыярмын күчтәнәчкә.
Син үзең белмәгәч тә,
Үсә анда, авылда
Кара карлыган гына.

— Түтәлкәем, исәнме!
Кыярларың үсәме?
Кая соң, эзлим әле.
Юк инде, өзмим әле!
Үссен алар бәләктәй,
Алар әле бәләкәй.
Өзсәм дә... берне генә...
Өзәм мин юри генә...
Менә икән син, менә!
— Зөһрә, кыярга тимә!—

Кем булсын инде? Әни!
Күрде дә мине әрли...
— Әйдә, ашарга кер, — ди,
Күрешергә дә бирми.

Көтеп тор, бакчакаем,
Ашап кына чыгаем...

## Һава сибү

Кызык безнең дачада,
Дачадагы бакчада.

— Түтәлләр тигез-тигез
Үссеннәр, үссен, — дибез.
Утыйбыз да чүпләрен,
Йомшартабыз төпләрен;
Ашламасын бирәбез,
Яудырып су сибәбез —
Безне ялкау димәгез!
Кара әле, су сипкәч,
Көн буе кояш өткәч,
Кибеп каткан төпләре —
Боек шалкан түтәле:
Яфраклары салынган,
Үтеп булмый яныннан.
Ярдәм итәргә кирәк
Тиз-тизрәк лә, тиз-тизрәк —
Һава сибәргә кирәк!
— Менә син дивананы!
Сибәләрме һаваны?—
Шулай диеп әйтсәгез,
Бергә сибик, әйдәгез.
Сибәләр шул һаваны —
Бик гади ул дәваны
Эшләп күрсәтик әле:
Шиңгән шалкан түтәле
Күтәрелсен яңадан,
Дәва алып һавадан.
Менә болай иттереп,
Бөтен шартын китереп,
Йомшарткачтын, күпереп
Китә шалкан түтәле —
Кирәк түгел бүтәне.

Туфрак аша һава
Ага да ага, ага...
Шул инде дәва аңа,
Шул инде сибү һа-ва!

## Курчак уены

И син, Ләйлә — курчагым!
Синең дә уйнар чагың,
Минем дә уйнар чагым.
Уйныйк әле икәү без,
Сагынышкан икәнбез!

Бардык та без комлыкка
Уйнарга тотындык та.

Комлыкта рәхәт инде!
Булатка рәхмәт инде:
Тубын шунда калдырган,
Эзләр әле ахырдан.

Мине тыңла, син, Ләйлә,
Әйдәле, әйдә, әйдә,
Уйныйк әле туп чөеп:
«Мин чөям, син тот!» — диеп.

И кулларың, кулларың!
Тупның килеп кунганын
Көтмә авыз ачып син,
Тот тизрәк, ашык син!
И туп читкә сикерә...

Алайса менәтерә
Комга күмик без аны,
Тормыйк бер дә кызганып.
Булат килсә — күрмәдек,
Тупны комга күммәдек!
Менә шулай!

Әллә ардың да, Ләйлә?
Йокың киләме әллә?
Кил, алдымда тирбәтим,
Әлли-бәлли көйләп мин.
Әлли-бәлли, әлли лә,
Әләкләшмә энигә.

Синең белән икәү без
Буялышып беткәнбез.
Каралса да күлмәгем—
Син күрмәдең, белмәдең...
Хәзер менә салам да,
Комда юып алам да,
Киптерәм дә үтүклим—
Сандалием — үтүк, дим.
Ә син йокла!

Уяндыңмы? Кайтыйк без:
«Кайттык», — диеп әйтик без.
Йә килер әни эзләп,
Эләгер аннан безгә!

Инде Ләйлә белән без

Икәү кайтып киләбез.

Миләүшә апа — күрше:
— Күрче, Зөһрә, — ди, — күрче!
Буялыплар беткәнсез
Ләйләң белән икәү сез.

Әйдә, килегез әле,
Суга керегез әле:
Юыныйк, чистарыныйк,
Ком-тузаннан арыныйк.
Миләүшә апаларның
Ваннасы бар аларның
Алмагачы төбендә.
Суы җылы бүген дә!

Минем ялангач тәнне
Карап тормагыз, яме—
Оялырмын...

## Зөһрә нигә керә?

Кызык безнең дачада,
Дачадагы бакчада.

Йөгерә-йөгерә керә
Күрше кызы Зөһрә.
Шул дүрт яшьлек Зөһрә
Интектереп бетерә:
— Суган әче ни өчен?
Әллә шуны белмисең?
Әче...
    әче... ул суган—
Ул суган әче судан!
Ә су әче...
Юк, төче...
Әем, әем,
Әйтмәем:
Ачулана әнкәем!
Ул бераз тынып торыр,
Аннары кызыктырыр—
Өзеп алып бер кыяр,
Керт итеп тешләп куяр:
— Безнең Булатның теше
Кыяр тешләгәч төште...
Ә мин кыяр ашамыйм,
Өзсәм, ташлыйм...
Ташламыйм...
Әем, әем,
Әйтмәем:
Ачулана әнкәем!
Өзеп алса бер җиләк,
Тагын сөйләргә кирәк:
— Сезнең җиләк тә тәмле,
Сезнең бакча да ямьле...
Ни өченме?
Ни өчен?
Әллә шуны белмисең?
Әем, әем,
Әйтмәем:

Ачулана...
Юк...
Колагыңа әйтәмен:
Ачуланмый әнкәем.
Шуңа сездә гел ямьле.
Әче суган да тәмле.
Һап!
Өз дә авызыңа кап!
Менә шулай...

## Кызыга...

Кызык безнең дачада,
Дачадагы бакчада.

Тагын йөгерә-йөгерә
Килеп керә Зөһрә:
— Миләүшә апа, нишлисең?!
— Эшлимен тиешлесен:
Чүп утыймын, акыллым,
Яле, булыш, алтыным!
Кызның авыз турсая:
— Тукта, туктап торсана!
Үләннәр бәби, нәни—
Сорамыйча өзмә, — ди.
— Мин бит чүпләрен
йолкам...
— Ә мин йолкырга куркам.
Бездә дә үләннәр күп—
Әллә кишер,
Әллә чүп?
Тик өзәргә ярамый
Әниемнән сорамый...
Кайсысы нинди үлән—
Мин әле белмим...
Беләм...
Әем, әем,
Әйтмәем:
Ачулана әнкәем!
Ә син белеп эшлисең,
Бик белдекле кеше син,
Әйеме?!

## Су керү

Кызык безнең дачада,
Дачадагы бакчада.

Сул ягыбызда — Идел,
Уң ягыбызда — Зур Күл,
Аяк очында — култык!
Без тәмам үрдәк булдык:
Иртән үк йөгерәбез—
Туйганчы су керәбез.
Чупыр-чупыр чумабыз
Култыктагы суга без,
Кайнар комга чыгабыз,
Сузылышып шунда без

Тезелешеп ятабыз—
Кара яна аркабыз.
Кояш өтә, пешерә,
Суны искә төшерә.
Тагын суга чумабыз,
Тагын комга чыгабыз.
Мактанабыз:
— Мин кара!
— Син менә мине кара!
— Ә мин негр шикелле...
— Ә мин чумдым бер илле...
— Ә син тиле, шыр тиле:
Куба аркаңнан тире!
Менә шулай җәй буе
Култыкта «пәри туе».
Әй рәхәт соң, әй рәхәт!

...Бервакыт безгә Әхәт
Килеп төште кунакка
Берәр айга — озакка...
Әхәт — авыл малае.
Анда авылда әле
Юк Идел дә, Зур Күл дә
Туйганчы су керергә.
— Әйдә, — дидем Әхәткә, —
Су керү бик рәхәт лә!
Иртүк торып йөгердек—
Төшкә хәтле су кердек.
— Ну шәп кыза, шәп кыза!
— Бу Әхәт безне уза!
Аннан сугыш уены
Уйнадык көне буе...

Ә төнләме, ә төнлә
Әхәт «яна төтенләп»!
Әни сөртә вазелин:
— Ерма, — ди ул, — авызың!
Харап кына иткәнсең—
Миһербансыз икәнсең...
— Ни өчен миһербансыз?
Сугыш булмый корбансыз!
Әхәт түзем, шәп егет:
Елап тормады җебеп.
Үпкәләп тә йөрмәде—
Тик су гына кермәде.

## Урманга бару

Кызык та бит дачада,
Дачадагы бакчада—
Якында гына урман,
Гел кызыктыра торган.
Ә урманда — кош-җәнлек,
Тик берсен дә күргән юк!
Киттем шулай урманга—
Тотмаммы аю анда?
Урман куе, караңгы—
Тәнгә курку таралды.
Кемнәрдер карый сыман

Агачлар арасыннан.
Нәрсәдер кыштырт итә,
Ә мин сискәнеп китәм.
Ботаклар шыгырдаша,
Серләшә-пышылдаша.
Яфраклар җилбердәшә...
Арттан килеп берәрсе
Кинәт китереп бәрсә—
Аюмы, шүрәлеме!—
Ярырлар йөрәгеңне...
Мин тизләтәм адымым,
Атлый-йөгрәм, абынып.
Ә йөрәгем тук та тук:
Бу урманданиләр юк!
Ачылды урман алды—
Куркуларым таралды.
Тор да йөгер дачага,
Дачадагы бакчага!

## Казанга кайту

— Сизелмичә дә калды,
Үтте ике көн ял, — ди.
Әллә соң әни алдый?
Ял итмәдек бер дә без!
Хәзер әйтеп бирәбез
Кем нәрсә эшләгәнне,
Ял искә төшмәгәнне.

Әти су сибеп йөрде,
Койма коеп бетерде,
Астын өскә китерде—
Бакчаны ялт иттерде!

Әни сулар китерде,
Керләр юды, киптерде,
Ашарга да пешерде,
Гөлләрне дә күчерде,
Күршеләргә дә керде—
Сөйләшеп утырырга!

Булат балыкта йөрде:
— Тота яздым, — ди, — берне!
Аннан комда туп типкән,
Тубын калдырып киткән,
Ул шуны эзли икән:
— Белмисезме? — ди икән.
Беләмен дә белүен —
Тупның кайда күмелүен
Әйтимме соң?

Ни эшләдемме үзем?
Үзем, үзем, мин үзем,
Күп уйнасам да, түздем:
Еламадым, армадым,
Әнигә зарланмадым!
Зарлансаң, безнең әни:
— Кайтыйк инде өйгә, — ди.
— Зөһрә тулып килә, — ди.

— Тулышыр да түгелер,
Күршеләрне көлдерер.
Алып килмәбез башка—
Килешми аңа бакча!

Ә бу юлы, бу юлы,
Ерак булса да юлы,
Кайтканда да түздем мин—
Тәпиләдем үзем мин
Тимер күпергә кадәр!
Әти алмаса әгәр
Күтәреп кочагына,
Белмим шул, ул чагында...
Ул чагында...
Әтинең кочагында...
Күз йомыла... и рәхәт...
Әтиемә бик рәхмәт...
Әниемә дә рәхмәт...
Телем әйләнми рәтләп...
Йокым килә... Хуш, дача!..
Йоклыйм мин. Ка-зан-га-ча.

## Иң-иң...

Бездә кырлар иң-иң ямьле,
Бездә сулар иң-иң тәмле,
Бездә җырлар иң-иң матур,
Бездә дуслар иң-иң тату.
Иң-иң, иң-иң...
Безнең як бу!

Иң-иң җылы безнең җәйдер,
Иң-иң ява безнең яңгыр,
Иң-иң агы безнең кардыр,
Иң-иң биек безнең таудыр.
Иң-иң, иң-иң...
Безнең авыл!

Иң-иң әби-бабай бездә,
Иң-иң апа-абый бездә,
Иң-иң әти-әни бездә,
Иң-иң тәти бәби бездә.
Иң-иң, иң-иң...
Үзебез дә!

Кем ышанмый минем сүзгә:
«Алдаша, — ди, — карап күзгә», —
Кышта-язда,
Җәйдә-көздә
Бер кунакка килегез лә
Иң-иң элек үзебезгә!
Иң-иң, иң-иң...

## Авыл җәе ямьлерәк...

Илшат китте авылга,
Их, ияреп барырга!
Барыр идем дә менә...
Мин йөзү мәктәбенә—

«Дельфин»га йөрим хәзер—
Йөзәргә өйрәнәбез.
Әйтерсең юк авылда
Агымсулы Ык-елга!
Әйтерсең анда бары
Коена авыл казлары!
Әйтерсең алтын-сары
Комлык түгел Ык яры!
Илшатның эш рәхәттер,
Менә инде бәхеттер
Кызыну да су керү,
Ярдан суга сикерү!
Ул балыкка баруы,
Эләгер дип иң зуры...
Әнинең сүзен тыңлап,
Бассейнда чупырдап
Ятсам да менәтерәк,
Авылда әйбәтрәк,
Авылда җәй ямьлерәк,
Белдегезме?!

## Салават күпере

Яңгыр белән кояш нуры,
Үрелеп бергә-бергә,
Әверелде аллы-гөлле
Салават күперенә.
Шундый матур дугаланып
Балкыды ул аннары!
Иңләде,
Кочты,
Буйлады
Елга,
        кыр,
                урманнарны.
Күк йөзенә ука чуклы
Билбау булып ятты ул.
Күңелдәге якты хыял—
Хисләрне уятты ул.
Яшеннәре дә уйнасын,
Күкләре дә күкрәсен—
Тукта,
Сүнми тор,
Өзелмә,
Салават күпере, син!
Бер генә йөгереп узыйм
Синең аша,
Бер генә!
Матур төштәй шул мизгелне
Мин онытмам гомергә.

## Шаян җил

Чыгып әллә каян гел,
Исәсең син,
Шаян җил!
Исәсең,
Тик тормыйсың,
Беркемгә тоттырмыйсың.

Бер карасаң —
Талларда
Керешәсең шауларга.
Бер карасаң —
Камышта
Төрле-төрле тавышка
Җырлыйсың,
Сызгырасың,
Кошлардан уздырасың.
Ул арада,
Кай ара
Килеп җиткәнсең,
Кара!—
Чәчемне чуалтасың,
Юриме шаяртасың?
Шаян җил,
Иллә мәгәр
Хәйләкәр син,
Хәйләкәр!
Күзгә күренеп иссәң:
«Качышлы уйныйк!» —дисәң,
Уйнар идек туйганчы—
Мин арып,
Син тынганчы!
Тел күрсәтеп сиңа мин,
Качар идем өйгә, дим.
Өйгә кермәс идең син,
Эзләп йөрмәс идең син.
Кызганыч,
Бик кызганыч—
Уйнап булмый шул качыш.
Буш исүдән ни файда?
Тукта әле!
Чү!
Кая?..
Кая киттең?
Кил әле!
Нигә тындың,
Җил, әле?
...Җил тынды,
Юкка чыкты.
Әйтегез,
Кем куркытты?

## Җәйге болында

Әй күңелле була икән
Көләч көндә җәйге болын!
Бабай әйтә:
— Яшел болын
Сиңа көлә, Илшат улым.
Син килә дип, карлыганнар,
Кара, ничек каралганнар;
Гөлчәчәкләр болыт буйлап
Йөгерешеп таралганнар.
Зәңгәр күлдә төнбоеклар
Алтын төймә булып үскән;
Сине көтеп, кояш үзе
Салкын суга тамып төшкән.
Әнә яна нәни фонарь—

Тулышкан кызыл бөрлегән,
Тизрәк табып алсыннар дип,
Балкыган шулай, өлгергән.
Чикерткәләр җырын тыңла,
Быжылдасын төклетура.
Җәйге болын байлыгына
Хуҗа булып кеше тора.
— Бабай, — димен, —
Ә мин — кунак!
Безнең өебез шәһәрдә...
Бабай әйтә:
— Син дә хуҗа,
Яратсаң җирне әгәр дә.

## Көмеш әкият

Яшел хәтфә болында,
Түгәрәк күл буенда
Бүген төнгелеккә без—
Төнлә атлар көтәбез.
Шундый серле,
Шундый тын...
Йокыда төнге болын.
Күк йөзендә көмеш ай—
Көмеш берлек акчадай.
Күл өстенә сузылган
Көмеш юл көмеш нурдан,
Суда елык та ялык
Сикерә көмеш балык.
Көмеш ярда көмеш ком,
Ком ялый көмеш дулкын.
Йоклый көмеш камышлар.
Йоклыйлар көмеш кошлар
Көмеш сарган талларда—
Уяныр лар таңнарда.
Көмеш күл,
Көмеш болын...
Көмеш ат,
Көмеш колын...
Бүген төнгелектә без
Көмеш атлар көтәбез.
Көмеш тынлык,
Көмеш төн
Кочкан көмеш җир өстен...
Көмеш куыш эчендә,
Күреп көмеш төш кенә,
Йоклыйсы иде дә бит,
Йоклыйсы килми лә бик!
Көмеш-көмеш дөньяда
Без яккан учак яна...
Төнге учак ялкыны
Ялмый көмеш салкынны.
Үрли-үрелә ялкын...
Көмеш ай,
Йөрмә якын —
Төшәрсең ялгыш утка,
Чыгарсың эреп юкка.
Син эрерсең дә...
Кинәт
Сүнәр көмеш әкият...

## Чыклы физзарядка

Кайсыгызның иртә таңда
Көмеш чык күргәне бар?
Чыклар ярып, яланаяк
Йөгереп йөргәне бар?
Моның өчен бабай белән
Болынга бару кирәк.
Көне буе печән чабып
Бик каты ару кирәк.
Яңа чабылган печәннән
Бер куыш ясау кирәк,
Йокларга ятканчы, әле
Ипи-сөт ашау кирәк.
Аннары бабайдан кызык
Әкият сөйләтү кирәк,
Йомшак печән өсләрендә
Йоклар өчен изрәп.
Аннарымы? Аннары шул—
Сызылып ата таңнары!
Кошлар сызгырып уята
Күп йоклап ятканнарны.
Йомшак, җылы куышыңнан
Син йөгереп чыгасың.
Боз энәләр тезгәнмени—
Басып кара чыкка соң!
Куркытылган куян кебек,
Куясың да сикереп,
Болын өсләп элдертәсең,
«Ми-ха-ха-хай!» иттереп!
Аякларың уттай яна,
Өтәли яшел үлән.
Коендырып юып ала
Салкын, көмеш чык белән.
Һай-һулап кычкырганыңны
Ишетеп торган кебек:
«Хәзер җылытырмын!»—диеп,
Кояш үрелә көлеп.
Кояш көлә,
Бабай көлә,
Мин көләм—
Безгә кызык!
Туктый алмый йөгереп үтәм
Куыш яныннан узып.
Бабай әйтә: «Сиңа, улым,
Ясарга кирәк аны,
Һәркөн иртән иренмичә,
Чыклы физзарядканы!»
Тәнемдә уйный җиңеллек,
Җаныма шундый рәхәт:
Чыклы физзарядка өчен
Чыклы болынга рәхмәт!

## Өйрәнегез ат менәргә

Велосипед,
Мотороллер, —
Сүз дә юк!—

Шәп нәрсәләр.
Сез менә нәрсә әйтерсез,
Әгәр дә өйрәтсәләр,
Ярсу атларга атланып,
Җилдән җитез җиләргә,
Сабантуй бәйгеләрендә
Беренче,
Баш килергә?
Ә?!
«Сабантуй» дип сөйләнсәм дә,
Анысы әле хыялда.
Атка атландым тәүге кат
Бабайларда мин,
Ялда.
Ул каеш йөгәннәре лә!
Ул муен дигәннәре!
Юыртканда,
Җир селкетеп,
Дөп тә дөп килгәннәре!
Бабай әйтте:
«Илшат улым,
Киләсе ел җәенә
Үзем әзерлимен сине
Сабантуйга—
Бәйгегә!»
Шулай итеп,
Бабай мине
Өйрәтте ат менәргә —
Юыртып та,
Чаптырып та,
Һай-һулап та үтәргә.
Сабантуйда чабармынмы —
Анысы әле билгесез.
Атта җилү иллә рәхәт!
Сез, малайлар, белмисез...
Велосипед,
Мотороллер, —
Сүз дә юк!—
Шәп нәрсәләр.
Өйрәнегез ат менәргә,
Әгәр дә өйрәтсәләр.
Үкенмәссез!

## Җиләккә бару

«Җиләккә барабыз», — дигәч,
Дәү әни тырыс бирде:
«Шушы тырысың тулганчы
Җыярга тырыш!» —диде.
Җиләкне мин ашамаска,
Күп җыярга тырыштым.
Би-и-ик тырыштым.
Би-и-ик тырыштым!—
Тик тулмады тырысым...
Әллә соң җиләк дигәне
Пешмәгән,
Үсмәгәнме?
Җиләк пешүен пешкән дә,
Мин үзем пешмәгәнмен.

Шәһәр малаеннан җиләк
Качып тора икән ул.
Каушата,
Кабаландыра,
Ашыктыра икән ул.
Кабаланган саен үзен
Табуы кыен икән.
Җиләк җыю дигән уен
Бик кыен уен икән.
Тырыс тулмаганны күргәч,
Күңелем төште минем.
Малайлар,
Билгеле инде,
Сизгәннәр эшне минем.
«Җиләк җыям,
Как коям, дип,
Дәү әнигә бүләккә...» —
Җырлый-җырлый җыйды алар
Тырыска да чиләккә.
«Монда җиләк күп икән...» — дип,
Минем тулмас тырысны
Кып-кызыл җиләкләр белән
Дусларым тутырышты.
Җиләккә барган чагында
Ярый нинди тырыс та.
Тырыслардан да бигрәк,
Кирәк икән чын дуслар!

## Илшат авылда булган

Малайлар сагынышкан,
Малайлар җыелышкан,
Тыгыз түгәрәк ясап,
Бер-беренә елышкан.
— Исәнме, дус!
— Нихәл, дус! —
Зурларча күрешәләр.
Кем кайда да,
Кем ничек? —
Сөйләргә керешәләр.
Айдар быел ял иткән
Балалар лагеренда.
Сәлим Мәскәүдә булган —
Ерак апаларында.
Азат булган Артекта,
Булат булган Себердә.
— Мин, — ди Илшат, — еракка
Китеп йөрмәдем бер дә.
Мин, — ди, — кайттым кунакка
Бабайлар авылына.
Идел кичеп күтәрелдем
Зур Ослан тавын гына.
Тау артыннан башлана
Сап-сары бодай кыры.
Шунда беренче тапкыр
Ишеттем тургай җыры.
Шунда бодай урдык без
Миргалим абый белән.
Комбайнны мин хәзер

Йөртеп тә карый беләм!
Ә берсендә, малайлар,
Чыктым төнге уракка.
Төне буе күзләде
Күктән безне урак ай.
Комбайннар уралар,
Нур чәчеп көлтә-көлтә.
Машиналар бодайны
Чак-чак ташып өлгертә.
Белдем суккан бодайның
Җылы, рәхәт икәнен,
Хәтта бодай өстендә
Бер черем дә иткәнмен!
Анда әле бер күл бар,
Ерак түгел басудан.
Кара-чутыр иттереп
Биткә утыргач тузан,
Урып-эшләп арыгач,
Йокы төшкәч күзләргә,
Күлгә бара идек без
Колач салып йөзәргә.
Тузан белән йокыны
Юып ала салкын су.
Кызарып таң атканда,
Офык яна ялкынсыз...
Дулкынлана басу-кыр,
Яңадан гөрли мотор.
Юк икән ул, малайлар,
Төнге кырдан матур кыр!
Төнге кырдай сихерле
Күрмәдем мин бер җирне.
Бабай әйтә: «Кагылды
Сиңа басулар җене...»
Сүз көрәштереп тормыйм.
Кагылса кагылгандыр.
Җәй дә кайтып йөрсәм дә,
Туймам күк авылдан бер!

## Исәнме, мәктәп!

Укучыларның кулында
Кыр бүләге — чәчкәләр:
— Исәнме, мәктәп! — дигәндәй,
Хуш исләрен чәчәләр.

Бер нәни кыз үрелгән дә
Әнисе колагына:
— Исәнме, мәктәп! — дип сөйли,
Бу әле болай гына.

Бу әле сынамак өчен,
Иртәгә кыз әйбәтләп,
Шатланып, кычкырып әйтер:
— Исәнме, туган мәктәп!
Авыл сукмаклары буйлап
Атлыйлар малай-кызлар:
— Исәнме, мәктәп! — ди алар.

— Шәп, шәп! — ди урман-кырлар.

Шул бер үк сүзләр яңгырый
Ничәмә-ничә яктан:
— Исәнме, мәктәп! — дип әйтә
Йөз телдә безнең Ватан.

## Гомерлек бәйрәм

Дөнья белән танышулар
Башлана китаплардан.
Әти-әниләр тормышка
Китап тотып атлаган.

Авыр сугыш елларында
Солдат котомкасында
Китап атакага барган,
Кергән бомба астына.

Әлифбадан хәреф танып,
Белем алып үзенә,
Гагариннар чиксезлектән
Караган Җир йөзенә.

Үтәр еллар...
Алда юллар,
Синең тормыш юлларың.
Телим кулыңда һәр көнне
Яхшы китап булганын.

Китап белән дус икәнсең,
Бер шатлык, бер ямь бит ул.
Айлык-көнлек кенәмени,
Гомерлек бәйрәм бит ул!

## Зәңгәр песи

Бик ярата зәңгәр төсне
Зәңгәр песи,
Зәңгәр песи.
Зәп-зәңгәрдән
Киенгәндер-бизәнгәндер:
Үзе зәңгәр,
Күзе зәңгәр.
Зәңгәр песи,
Зәңгәр песи
Тотып кайткан зәңгәр күсе.
Тоткан булса песи әгәр
Тычкан-мазар,
Анысы да булыр иде
Зәңгәр-зәңгәр.
Зәңгәр песи
Эчә зәңгәр тәлинкәдән
Зәңгәр сөтне,
Зәңгәр сөтне—
Зәңгәр төсне.
— Нигә, — диеп, — бар да зәңгәр? —
Сорасагыз миннән әгәр,
Соң, шуны да күрмисезме:
Буяу карандашым зәңгәр!

## Күбрәк ошый...

Илшатмы сугыш чукмары?
Кем ышансын бу сүзгә?
Чынлыкта ничек булганын
Сөйлим мин үзегезгә.
Тәнәфестә колга хәтле
Бер малай кичә генә
Безнең класс кызларының
Бәйләнде ничәсенә.
Тәмам узынды ул «колга»,
Теңкәгә тиде бит, ә!
Этеп-төртеп тә җибәрә,
Чәчтән дә тартып китә.
Ә малайлар «батырлыкта»
Булдылар шундый бердәм:
Тайдылар безнең тирәдән
Бары да берәм-берәм!
Илшат кына курыкмады:
«Җитәр! — диде «колга»га. —
Телеңне син бик озайтма,
Кулларыңны болгама!»
«Безелдәмә, черки!» —диеп,
«Колга» аңа кизәнде,
Әмма үзе борыны белән
«Иснәп алды» идәнне!
Мышык-мышык еламсырап,
Сыпыртты «колга» аннан.
Имеш, Илшат кыйнаган да,
Имеш, борыны канаган.
Усаллыктан түгел Илшат,
Безне яклап «сугышты».
Кем ничектер, ә мин үзем
Яклыйм-аклыйм бу эшне.
«Мин көчле!» —дип йөргәннәрнең
Тавышы да чыкмады.
Миңа күбрәк ошый менә
Илшат — «сугыш чукмары»!
Ә сезгә?

## Тәнкыйтьлим...

«Сөйләрмен!» — дип, мин сүз бирдем,
Чыгыш ясарга кирәк;
Бездә кимчелекләр бик күп—
Кыю ачарга кирәк.
Тик кайсысын тәнкыйтьләргә?
Кызганмаска кемне соң?
Айдарнымы,
Наилнеме,
Илдуснымы,
Равилнеме,
Әлфияне,
Гөлшатнымы,
Булатнымы,
Илшатнымы—
Кемне икәнен кем белсен?!
Сөйләр идем мин Айдарның
Булатны кыйнаганын... —
Төшмәс микән икенчеләй
Йодрыгы миңа аның?..
Күп сорамас аулакта бер

Сугып тәгәрәтергә:
Айдар көчле,
Айдар йөри
Бокс түгәрәгенә.
Сөйләр идем мин Наилнең
Китапханә китабын:
«Рәсемнәре матур!» —диеп,
Ботарлаган-ертканын... —
Наилләрнең эте усал!
Эт өстерсә, нишләрсең?
«Эт тәнкыйтьне аңламый», — дип,
Телеңне тиз тешләрсең!
Сөйләр идем...
Гөлшат белән
Әлфиянең дәрестә,
Чыпчыклардай, бертуктаусыз
Чыркылдавы дөрес тә... —
Рус теленнән өйгә эшне
Күчерсәм мин берсеннән,
Әҗәткә егерме тиен
Алдым икенчесеннән.
Сөйләр идем мин Равилнең
Әшәке сүз әйткәнен... —
Велосипед биреп торды,
Гадәте әйбәт аның.
Төрле әкәмәт хәлләрен
Сөйләр идем Илдусның... —
Илдус бит минем җан дустым—
«Сатты, — диярләр, — дустын!»
Таптым!
Таптым!
Җаен таптым,
Үтим биргән сүземне:
«Тәнкыйть итә белмим...» —диеп,
Тәнкыйтьлим мин үземне!

## Һай, Якуп...

Безнең Якуп — төгәл малай,
Санаулы һәр сәгате:
Төп-төгәл җиде тулганда
Тору — аның гадәте.
Һай, уңган!

Ә сигездән бергә кадәр
Черем итә ул тагын...
Кайда, дисезме?
Дәрестә!
Ачып куеп китабын.
Һай-һай-һай...
Өйдә дәресен әзерли,
Үзләштерә һәр фәнне:
Язма эш белән ботканы
Кушкач — бигрәк тәмле!
Һай, тәмле!

«Бераз уйнап керим», — диеп,
Чыкса әгәр урамга,
Эзләп табып булмый аны—

Эттәй чаба ул анда.
Һай, елгыр!

Уйнап кайткач, ашап алгач,
Авырайта ярыйсы...
Дәрес качмас, бар бит әле
Телевизор карыйсы.
Һай, кызык!

Төнге уникегә кадәр
Якуп белем арттыра:
Телевизор тирәсендә
Чүмәләдәй утыра.
Һай-һай-һай...
Уникене сукты сәгать...

Тагын җитмәде вакыт.
«Йокы баса... Ятам...» — диеп,
Урынга ава Якуп.
Һай, Якуп...

## Сүзләр эзләү

Хәйләкәр дәү әни:
— Илшат улым, мә, — ди, —
Менә сиңа китап—
Ун иҗекле сүз тап.
Эзлә шуннан, актар,
Укытучың мактар.

Әй тотындым эзләргә!
Бер иҗекле сүзләр дә
(Әйтик, «бер» — үзе бер),
Ике иҗекле сүзләр дә
(Әйтик, «әй-тик» дип әйтик),
Өч иҗекле сүзләр дә
(Әйтик, сүзне «эз-ләр-гә»)
Була ул, бик мөмкин.
Никадәр интектем —
Ун иҗек тапмадым,
Китапны актардым,
Актардым, актардым...
— Дәү әни, кил әле!
Син табып бир әле.

Ул әйтә: — Эшем бар.
Китапны син актар,
Ак-тар-га-лаш-ты-ра тор...

— Дәү әни, син үзең
Ак-тар-га-лаш-тыр-га-лаш-тыр...

Дәү әни: — Улым, — ди, —
Буш түгел кулым, — ди.
Бу-лыш-тыр-га-лаш-тыр-га-ла-саң-чы!
Борын тартып,
Мыш-кыл-даш-тыр-га-лаш-тыр-га-ла-ган-чы!
— Уф, җитте!
Тын бетте.

Иҗекләр артып китте —
Житте, дәү әни!

## Кар ява...

Ак тынлык...
Ак дөнья —
Кар ява...
Кар ява...
Көн буе яуган кар —
Тын шатлык дөньяга.
Бу аклык,
Бу шатлык
Мәңгегә каласы
Күңелеңдә, әй, кеше! —
Табигать баласы.
Кычкырса бер әтәч:
— Кик-ри-күк!
Кик-ри-күк!
Бу тынлык шунда ук
Коелып төшәр күк.
Кычкырса бер карга:
— Кар да кар!
        Кар да кар!
Кар яуган тынлыктан
Тынрак нәрсә бар?
Урманда бер тукран
Тукыса:
— Тук та тук!
Ак карлар тынлыгын
Буламы туктатып?
Ак тынлык...
Ак дөнья —
Кар ява...
Кар ява...
Кар ташый тын шатлык
Күңелгә,
Дөньяга...

## Ялгыз каен буранда...

Урлаганнармы әллә
Кыш бабайның Кар кызын?
Күрче инде бу көннең
Котыруын, азуын!

Шундый зәһәр буранга,
Салкыннарга кем чыдар:
Посып бетте песнәкләр,
Качып бетте чыпчыклар.

Басып калды каен тик,
Әйтте: «Тамырым җибәрми.
Көчем — тамырым җирдә, — ди, —
Мине буран җиңәрме?»

Китте шуннан буталыш,
Югалды көн яктысы;

Җиде кат күк убылып,
Кар-диңгезләр акты соң!

Дөнья әле исән, дип
Улап торды җил генә.
Караңгы төн җитмичә
Басылмады зилзилә.
Тынып калды тирә-як,
Җилнең җыры басылды;
Җирне барлау өченгә
Йолдызлы күк ачылды.

Чыкты йөзе куркулы,
Боз кебек сулышлы ай,
Күрде: тора ак каен
Яралы сугышчыдай.

Ботаклары чуалган,
Башы акка уралган.
Дөнья тып-тын. Ни калган
Зәмһәрир кар-бураннан?

Каен аяк астында,
Бохар песие төсле,
Йомшак мамык көрт булып
Буран ята...
Кем көчле?!

## Мич башында биш мәче

«Ш», «Ч», «С» ны әйткәндә
Миләүшәбез интегә.
Интекмичә нишләсен,
Карагызчы инде, йә:
«Шат» та аның өчен «сат»,
«Чат» та аның өчен «сат»,
«Сат» та аның өчен «сат»,
Илшат түгел мин — «Илсат»!
Алма бирсә дәү әни:
«Кызыл икән төсе, — ди, —
Өсәү-бисәү төсе, — ди, —
Әсе түгел, төсе», — ди.
Ә беркөнне әтием
Утыртты да алдына:
«Тыңла әле, кызым, — ди, —
Булдым доктор янында.
Белә икән ул сине:
«Миләүшә бик чибәр, — ди, —
Матур итеп сөйләр», — ди,
Киңәш биреп җибәрде.
Иренмәсәң, тырышсаң,
Киңәш булыр бик яхшы:
«Мич башында биш мәче.
Биш мәченең биш башы».
Шул сүзләрне кабатла
Бит-кулыңны юганда,
Ашарга утырганда,
Таудан чана шуганда,
Курчаклы уйнаганда,

Гөлләргә су сипкәндә,
Әниеңне көткәндә,
Кичен йоклап киткәндә».
Миләүшәбез тырыша,
Көн дә күнегү ясый:
«Мис басында бис мәсе,
Бис мәсенең бис басы...
Миш машында миш мәше,
Миш мәшенең миш машы...
Мич мачында мич мачы,
Мич мәченең мич мәче...
Биш башында мич башы,
Мич башының биш мәче...
Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы...»
Хәзер инде яңадан
Миләүшәбез интегә.
Көчле булды даруы,
Карагызчы инде, йә:
«Су сал» дими, «Шу шал» ди.
«Илшат абый ушал» ди.
«Тәмле, ди ул, аш ише,
Килә минем ашыйшы».
Белер-белмәс кылансаң,
Менә нинди эш ясый:
«Миш башында мич мәче,
Мич мәченең биш басы...»
Әем лә, алай түгел!

## Биографик белешмә

Марс Шабаев 1933 елның 14 июлендә Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында укытучы гаиләсендә туа.

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Минзәлә педагогия училищесында белем ала. 1953—1958 елларда ул Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Шуннан соң аның журналистика өлкәсендәге күпьеллык хезмәт эшчәнлеге башланып китә: 1958—1960 елларда ул — Татарстан радиокомитетында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире, 1961—1964 елларда — «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, аннары 1967 елның апреленә кадәр «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналының җаваплы сәркатибе булып эшли. 1968—1970 еллар арасында «Чаян» журналында тәрҗемәче һәм Язучылар берлеге карамагында чыга торган «Идел» альманахының җаваплы мөхәррире булып эшләгәннән соң, М.Шабаев Татарстан китап нәшриятына эшкә күчә, анда баш мөхәррир урынбасары, ә 1972—1977 елларда баш мөхәррир була. Каты авырудан соң, М.Шабаев 1983 елның октябренә кадәр матур әдәбият редакциясендә өлкән мөхәррир булып хезмәт итә.

1984—1991 елларда Марс Шабаев профессиональ язучылыкка күчә, әдәби иҗат белән шөгыльләнә.

1991 елдан башлап 2005 елның гыйнварына кадәр «Казан утлары» журналында җаваплы сәркатип, аннары бүлек мөхәррире була.

М.Шабаевның шигырьләре көндәлек матбугатта узган гасырның 50 нче елларыннан күренә башлый. «Яңа җыр» дигән беренче китабы 1962 елда басылып чыга. 60 нчы еллар дәвамында гына да тагын җиде җыентыгы дөнья күрә.

«Җикән камыш», «Онытма» һәм русча чыккан «Ищу тебя» исемле җыентыклары өчен Марс Шабаев 1976 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

М.Шабаев проза һәм тәрҗемә өлкәсендә дә нәтиҗәле эшли. Ул — «Салда сәяхәт» исемле повесть һәм лирик хикәяләр авторы. Америка шагыйре Уолт Уитменның «Үлән яфраклары» исемле шигъри китабы М.Шабаев тәрҗемәсендә татар телендә чыгу (1975) татар тәрҗемә әдәбиятында вакыйга буларак кабул ителде.

Е.Евтушенконың «Казан университеты», «Әни һәм нейтрон бомба» поэмаларын, Рауль Мирхәйдәровның «Аккош», «Өч чакрымлык юл» хикәяләрен, «Иртәләгән сагыш», «Һәрнәрсәгә — акчалата», «Үзем хөкем итәм» романнарын тәрҗемә итә.

М.Шабаев, беренче тапкыр басылып чыгуына 150 ел тулган чорда, карело-фин халкының сайланма рунолары тупланган «Калевала»дан өзекләр тәрҗемә итә.

М.Шабаев РСФСР Язучыларының съездларында катнаша, РСФСР Язучылар оешмасының ревизия комиссиясендә әгъза була. Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы итеп сайлана.

М.Шабаев 1967 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. Ул, союз таркалгач, Татарстан Язучылар оешмасы әгъзасы.

1984 елда М.Шабаевка «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем бирелде.

Марс Садри улы Шабаев 2008 елның 21 февралендә җитмеш бишенче яшендә вафат булды.

## Марс Шабаевның басылып чыккан китаплары

**Татар телендә**

**Яңа җыр:** поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр.,1962. — 35 б.
**Кына гөле:** поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр.,1963. — 36 б.
**Ашкыну:** шигырьләр һәм поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. — 36 б.
**Зәңгәр планетам:** шигырьләр һәм поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. — 70 б.
**Сине эзлим:** шигырьләр һәм поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. — 58 б.
**Әби-апа:** шигырьләр һәм поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. — 58 б.
**Гомерлек бәйрәм:** балалар өчен шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. — 46 б.
**Ир-егет — Идел кичәр:** шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. — 60 б.
**Салда сәяхәт:** повесть. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. — 152 б.
**Җикән камыш:** шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. —126 б.
**Онытма:** шигырьләр һәм поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. — 142 б.
**Салда сәяхәт:** повесть / төзәтелгән һәм тулыландырылган 2 нче басма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. — 264 б.
**Көн арты көн:** шигырьләр һәм поэмалар / шигырь китапханәсе сериясеннән. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. — 384 б.
**Мич башында биш мәче:** балалар өчен шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. — 40 б.
**Актынлык:** шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. — 96 б.
**Җыр тәме:** шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. — 239 б.
**Сайланма әсәрләр:** шигырьләр, балладалар, легендалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. — 296 б.
**Алып батыр кайчан чабатасын каккан?:** балалар өчен шигырьләр, әкиятләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. — 79 б.
**Гомер уты:** шигырьләр, поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 142 б.
**Чаба иде бер куян:** әкиятләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. — 64 б.
**Гөрләвекләр:** балалар өчен шигырьләр һәм әкиятләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 151 б.

**Рус телендә**

**Ищу тебя:** стихи поэмы. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1974. — 157 с.
**Полушария:** стихи. — М.: Современник, 1979. — 64 с.

**Рус теленнән тәрҗемә иткән китаплары**

Уитмен Уолт. **Үлән яфраклары.** — Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. — 224 б.
Евтушенко Евгений. **Казан университеты:** поэмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. — 148 б.
**Чегән әкиятләре.** — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. — 320 б.
Мирхәйдәров Рауль. **Иртәләгән сагыш:** роман. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 447 б.
Мирхәйдәров Рауль. **Һәрнәрсәгә — акчалата:** роман, хикәяләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 382 б.

# Эчтәлек


Эзләнү юлыннан. *Х.Камалов* ....................

**Мин — сезнеке**
Мин — сезнеке ...........................
Җыр башлау ............................
Минем өчен .............................
«Сагыну гынамы бу?..» ......................
Яңгыр үтте... ............................
Фатиха сорау ............................
«Озын сыйрак, җиңел сөяк...» ....................
Ык агамыни? ............................
...Ра-ра-о-ом! ............................
Педучилище каеннары ......................
Зөһрә йолдыз ............................
Кадерәк ...............................
Ак каеннар йөгерә .........................
«Чәчелеп киткән җиләк түгел...» ................
Ти-и-иде! Ти-и-иде!.. ........................
«Әрәмәне бала-чага сарган...» ....................
«Таныш бу моң, бишектән үк таныш...» .............
Балыкчы карт сөйли ........................
Янә сәлам бирү ...........................
Алиһәләр ..............................
«Урман-сулар, болыннарга...» ....................

«Ык суында йөзә пар акчарлак...» .................
«Кабырчыклар җыям, кабырчыклар...» .............
«Кояш әле агач башларында...» .................
«Кама яры...» ............................
Хәтерләүләр *(Шигъри бәйләм)* ..................

**Сөяр өчен килдем дөньяга**
Назга сусау .............................
Мәхәббәтнең серле табигате ...................
Булсын... ..............................
Бодлер рухында ..........................
«Ак төймәм дә, күк төймәм дә түгелсең...» ............
Бәйлә... ...............................
Ела... ............................ ....
Вәгъдә йөзеге ............................
«Исемеңне язам комга...» .....................
Май кызлары ............................
«Урамда — җәй...» ........................
«Йоклый дөнья җәй кочагында...» ................
Алма кайчан кызара ........................
«Дөнья!..» ..............................
«Сокланулы яшерен карашымны...» ...............
Алай булгач .............................
Бер очрашу .............................
Хатка язмас бер сүз ........................
«Ак күгәрченмени!..» .......................
Кабан буйларында көзге җил ...................
Яшем — утлы яшен ........................
Мизгел ...............................
Баркарола ..............................
Сөяр өчен килдем дөньяга .....................
Өч экспромт ............................
«Әй, егет чак...» ..........................
Моңсу көзем *(Шигъри бәйләм)* ..................

**Янсын җаның, янсын...**
Килдем... ..............................
Көз ..................................
Урам. Гади якшәмбе ........................
Литавралар елый... .........................
Без ике ир ............................
Дворник карт белән малай ....................
Үз-үземне юату ..........................
«Кояш кебек балкый, диләр...» ..................
Кызлар бәрәңге ала .........................
Башка юк ..............................
Соңлый язган тәүбә ........................
Шагыйрь монологы ........................
Дирижер Алмазга .........................
Җаныңны як ............................
Куан, каләм! .............................
Казан циркында ..........................
Кичке эңгер ............................
Бушлай гына... ...........................
Бабай ................................
Ана .................................
Ак патшалык ............................
«Шагыйрь теленә кергәнсең икән...» ...............
Идел акчарлагына .........................
«Яшелләнеп уҗым шыткан...» ..................
Ялта аһәңнәре *(Шигъри бәйләм)* .................
Йөрәгем ...............................
Тукайны сагыну *(Шигъри бәйләм)* ...............

**Балладалар, легендалар**
Тормыш әлифбасы .........................
Кыз һәм Йөрәк ...........................
Таш гасыр кыйссасы ........................
Айзирәк ханбикә кыйссасы ....................
Һәйкәл ...............................

Шәһре Болгар ...........................
Ык әрәмәләренә карап моңлану .................
Куропаты корбаннары ........................
Балыкчы һәм дулкыннар ......................
Күз яшедәй күл яше .........................
Ай нидән сары, нидән салкын? ...................
Сагыш йорты — шәһәр бакчасы .................
Ярымшарлар ............................

**Поэмалар**

Шәймәт карт ............................
Яңа җыр ...............................
Сине эзлим... ............................
Җирән Конрад ...........................
Кына гөле ..............................
Артист ...............................

**Көмеш әкият**

Йөгерек гөрләвек .........................
Ташу ................................
Яз бүләге ..............................
Мөгез нигә кирәк? .........................
Сыерчыклар туган көн .......................
Тырый-тырый-тарый! ........................
Казлар очканда ...........................
Дачага бару .............................
Исәнме, бакча! ...........................
Һава сибү ..............................
Курчак уены ............................
Зөһрә нигә керә? ..........................
Кызыга... ..............................
Су керү ...............................
Урманга бару ...........................
Казанга кайту ............................
Иң-иң... ...............................
Авыл җәе ямьлерәк... .......................
Салават күпере ...........................
Шаян җил ..............................
Җәйге болында ...........................
Көмеш әкият ............................
Чыклы физзарядка ........................
Өйрәнегез ат менәргә .......................
Җиләккә бару ...........................
Илшат авылда булган .......................
Исәнме, мәктәп! ..........................
Гомерлек бәйрәм ..........................
Зәңгәр песи .............................
Күбрәк ошый... ...........................
Тәнкыйтьлим... ..........................
Һай, Якуп... ............................
Сүзләр эзләү ............................
Кар ява... ..............................
Ялгыз каен буранда... .......................
Мич башында биш мәче ......................

Биографик белешмә ........................
М.Шабаевның басылып чыккан китаплары ..........

Литературно-художественное издание

**Шабаев** Марс Садриевич

**ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Шабаев** Марс Садри улы

**САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР**

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.07.2011.
Форматы 70x108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 14,70.
Тиражы 1000 д. Заказ Р-995.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.